PRESSA.RU

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№4 (304) – АПРЕЛЬ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Тел… чувашларга илтер!

«Кайтыйк әле Мөслимгә бер…»

Хәзәр каганлыгы һәм болгарлар

ЕЛМАЙ ӘЛЕ БЕЗГӘ, «ГАГАРИН»!

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Авторлар: Ксения Семина, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Диана Сираҗиева

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 дана,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-863

Басарга кул куелды: 17.04.2017

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76

Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

КАНАТЫҢ ҖИЛПИ-ҖИЛПИ...

Апрельнең беренче көннәрендә, әле кыш Казанны калдырып китәргә теләмичә тартышканда, тәрәзә артында кинәт... сандугач җырлап җибәрде. Төнлә, әлбәттә. Һәм бу хәл кешеләр бер-берсен алдап-йолдап тинтерәтә торган 1нче апрельгә каршы төндә түгел, ә 2сеннән 3сенә каршы төндә булды. Бер-бер артлы тәрәзәләр ачыла башлады. Күрәсең, кешеләрнең йокысы качты, салкын апрель төнендә сандугач сайрасын әле. «Концертның» беренче бүлеге тәмамланыр алдыннан, кайдадыр өстәрәк – 11нче катлар тирәсендәге бер әбинең: «Тамагына салкын тидерә инде, бичара!» – дигән тавышы ишетелде. Урамда минус алты градус булып, җирдә яткан ак кар караңгы төнне яктыртып тора иде шул әле.

Уйлап карасак, без сандугачлар турында нәрсә беләбез соң? Иң атаклылары – Курск сандугачлары, әлбәттә. Үзебезнең Татарстанда исә кайсы җырчыны гына алма, бар да – сандугач. Тургенев сүзләренә ышансак, әйбәт сандугач ачык итеп сайрарга һәм музыкаль өлешләрне буташтырмаска тиеш. Википедия әйтүенчә, әлеге җырчы кошлар туган ягыбызга апрель азагында – көннәр җылынгач һәм тирә-юнь яшеллеккә күмелгәч әйләнеп кайта. Күрәсең, безнең Казан сандугачы көннәрнең исәбен бераз бутаган, әмма бит, бер кайткач, кабат меңләгән чакрымга очып китеп булмый инде! Ә бәлки, сәхнәдә беренче булып урын яуларга ниятләве булгандыр, оя корырга өметләнүе. Кышның шулай озын-озакка сузылуына кошлар да чыдап тора алмый, күрәсең...

«Өенә кайтырга зарыккан инде ул, бахыр!» – дип сөйләнде кабат теге әби, сандугачның «концертын» сабыр гына тыңлап бетергәч. Чынлап та шулай, ахрысы. Өеңне сагынасың икән, диңгез яры буенда язны көтеп утырырга кирәкми, очарга кирәк Ватаныңа, канатларыңны җилпи-җилпи.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Сандугач «концертын» журналыбыз сайтында тыңлый аласыз: www.protatarstan.ru

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен



Рәссам: С.О.Лывин. 1987 ел.

АПРЕЛЬ. ЛЕНИНО-КОКУШКИНО АВЫЛЫ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Тел... чувашларга илтер. Татарстанда милли телләрне өйрәтүче ничә мәктәп бар?

12. Бизнес – традицияләр сагында. Иске Күклюктә борынгы мирасны ничек саклыйлар

18. IT-буын. Билгесез киләчәкне ничек йөгәнләргә

22. Кайгыңны үзең генә йотма! Якын кешең югалганда нишләргә?

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

36. Андроид һәм кешенең җиде хисе. Робот Гагарин үзен ясаучыларны ни белән куркыта

40. Дөньядагы иң шәп урын! Галәм гизгән эт кайсы районга төшкән

46. «Кайтыйк әле газиз Мөслимгә бер...» «Кече Ватан патриотларының» чираттагы сәяхәте

52. Юка өчен юкә әйбәт. Кайбыч районыннан юка пешерү серләре турында

56. ТАССРның 100 еллыгына. Кайсы космонавтларның Казан обсерваториясенә килгәне бар

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

64. Хәзәр каганлыгы. Бу чордан безгә ниләр килеп җиткән

68. Китап киштәсе. Кыйпылчыклардан җыелган тарих

72. Төп бүләк – китап бастыру. «Татарстан» журналының әдәби премиясен дәгъвалаучы әсәр

78. Татар авыллары. Арча авыллары әнкәсе

86. Олы Солтан риваятьләре. «Бермуд өчпочмагы», упкәләгән күл һәм пычрак мунча

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

23.03

Олег Морозов, Федерация Советында Татарстан сенаторы, – Казанда узган «Бердәм Россия» партиясе – Кытай Коммунистлар партиясе» форумы көннәрендә:

– Татарстан, минемчә, кытайларны нәкъ менә инвестицион җәлеп итүчәнлек буенча беренчеләрдән булуы һәм Кытай инвесторларына тәкъдим ителерлек шартлары белән кызыксындырды. Өстәвенә, Кытай предприятиеләре инде эшли, шул исәптән махсус икътисадый зонада да. Шуңа да сәясәт – сәясәт белән, әмма, миңа калса, монда реаль инвестицияләр алу һәм реаль проектларны тормышка ашыру өчен зур потенциал бар.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

18.03

Алмаз Хәмидуллин, Казандагы 2 нче интернат-лицейның математика укытучысы, – «Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабында җиңеп чыккач:

– Минемчә, нәкъ менә мәктәптә дөньяны үзгәртеп була. Укытучы хезмәтенә алынганда, минем өчен ул төп идеягә әверелде. Һәм хәзер, мәктәптә инде җиденче ел эшләү дәверендә, педагогиканың чыннан да минем эшем икәнлеген аңладым. Монда үземне җәмгыятькә файдалы кеше итеп хис итәм.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

23.03

Алсу, җырчы, Татарстанның халык артисткасы, – Украина идарәчеләренең Россия кызы Юлия Самойлованы Киевтагы «Евровидение» конкурсына кертмәскә җыенуларын белгәч:

– Музыканың чикләре юк һәм булырга да тиеш түгел. «Евровидение»дә бу чикләрнең барлыкка килүе бигрәк тә кызганыч. Безне сәяси һәм башка төрле чикләр белән аермагыз! Музыка андый дөньяда яши алмаячак.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстанда **НИЧӘ** мәктәптә милли телләр өйрәнелә

КАЙСЫ авыл актив халкы белән аерылып тора

Киләчәкне **НИЧЕК** йөгәнләргә

Якын кешең югалганда **НИШЛӘРГӘ**

PRESSA.RU

ТЕЛ...
ЧУВАШЛАРГА ИЛТЕР!

Автор:
Руфия Фазылова

Татарстанда 126 меңнән артык чуваш кешесе яши. Чагыштырып карасак, Әлмәт шәһәрендә дә шулкадәр халык бар. Тик ни өчендер без ут күршеләребез, туганнарыбыз (чуваш теле төрки һәм монгол телләре арасындагы тел, аларны бәйләп торучы тел санала) турында аз беләбез. Баксаң, аларның да милли проблемалары безнекенә аваздаш икән.

Фото: Ната Смирнова

Мәктәпнең «Родник» ансамбле кызлары укытучылары белән.

ТҮБӘДӘН СУ АГА, ШУЛАЙ ДА...

Буа районында 14 чуваш мәктәбе бар. Без Рунго урта мәктәбенә юл тоттык. Әлеге уку йорты Буа районындагы чуваш мәктәпләренең милли үзәге булып тора. Бирედә 78 укучы белем ала. Мәктәптә бары тик бер Рунго авылы балалары гына икәнен исәпкә алсак, башка салалар белән чагыштырганда, бу сан бер дә начар түгел икәнлегенә инанасың.

Рунгога килеп кергәч тә, төзек йортлар, пөхтә урамнар күреп сөенеп куйдык. Кайсыдыр ягы белән татар авылларын хәтерләтә. Чәчәкләп ясалган тәрәзә яңакларын да очраттык. Әллә бирედә татарлар да яшиме диган уй туды.

– Рунго чып-чын чуваш авылы, – дип сөйләде безгә урта мәктәпнең укыту эшләре буенча директор урынбасары Ирина Гордеева. – Элек безнең авыл бик зур – 800 хуҗалыклы булган, бүген исә 200 хуҗалык кына бар. Бөтен авыллардагы проблема безгә дә кагылды: авылда яшьләр калмый. Әле ярый, Буа шәһәре якын, җиде генә чакрым. Халык шунда барып эшли. Аеруча ир-атларга кыен, алар Казанга да, Мәскәүгә дә йөреп эшләргә мәҗбүр. Җәйләрен тирә-як авылларга «шабашка»га йөриләр. Тормышны алып барырга кирәк бит. Чувашлар бик тырыш халык, бер эштән дә курыкмыйлар.

Рунго урта мәктәбенең тарихы 1831 нче елларга барып тоташа. Башта ул чиркәү мәктәбе буларак эшләгән. 1917 елдан башлангыч мәктәпкә әйләнгән. 1949 елдан инде урта мәктәп статусы алган. Ул чорда балалар өч бинада укыган. Һәм 1987 елда Рунго мәктәбе ике катлы, 300 бала сыйдырышлы итеп ачылган. Һәм шул көннән бирле уку йортына бер тапкыр да ремонт булмаган. Буялган агач иданнар, иске тәрәзәләр, «шыгырдый» торган ишекләр, без хәзер мондый урта мәктәпләрне күреп күнекмәгән.

– Мәгариф учреждениеләренә капиталь ремонт программасына быел кертмәделәр, – дип сүзен дәвам итте Ирина Владимировна. – Киләсе елга булыр, дип өметләнәбез. Әлбәттә, яхшы мәктәптә укыйсы килә. Белем сыйфатына килгәндә, сер бирмибез: «Республиканың иң яхшы йөз авыл мәктәбе» исемлегенә кердек. Төрле юнәлештәге түгәрәкләр эшләп килә. БДИ һәм ДЙАнә дәрестән соң калып әзерләнәләр. Шәһәр мәктәпләрендә укучылар акча түләп репетиторга йөрсә, безнең укытучылар бушка эшли. Балаларыбыз шулай ук имтиханнарны югары балларга тапшыра.

«ТУГАН ТЕЛГӘ ИХТИРАМ БАР, ИГЪТИБАР ЮК»

Мәктәпнең чуваш теле укытучысы Надежда Сайкина белән таныштык. Балалар белән махсус милли киемнәрдән каршы алды ул безне. Мәктәптә «Родник» ансамбле оештырган. Укучылар белән районда, республикада узган төрле конкурсларда чыгыш ясыйлар, призлы урыннар яулыйлар икән. Безгә дә укучы кызлар чуваш халык биюен күрсәтте.

– Укучылар туган телләрен ихтирам итәме, ни дәрәҗәдә беләләр? – дип сорыйм Надежда Михайловнадан.

– Дөресен генә әйткәндә, чуваш теленә игътибар кимеде. Өйдә әби-бабай, ата-ана белән аралашу теленә генә калып бара ул. «Безгә БДИны рус телендә бирәсе бар», – дип кенә әйтәләр. Әйе, авылда әле туган тел барыбер саклана. Ә менә шәһәрдә ата-аналар балаларын бөтенләй чуваш теленә өйрәтми. Янәсе, нәрсәгә кирәк ул?! Имтихан бирәсе юк, сөйләшкәндә русча аралашу әйбәтрәк. Без, әлбәттә, хәлдән килгәннең барысын да эшлибез: милли бәйрәмнәребезнең берсе дә читтә калмый, традицияләрне саклыйбыз. Дәрестән тыш чараларда да милли үзенчәлекләр турында сөйлим.

Рунго урта мәктәбендә төп фәннәр рус телендә укытыла. Ана теленнән тыш, укучылар рус, татар, инглиз телләрен өйрәнә. Малайлар-кызлар аеруча соңгысын яратып укый икән. Яңа белем бирү стандартлары кертелгәннән соң, чуваш теленең сәгать саннары кимегән. Мисал өчен, 5нче сыйныфлар чуваш телен атнага 3 дәрес укыса, өлкән классларга җиткәндә аның саны бергә генә кала. Өстәвенә, чуваш теле һәм әдәбиятын да берләштергәннәр, хәзер ике фәнгә бер генә билге чыга.

– Чуваш теленнән БДИ юк, ә менә ДЙА бар, – дип сүзен дәвам итте Надежда Михайловна. – Узган ел биш укучым ДЙА тапшырды, баллар уртачадан югарырак булды. Әгәр БДИны да укучыларга туган телләрендә бирергә ярасa, ана телләренә карата игътибар артыр иде, минемчә. «Чуваш теленең кирәге юк бит», – диган фикерне бәлки ата-аналардан ишетмәс идек. Хәер, туган телгә мәхәббәт БДИ бирүгә генә кайтып калырга тиеш түгел. Бу гаиләдәге тәрбиядән дә килә. Бала үз туган телен белергә тиеш!

– Чуваш теле укытучыларына кытлык юкмы? – дим.

– Юк, Ульяновск, Чебоксарда чуваш теле укытучыларын әзерлиләр, Казан дәүләт педагогика университетында да заманында чуваш теле белгечләре әзерләделәр. Ә тулаем алганда, мәктәпкә яшьләр бик килми. Коллективыбыз урта, өлкәнрәк буын укытучылардан тора. Әле менә яңа уку елында башлангыч сыйныфларга бер яшь мөгаллимә килде. Күрше авылдан, татар кызы, чувашча бер диган итеп сөйләшә.

Бәйрәм-йолаларга килгәндә, рус бәйрәмнәре «Раштова» («Раштуа»), «Монгон» («Пасха»)

PRESSA.RU

дан тыш «Җаварни» («Масленица»), «Мигула» («Николов день») уздыралар. Ә иң мөһим көн, чара дисәм дә дөрес буладыр – «Семык» («Родительский день»).

– Күптән күрмәгән авылдашың, туганыңны очратасың килә икән, ул көнне авылга кайтырга кирәк, – дип сөйләде Надежда Михайловна. – Әби-бабасы, ата-анасы каберенә барып дога кылу, аны чистарту – һәр чуваш кешесенең бурычы. Җитди сәбәпләре булмаганда, һәр кеше зиратка бара, ераклардан ук кайталар. Үзенә күрә бер бәйрәм ул. Бөтен туган-тумача җыела, авылдашлар очраша. Күрешәләр, кунакка йөрешәләр.

«Кул астыбызда бөтен нәрсә бар: кәкре ботаклар, агачлар. Менә шуларны аз гына төзәтеп, ышкылап яки кисеп, буяп җибәрәсе генә бар бит», – ди рәссам-укытучы Александр Алексеев.

ТЕРЕ ЛЕГЕНДА

Рунго урта мәктәбе укытучылары арасында атаклы рәссам, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Александр Алексеев та бар. Чуваш дөньясында аны Сандр Пикл дип тә беләләр. Беренче минуттан ук үзенә гашыйк итә торган үзенчәлекле шәхес ул. Мәктәптә аның зур остаханәсе бар. Хәер, аны туган якны өйрәнү музее дисәм дә ялгыш булмас. Монда ни генә юк! Чуваш халкының үткәнен гәүдәләндергән архитектура сыннары, авыл турында сөйләүче аерым рәсем, эшләнмәләр...

– Апрель башында 60 яшемне тутырдым, эштән кусалар дип, куркып торасы юк, дөресен сөйлим, – дип башта гаҗәпкә калдырды Александр Иванович. – Остаханәгә су үтә, менә карагыз. Мәктәп бинасына утыз ел бит. Юк, миңа бу эшләргә, иҗат итәргә бер генә дә комачауламый. Киресенчә, үзенә бертөрле мохит тудыра.

Чынлап та, остаханәдә аерым бер рух хөкем сөрә. Тишек түбәдән аккан сулар да иҗади тәртипсезлек җирлегендә килешле күренә. Александр Иванович белән сәнгать әсәрләрен карап йөрибез. Бүтән бер җирдә дә мондый эшләнмәләр күргәнем юк иде: агачтан уеп ясалган ат, төрле кош, кеше сыннары, киндергә ясалган рәсемнәр, матрешкалар, тагын әллә ниләр...

– Төрледән төрле ат сыннары ясагансыз. Чуваш халкы да атларга дан җырлыймы әллә? – дим.

– Әйе, атлар безнең өчен тырышлык символы. Татарларның да атларны яратканлыгын беләм. Безнең ул яктан охшашлык бар. Хәер, чуваш белән татарны берләштерүче әйберләр байтак, тамырлар уртак бит. Безне бары тик дин һәм партия генә аерган.

Александр Алексеев ясаган картиналар беренче карашка бик аңлашылмаска да мөмкин: тирән фәлсәфә ята аларда. Изге Ана сыны янында кәҗә башы урнашкан, сулык янында без күрмәгән ялгыз хайван басып тора. Миңа исә аның «Хайлав» («Сказание») картинасы ошады. Адәм баласының бөтен тормышы гәүдәләнә анда: түгәрәк сулыкның (ягъни җирнең) бер башында кечкенә генә сыннар. Алар су буйлап килә бара һәм сыннар да зурая. Ә һавада кушаяклап



Бүтән бер җирдә дә мондый эшләнмәләр күргәнем юк иде: агачтан уеп ясалган ат, төрле кош, кеше сыннары, киндергә ясалган рәсемнәр, матрешкалар, тагын әллә ниләр…

Чуваш кешесе 1 ай эчендә татарча өйрәнә ала, диләр. Чынлап та, уртак сүзләр бик күп: сәлам (салам), чәй (щей), кишер (кишер), сөт (сет), әти (атте), әни (анне), алма (улма), туй (туй), бал (пыл), савыт (савыт) һ.б.

ат чабып бара. Чувашларда: «Вакыт ат кебек юырта гына, аның артыннан җитеп булмый», – дигән гыйбарә бар икән. Рәссам шуны да әйтергә теләгән.

Александр Ивановичның барлык картиналарын күрү бәхете насыйп булмады. Алар аның өендә саклана икән, дөресрәге, чормада. Рәссамның монда тулы бер эш бүлмәсе, ди. Ә без Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре белән күбрәк мәктәп, балалар турында сөйләштек. Менә нәрсәләр борчый аны:

– Бүген бөтен нәрсәне стандартларга кертеп бетерделәр. Иҗатка урын бик юк. Мин, мәсәлән, балалар белән эшләгәндә, бары тик табигый әйберләр генә кулланам. Кул астыбызда бөтен нәрсә бар: кәкре ботаклар, агачлар. Менә шуларны аз гына төзәтеп, ышкылап яки кисеп, буяп җибәрәсе генә бар бит. Бер дигән сәнгать әсәре туа! Һәр нәрсәне: агачтан башлап пластилинга кадәр эшкә җигәбез. Игътибар иткәнегез бармы, кечкенә балалар, кеше сурәте ясаганда, әти-әниләрен төшерәләр. Бу табигый, ул күз алдына иң беренче аларны китерә. Ә үсә-үсә үзен ясый башлый.

Александр Иванович пластилиннан ясалган сурәтләр янына чакырды:

– Бу безнең элеккеге укучыларыбызның эшләре. Ничә еллардан соң да моннан үз эшләрен табалар.

Шул рәвешле рәссам укытучы, һәр эш янына тукталып, аның тарихы, үзенчәлекләре турында сөйләде. Нәрсә дим, Рунго балалары бәхетле, мондый укытучыда белем алган малайлар һәм кызлар, һичшиксез, сәнгатьне тоемларга, яратырга өйрәнәләрдер.

«БИЕП КЕНӘ БУЛМЫЙ!»

Казанда чыга торган чуваш газетасы «Сувар»ның баш мөхәррире Константин Малышев да тумышы белән Буа районыннан. Рунго авылын, аның мәктәбен бик яхшы белә, анда еш була. «Биредә элек яһүдләр яшәгән. Шуңа күрә бу авыл зыялылыгы, күп уен коралларында уйный белүче кешеләре белән аерылып торды», – диде. Ә безгә таныш рәссам Сандр Пиклны: «Чуваш халкының бик зур горурлыгы», – дип атады.

– Кызганычка каршы, чуваш теле бүген, өйдән чыгып киткәч, кирәкми башлады, – дип фикерләре белән уртаклашты Константин. – Кешеләрдә сүз запасы кими. Моның сәбәпләре төрле. Беренчедән, 2012 елда мәгариф системасына ФГОС стандартлары кертелде. Хәзер чуваш балалары бакчада ук, дәүләт теле буларак, рус һәм татар телләрен өйрәнә. Әйе, тәрбиячеләр алар белән туган телләрендә аралаша, ә чуваш хәрефләрен беренче тапкыр мәктәпкә килгәч кенә күрәләр. Нәтиҗәдә, ана телләрен фән буларак кабул итмиләр. Икенчедән, мәгълүмати технологияләр заманы хәзер, ә алар чуваш теленә ихтыяҗ тудырмый. Рус телен белсәң, Интернеттан җаның теләгән әйберне табарга мөмкин. Лексикага көн саен яңа сүзләр өстәлә һәм алар барысы да читтән кергән терминнар. Чувашлар ниндидер фәнни ачышлар, яңа терминнар кертсә, әлбәттә, аңа карата ихтирам артыр иде. Ә бу мөмкин түгел, чөнки чуваш телендә физика, химия, башка фәннәр алып барылмый. Ә бер филология белән генә ерак китеп булмый. Өченчедән, хәзер милли җанлы белгечләрне бармак белән генә санарлык. Укытучының бүгенге максаты – БДИ, ДӘИндә яхшы күрсәткечләргә ирешү. Берничә ел элек чыгарылыш сыйныф укучылары чуваш теленнән бөтенләй имтихан тапшырмый иде. Соңгы ике елда, укучыларга, үз теләге белән чувашча ДӘИ бирергә рөхсәт ителә башлады. Минемчә, тугызынчыны тәмамлаган һәр укучыга мәҗбүри рәвештә туган теленнән имтихан тапшыртырга кирәк. БДИ да булса тагын да яхшы булачак. Шул чагында, бәлки туган телгә игътибар артыр.

Бүген ата-аналар, бигрәк тә яшьләр, балаларын шәһәр тормышына әзерли. «Аңа Казанда, Самарада чуваш теле нигә кирәк?» – дип фикер йөртәләр. Янәсе, артык мәгълүмат белән баланың башын катырмаска кирәк. Ә чувашларда шундый әйтем бар: «Үз телеңне камил белсәң, чит телне өйрәнү берни түгел».

Мәктәпләрдә очрашуларда еш булам. (Константин Малышев чуваш телендә проза әсәрләре дә яза. – **Авт.**) Хәзер балалар тел белүләре белән мактана алмый, шигырь сөйләү, әкиятләр кую кебек гади әйберләр артта калып бара. Аның каравы оста итеп бииләр. Махсус милли киемнәр тектергәннәр. Шул рәвешле укытучылар да, балаларның туган телләрен белмәүләрен яшерергә тели кебек. Ә чуваш биюен татар кызы да, рус кызы да бии ала. Вазгыять үзгәрмәсә, киләчәктә чуваш теле әнә шулай милли биюләрдә, киемнәрдә генә калыр, дип куркам…

Саннар

- Татарстанда **98 чуваш мәктәбе** бар.
- Россиядә бер миллион кеше чуваш телендә сөйләшә, шуларның **55 проценты** Чувашия Республикасында яши.
- Татарстанда чувашлар күпләп яшәгән районнар: Чүпрәле, Буа, Нурлат, Тәтеш, Аксубай, Чирмешән, Әлки.

PRESSA.RU

МИЛЛИ ТЕЛЛӘР ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН ТАТАРСТАН МӘКТӘПЛӘРЕ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ СОСТАВЫ (кеше)

Татарлар	2 012 571	Украиннар	18241	Белоруслар	4592
Руслар	1 501 369	Башкортлар	13726	Яһүдләр	2624
Чувашлар	116 252	Азәрбайҗаннар	9527	Немецлар	2200
Удмуртлар	23 454	Үзбәкләр	8881	Дагыстанлылар	1908*
Мордвалар	19 156	Әрмәннәр	5987	Казахлар	1758
Марилар	18848	Таҗиклар	5859	Грузиннар	1478

* Татарстан Республикасында яшәүче Дагыстан Республикасы халыклары вәкилләре



Кыргызлар →	1156	Чеченнар →	420	Ассириялеләр →	123
Төрекмәннәр →	968	Осетиннар →	346	Һиндлар →	87
Кореялеләр →	864	Гарәпләр →	271	Бурятлар →	57
Лезгиннар →	862	Вьетнамнар →	244	Сүриялеләр →	6
Төрекләр →	486	Ингушлар →	156	Месхетиннар →	3
Греклар →	477	Әфганнар →	136		

PRESSA.RU

ДӨНЬЯ ЧЕЛТӘРЕ ДУС ҺӘМ МӘРХӘМӘТЛЕ БУЛЫРГА ӨНДИ

Тимур Кадыйров, Татарстан халыкларының яшьләр ассамблеясе советы рәисе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы:

– Безнең оешма төрле милләт вәкилләре булган яшьләрне күптөрле чаралар уздыруга җәлеп итү буенча зур эш башкара. Шул рәвешле аларга тамырларын һәм үз мәдәниятләрен тирәнрәк белергә ярдәм итәбез. Әлеге белемнәр күбрәк булган саен, алар башка халыкларның мәдәниятләре белән традицияләренә дә кызыксыныбрак карыйлар, күпмилләтле яшь татарстанлыларның шулай итеп үзара бәйләнешләре ныгый төшә.

Әмма яшьләр белән эшләү өчен яңа, заманча форматлар кирәк, шулай ук – күбрәк белем бирүгә йөз тоткан медиапроектлар. Шушыларны күздә тотып, без 25–26 мартта Казанда узган бөтендөнья инстамитын (WWIM15) оештыру эшләрендә катнаштык. Бу чара Россиянең һәм чит илләрнең иң атаклы блогерларын берләштерде. Дискуссияләр мәрхәмәт һәм халыклар дуслыгы турында барды. Инстамитта катнашучы яшьләрнең Татарстаныбыз башкаласында төрледән-төрле милли костюмнардан төшкән һәм Инстаграмда үз аккаунтларына элгән сурәтләре гаять зур популярлыкка ия булды. Блогерлар язылучыларга теге яки бу костюмның кайсы милләтнеке булуын язарга тәкъдим итте. «Рәсми Татарстан» аккаунты белән Инстаграмга урнаштырылган бу фотолар гомуми исәп белән 10 мең «лайк» җыйды.

Социаль челтәрләр – эшләгән эшебезне популярлаштыру юнәлешендә иң көчле коралларның берсе булып тора, һәм мондый мөмкинлек бирә торган заманча технологияләрне республиканың милли сәясәтен тормышка ашыручы проектларны танытканда актив кулланырга кирәк. Татарстан халыкларының III съездында без нәкъ менә шулар хакында сөйләргә планлаштырабыз да.

ЯКШӘМБЕ МӘКТӘБЕНДӘ БУРЯТ БҮЛЕКЧӘСЕ АЧЫЛДЫ

Маринэ Хухунашвили, Татарстан халыкларының яшьләр ассамблеясе рәисе урынбасары, Казан шәһәрендә гомер итүче грузиннарның «Сиони» Милли-мәдәни автономиясе рәисе, Казан шәһәренең Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе директоры:

-Якшәмбе мәктәпләренең төп максаты – үзебезнең шәһәрдә яшәүче милли автономия вәкилләренең телләрен саклау. Иң өстенлекле юнәлешләрнең берсе – баланы үз мәдәнияте һәм халкының уникальлеген, кыйммәтен генә түгел, ә аны әйләндереп алган башка халыкларның үзенчәлекләрендә аңлый, ихтирам итә белердәй итеп тәрбияләү тора. Күпмәдәниятле тәрбия турында сүз бара. Бүген безнең мәктәбебезгә 400 Казан баласы йөри, алар – 17 төрле милләт вәкиле. Татарстан Халыклары ассамблеясендә теркәлгән 36 автономиянең 19ы әлегә мәктәптә үз бүлекләренә ия түгел. Төп киртәләрнең берсе – укытучыларның булмавы. Беренчедән, Урта Азия, Кавказ арты һәм элеккеге союздаш республикаларның телләренә өйрәтә алырдай педагогларны (ә безнең мөгаллимнәр, закон таләпләре буенча, нәкъ менә педагог белеменә ия булырга тиешләр) Татарстанда табуы җиңел түгел. Икенчедән, без – нибары өстәмә белем бирү учреждениесе, һәм педагогларның эш хаклары мактанырлык түгел. Мин хәтта безнең мәктәптә эшләүне чын мәгънәсендә каһарманнарча хезмәт, миссионер хезмәте, дип атар идем. Моннан тыш, барлык гаиләләр дә (бигрәк тә балалары югары сыйныфта укып, БДИ тапшырырга әзерләнүчеләрнеке) балаларын өстәмә укулар белән җәфаларга теләми. Шулай ук Интернетта утырып, социаль челтәрләргә кереп, үзләренә юаныч таба алганда, югары сыйныф укучылары үзләре дә безгә килергә атлыгып тормый. Ә менә килгәннәре укый да, без оештырган чараларда бар күңелен биреп катнаша да. Бу елда без украин, азәрбайҗан, мари бүлекчәләрен яңадан эшләтеп җибәрдек. Беренче тапкыр вьетнам һәм бурят бүлекләрен ачтык. Чиратта – удмуртлар, аларның да аерым бүлекләре булганы юк әле. Кеше үз ватаныннан никадәр ераграк булса, аның хакындагы хәтерне шулкадәр ныграк сакларга һәм балаларына да күчерергә омтыла. Безнең мәктәп бу эштә ярдәмгә килергә һәрчак әзер.

УДМУРТ ТЕЛЕВИДЕНИЕСЕ БУЛСЫН ИДЕ!

Андрей Герасимов, «Базис-Инвест-Холдинг» ҖЧҖ директоры, «ТРнда яшәүче удмуртларның милли-мәдәни автономиясе» ТИО идарәсе рәисе:

– Без балалар һәм яшьләр белән эшләүгә күбрәк өстенлек бирәбез. Республикадагы этномәдәни компонентлы балалар бакчалары өчен «Мудорвай» («Росточек») дип исемләнгән халык иҗаты фестивале кебек эре проектлар оештырабыз һәм уздырабыз. Күптән түгел Удмуртиядәге удмурт берләшмәләре федераль дәрәҗәдәге «Чакара» фестивален бергәләп уздырырга тәкъдим ясадылар. Фестиваль июль аенда Кукмара районында үтәргә тиеш. Төп бурычларыбызның берсе – уңышка ирешкән һәм бу тормышта үзләрен тапкан шәхесләр мисалында удмурт берләшмәсе яшьләрен дә мәдәниятебезне саклый һәм үстерә алырдай төпле итеп тәрбияләү. Милли телләрне һәм традицияләрне популярлаштыру киң колачлырак итеп башкарылырга тиеш. Татарстан халыкларының III съездында без, мари һәм мордва вәкилләре белән бергә, Татарстан территориясендә безнең телләрдәге дә теле- һәм радиотапшырулар булдыру инициативасы белән чыгыш ясарга ниятләп торабыз. Моннан тыш, районнардагы якшәмбе мәктәпләренә финансларны бүлеп бирүне дә арттырырга кирәк, дигән мәсьәләне күтәрергә җыенабыз.

Татарстанның милли сәясәтне алып бару юнәлешендәге эшчәнлеге – кабатланмас һәм бердәнбер, нәтиҗәле үрнәк рәвешендә ул Россиянең башка төбәкләрендә дә файдалы кулланыла алыр иде.

Владимир Кусков,
«Свет» ААҖ
генераль директоры

СЫЙФАТ ЮГАРЫЛЫГЫН **САКЛАП…**

1835 елда Алабуга сәүдәгәре Фёдор Чернов Сюга пыяла заводына нигез сала. Бүген исә әлеге завод эшен Удмурт Республикасының Можга шәһәрендәге «СВЕТ» Ачык акционерлык җәмгыяте буларак дәвам итә. Хәзер ул – Россиядә пыяла ясау тармагының тотрыклы үсештәге оешмаларыннан берсе, илебездә пыяла савыт җитештерә торган иң эре ун предприятие исемлегенә керә.

«СВЕТ» ААҖ – иң заманча техника белән җиһазландырылган куәтле предприятие. Белгечләренең профессиональлеге, җитештерелгән продукциянең тел тидермәслек сыйфаты, заказ бирүченең шәхси теләкләрен исәпкә алып эш йөртү завод продукциясенә дөньякүләм дәрәҗәдә көндәшлек мөмкинлеген бирә. Россия Федерациясенең пыяла савыт базарында «СВЕТ» тамгасы төшерелгән продукциянең гомуми авырлыгы якынча 5 процентны тәшкил итүен телгә алу да җитә.

Предприятиенең барлык партнерлары да аларга озатыла торган пыяла савытның югары сыйфатын, Европа стандартларына һәм халыкара таләпләргә туры килүен билгеләп уза. «СВЕТ» ААҖнең продукциясенә Россия территориясендә һәм чит төбәкләрдәге ликер-аракы, сыра һәм хәмерсез эчемлекләр җитештерә торган иң эре предприятиеләрнең ихтыяҗы зур. Завод 20 елдан артык Россия Федерациясенең иң эре алкоголь компанияләренең берсе булган «Татспиртпром» АҖ белән уңышлы хезмәттәшлек итә. Завод продукциясенең 35%ы нәкъ менә шушы алкоголь ширкәте өчен җитештерелә.

Заводның төп һәм ярдәмче цехларында үзгәртеп кору һәм техник яктан җиһазландыру эшен даими алып бару предприятие җитәкчелегенең стратегик фикер йөртү сәләте турында сөйли. Соңгы елларда җитештерү процессы тулысынча яңартылган. 2016 елның ноябрь аенда заводта – парфюмерия һәм фармацевтика сәнәгате өчен савытлар җитештерү линиясен, ә быел февральдә пыяланы туендыргычта буяу җайланмасын эшләтеп җибәрделәр. Бу исә бер тәүлектә 40 тоннага кадәр төсле пыяла җитештерергә мөмкинлек тудырды. Хәзер исә «СВЕТ» – Россиядә бер үк вакытта төсле пыяла да, буялмаган супер ак (superflint) пыяла да эшләп чыгара торган бердәнбер предприятие.

Югары сыйфат һәм арзан бәя, инновация алымнары кулланып җитештерелгән продукциянең күптөрлелеге Россиянең бик күп төбәкләрендә һәм чит илләрдә сатып алучыларның ышанычын яуларга ярдәм итте. Моннан ике гасыр диярлек элек нигез салынган пыяла җитештерү традицияләрен дәвам итеп, югары сыйфатлы һәм кирәкле продукция эшләп чыгара торган «СВЕТ» ААҖ киләчәккә тулы ышаныч белән карый.

свет

«СВЕТ» ААҖ
427790, Россия, Удмурт Республикасы,
Можга ш., Свердловск бульвары, 39,
тел. (34139) 3-30-50, 3-00-08,
e-mail: steklo@zavodsvet.ru,
www.zavodsvet.ru

Реклама

PRESSA.RU

Кунакларны «Марийские зори» ансамбле каршы ала.

БИЗНЕС – ТРАДИЦИЯЛӘР САГЫНДА

– Әйе, без активлар. Ә башкача булмый бит! Нәрсә, безнең өчен Путин килеп эшләрме әллә боларны? Дөрес, көтеп утырган авыллар да бар-барын. Без андыйлар түгел…
Җирле активист һәм мәктәп директоры Иван Мельников мине Иске Күклюк – Алабуга районында бердәнбер мари авылы буенча таныштыру экскурсиясенә алып китте. Минем исә үземнең максат – бүгенге икътисадый тотрыксызлык һәм глобальләшү заманында бу кешеләрнең үз авылларын гына түгел, бәлки традицияләрен ничек итеп саклап кала алуларын белеп кайту.

Иван Мельников – мәктәп директоры, җирле Кулибин һәм активист.

Автор:
Ольга Туманская

ӘБИЕМ МИРАСЫ

Мине беркайда да әле болай каршы алганнары юк иде. Авыл клубына килеп кенә җиттем, каршыма матур күлмәк-алъяпкыч кигән ханымнар килеп басты. Күңелле җыр да сузып җибәрделәр, биеп тә киттеләр.

– Алар сезгә: «Сез, кадерлеләрем, кай яклардан килдегез? Без сезне көтәбез, каршы алабыз!» – дип җырлыйлар.

Боларын миңа, маричадан үзенчә тәрҗемә итеп, Иван Николаевич пышылдый.

Мин дә, соклануымны яшерә алмыйча, «Әфәрин!» дип кычкырудан тыелып кала алмадым, һәм без, бер-беребездән канәгать калып, әчкә – җылыга узабыз. Анда миңа зур горурлык белән үз куллары белән теккән мари милли киемнәрен күрсәтәләр. Ә мин гармунчыдан күзләремне ала алмыйм – менә ул чын раритетка ия кеше! Күлмәгенә гасырдан артык икән, ә күкрәген борынгы тәңкәләр бизи.

– Әбием – Нина Ивановнадан калган, – дип елмая ул. – Мин дә – Нина Ивановна. Шуңа күрә әбием нәкъ менә миңа мирас итеп калдыргандыр. Ничә тапкыр сатып җибәрүемне сорадылар, сатмыйм – саклыйм.

Фото: Ната Смирнова

Гаилә җәүһәрләрен саклаучы Нина Ивановна.

«Марийские зори» ансамбле артисткасы Алевтина.

Иске Күклюк халкында гаилә җәүһәрләренә генә мондый караш түгел икән.

– Безнең «Марийские зори» ансамбле үзенең утыз еллыгын бәйрәм итәчәк, – дип сөйли Алевтина. – Аны иң элек бер максат: телне, традицияләрне саклау берләштерде. Балалар аларны өйрәнсен һәм онытмасыннар иде, чөнки безнең мари авылы – тирә-якта бердәнбер. Бүген исә районда бер генә чара да бездән башка узмый!

КҮКЛЮКНЕҢ ИКЕ «КУЯНЫ»

– Ә сез безнең турыда каян ишеттегез? – дип сораштырды миннән авылдагы кызыклы урыннары белән таныштырып йөргәндә Николай Мельников.

– «Сарафан радиосы» җиткерде! – дим.

Николай – Иван Мельниковның улы. Әтисе кебек үк, Иске Күклюк мәктәбендә эшли. Әтисе кебек үк авыл активисты булып тора.

– Бу безнең төп әтәчебез, – дип күрсәтә ул миңа язгы кояш карап өлгергән кар өеменә. – Биеклеге берничә метрга җиткән иде! Ышанмыйсызмы? Ә узган елны шундый зур маймыл әвәләп ясадык, хәтта Яңа елга әзерлек буенча республика конкурсында да җиңеп чыктык. Бүләккә бирелгән акчаларга

Бөек Ватан сугышы тылы хезмәтчәннәре хөрмәтенә һәйкәл конкурста откан акчалар хисабына куелган, ә репрессия корбаннарына һәйкәлне һәм фәрештә скульптурасын үз куллары белән эшләгәннәр.

PRESSA.RU

Авточана.



Убырлы карчыкның күчмә йорты.

Мобиль чыршы.



Николай Мельников, укытучы һәм җирле яшьләр оешмасы җитәкчесе.

Бөек Ватан сугышы елларындагы тыл хезмәтчәннәре хөрмәтенә һәйкәл төзедек.

Сүз уңаеннан, Иске Күклюкта һәйкәлләр берәү генә түгел – өчәү. Ә музейлар квадрат метрга исәпләгәндә республика башкаласындагыга караганда да күбрәк дияргә була. Бүген алар барысы да бер максатка – туристлар агымын арттыруга эшли. Әйе, биредә авыл туризмы турында ишетеп кенә түгел, чынбарлыкта да яхшы беләләр. Алай гына да түгел, туристларның күпләп килүе авылны гына түгел, халык традицияләрен дә саклап-коткарып калачагына ышаналар. Берьюлы ике куянны атарга ниятлиләр, дисәк тә буладыр.

Ә барысы да мәзәктән башланган: нәкъ ун ел элек Иван Николаевич лошемобиль уйлап тапкан.

– Мин күрше авылда яшим. Анда барлыгы унсигез кеше генә калдык, – дип сөйләп китте ул миңа. – Эшкә йөрергә кирәк, машинаның ватылган чагы була. Менә иске машинадан атка җигә торган конструкция уйлап таптым шулай. Атны җигеп куям да чиста кәчтүм-чалбардан, галстук тагып матур гына эшкә барам – ни дисәң дә директор бит!

Лошемобиль фотографиясе, Интернетка эләгеп, Күклюкка туристлар сукмагы сала. Шуннан бирле йомгак тәгәри бирә! Немецлар һәм кытайлар, финнар һәм японнар – кемнәр генә килмәгән бирегә! Ә җирле Кулибин, авылдашларын куандырып һәм туристларны шаккатырып, яңадан-яңа әкәмәтләр ясый. Менә инде мәктәп янында, рәт-рәт булып, күчереп йөртә торган мунча, Убырлы карчык өе, бәдрәф һәм хәтта мобиль чыршы да утыра. Янәшәдә генә Күклюкның төп бизәге – «Мари ызбасы» Музей-йорты да урнашкан.

САЛАМ БАШЛЫ ЙОРТ

– Ә тегесе нәрсә? Ниндидер әкәмәт конструкция... – дип аптырап сорыйм, музейның салам түбәсен карый-карый.

– Таган ул! – дип көлә өлкән Мельников. – Җәен таган атынырга килегез.

Хәер, Күклюкта өй башындагы таганда атыну һәм лошемобильдә йөрүдән тыш та кызыклы нәрсәләр шактый. Туристлар өчен монда милли уеннарның тулы бер исемлеге төзелгән: әйтик, чабата һәм мари милли киемен киеп карау, кәрзин үрү, кәҗә саву һәм хәтта кара мунчада юынып-чабынып чыгу. Сүз уңаеннан, әнә ул ызбадан берничә адым ераклыкта гына тора.

– Мондый мунчада ис тимиме соң? – дим, кара төтенне йота-йота. Чабынып чыгарга кыймасам да, эченә кереп карамый түзмәдем.

– Соң аны төтен белән җылыталар да, – дип сөйли Николай. – Аннан соң күмерләрен алалар, төтенен куалыйлар. Эссесе кала! Мондый мунчалар безнең якларда еш очраган. Ә аларның савыктыру үзлекләре барыбызга да яхшы билгеле: үпкәләрне чистарта, тире авыруларын дәвалый...

Иске Күклюктагы мунчаны һәм мари ызбасын китаплар буенча түгел, әле ул заманнарны яхшы хәтерләгән авылдашлары сөйләве, аларның истәлекләре буенча яңартканнар.

– Мин үзем дә менә шундый йортта туып-үстем, – дип сөйли өлкән Мельников. – Күрәсезме, түбә астындагы сәндерәне – бу иң җылы урын, чөнки мичнең эссесе югарыга күтәрелә, ә менә мич белән өй стенасы арасына зәмһәрир суыкларда вак терлек-туарны да керткәлиләр иде.

Мин як-ягыма каранам. Минем кебек шәһәр кешесе өчен кысанрак тоела, билгеле, ә бит шундый өйләрдә кайчандыр өчәр буын бергә яшәгән. Озын эскәмияләр һәм өстәл, корама җәймә җәелгән киң карават, түбәгә эленгән бишек, ә аның янәшәсендә – кечкенә сәке һәм каба. Борынгы заманнарда хатын-кызлар кичләрне әнә шулай үткәргәннәр: аяклары белән бишек тирбәткәннәр,

«Мари ызбасы» Музей-йорты түбәсендәге таган.

Менә шундый өйләрдә кайчандыр өчәр буын бергә яшәгән.

«Изике, ичык» – чыра тоткычы.

шунда ук җеп тә эрләнгән, бишек көйләре дә көйләнгән.

– Ә монысы нәрсә? – дип, хәйләкәр генә сорап куя Иван Мельников, миңа зур гына, ләкин инде күгәрергә өлгергән тимер «ук» сузып. – Серен бераз чишәм: хуҗалыкта иң кирәкле әйбер!

Фотографыбыз белән тырыша-тырыша уйлыйбыз, нәтиҗәдә бирeләбез. Чыра тоткычы икән. Мари халкында «изике, ичык» дип атала. Элек тоткычның очлы ягын стенага керткәннәр, ә икенче ягына нараттан яисә пихтадан нәзек чыра беркеткәннәр, ә аска – күмер өчен – сулы савыт куйганнар.

Мари ызбасы стеналарын бизәкле ак сөлгеләр бизи, өстәлдә самовыр утыра. Без кулдан тукылган палас өстендә басып торабыз. Әйтерсең лә, хуҗалар да янәшәбездә генә: гаилә башлыгы мичкә ягарга дип утынга гына чыккан, әни кеше хәзер яңа сауган кәҗә сөте алып керәчәк.

– Кытайлар кунакка килгән иде, – дип мактана Иван Николаевич. – Мунчада чабындырдык үзләрен, мичтә бәрәңге тәгәрәтеп ашаттык. «Караша! Караша!», – дип, исләре китте үзләренең.

ТЕЛ – ТӨМӘНГӘ ИЛТӘ

Поро кече! Марича «Хәерле иртә!» дигәнне аңлата. Ләкин авыл мәктәбенә без көн урталарына гына барып җитә алдык, шуңа күрә безнең өчен күбрәк башка сәламләү сүзләре туры килде: «Поро кас!» Монысына мин мәктәп коридорында ук өйрәнә башладым – стенага гади генә сүзлек төзеп элгәннәр. Сүз уңаеннан, Иске Күклюк авылында язу язылган элмәләр еш очрый: алар өч телдә – русча, татарча, марича.

– Без бу яктан Мари Элдан да алдарак барабыз! – дип шаярта өлкән Мельников. – Күргәч, исләре китте! Үзләрендә дә шулай эшләмәкчеләр.

Асылда, без мәктәпкә тагын бер музейны күрү өчен кердек. Ишек ачылып китә... һәм безне тагын халык җыр-биюләре белән каршы ала. Бу юлы «Ужара» фольклор төркеменең яшь артистлары икән.

– Без шулай итеп тел белүне ныгытабыз, – дип сөйли аларның

«Ужара» фольклор төркеменең яшь артистлары икән.

Татьяна Филиппова авыл балаларын мари теленә өйрәтә.

житәкчесе һәм мари теле укытучысы Татьяна Филиппова. – Мәдәниятка тартылу шуннан башлана да.

– Ә әти-әниләр – алар балаларын өйрәтми, таныштырмыймы?

– Чиста мари гаиләләре бездә дә аз калды инде – катнаш гаиләләр күп. Ата-анага ярдәмгә иң беренче балалар бакчасы килә, мари телен сабыйларга анда өйрәтә башлыйлар, аннан соң – мәктәптә. Без шул рәвешчә Алабуга муниципаль районында мари этномәдәни белем бирү программасын гамәлгә ашырабыз.

«Ужара» төркеменә йөри торган Ангелина еш кына сәхнәгә үзенең әнисе – безгә инде таныш Нина Ивановна белән чыга.

– Ә өйдә мари телендә аралашасызмы? – дип сорыйм алардан.

– Нигездә русча – безнең әтиебез татар, ләкин кызларның үз серләре була бит – монда инде безгә мари теле ярдәмгә килә, – дип көлә Нина. – Киявем – удмурт. Бөтенебез бергә аралашабыз! Бар кешене дә үз традицияләребез белән таныштырабыз.

Нина сәхнәдә еш кына кызы Ангелина белән чыгыш ясый.

«МУЗЕЙ» – ГОРУР ЯҢГЫРЫЙ

Мәктәпнең туган якны өйрәнү экспозициясе рәсми рәвештә музей дип атала – моны документлар да раслый: таныклыкны ишек янына ук элеп куйганнар. Ә яшь экскурсоводлар – Кирилл белән Эльза килгән кунакларны туган яклары турында дүрт телдә сөйләп шаккатырырга сәләтлеләр. Менә бүген дә, җирлек макетын күрсәтә-күрсәтә, Эльза мине Иске Куклюк авылы тарихы белән таныштыра.

Эльза экскурсияне дүрт телдә алып бара ала.

– Безнең авылга мари кешеләре әле XVII гасырда ук нигез салганнар. Алар бу якларга башта – Нократ елгасы, аннан Умәк елгасы буйлап йөзеп килгәннәр. Элек биредә үтеп булмаслык карурманнар һәм сазлыклар булган. Сүз уңаеннан, Куклюк «сазлыклар ягы» дип тәрҗемә ителә икән.

Эльза безгә авылларыннан ерак түгел генә Екатерина күпере (күпердән Әби-патша үзе узган, диләр) һәм Гражданнар сугышы чорыннан калган окоплар булуын да күрсәтә. Безгә шулай ук мари халкының төп бәйрәме – Семык турында гына түгел, ә бәлки күршеләренең милли бәйрәмнәре ничек үтүе хакында да сөйли. Мин аннан Питрауда Иске Куклюк халкының җыелышып күрше рус авылы Үмәккә баруын, Троицаны Олы Елово авылында бәйрәм итүләрен ишетәм, Сабантуйда Татар Дөм-Дөмендә күңел ачалар икән... Экскурсияне Кирилл дәвам итә, һәм без вакыт аралыгында сәяхәтебезне дәвам итәбез. Беренче эре экспонат – борынгы туку ыстаны.


«Әгәр кыз шушындый ыстанда тукый белмәсә, аны кияүгә алмаганнар!»

– Әгәр кыз шушындый ыстанда тукый белмәсә, аны кияүгә алмаганнар! – дип, җитди генә хәбәр итә миңа Кирилл.

Янәшәдәге зур стендта үтүк, мал муенына тага торган кыңгырау, чабаталар һәм балчык кувшиннар урын алган. «Мондый савытларда сөт әчүр көн әчемәгән. Суыткыч булмаган бит! Ә инде базда гомумән атна буе сакларга мөмкин булган», – дип сөйләвен дәвам итә экскурсоводыбыз.

– Шәхсән үземнең тарафтан тикшерелгән, – дип, аның сүзләрен раслап тора Иван Николаевич та.

Күргәзмә «чәй өстәлендә» самовыр утырып тора, карашым белән безнең өчен гадәти булган чәйне эзлим – юк, аның каравы өстәлдә – мелисса, мәтрүшкә, карлыган, дуләнә һәм мариларның яраткан гөлҗимешләре – кышка витамин запасын алар шулай әзерләгәннәр.

Мин әле музей буйлап шактый озак йөрдем. Кызыксынып, өйдә тукылган тукымаларны тотып карадым, Гражданнар сугышы вакытыннан калган раритетларга күз салдым, иске фотосурәтләргә карап сокландым...

– Дөресен әйтегез әле, бүген сезгә милли мәдәниятегезне саклап калу кыенмы? – дип сорыйм киткәндә директордан.

– Кыен, – ди ул җитдиләнеп. – Барысы да энтузиазмга гына нигезләнгән. Барысына да: «Тиздән үз телегезне югалтачаксыз бит!», – дим. Менә

Технология укытучысы Надежда Кузьмина – традицион мари чигешләре буенча чын белгеч.

мәктәп ябыла икән – бетә. Ул таяныч булып тора! Мәктәпне саклап каласы иде… Бүген бездә егерме бала укый. Икенче елга тагын алты бала укырга керәчәк, ә менә өлкәнрәк классларда – упкын. Шулай да алда зур перспективабыз бар кебек. Күрәсез бит бездә нинди кызыклы нәрсәләр бар!

КӨЧЛЕ ИР-АТ СИМВОЛЫ

– Мин бүген улым өчен сөлге чигәм. Ир-ат көчен саклый торганны. Бездә шундый традиция: армиягә җыенган егет кеше, сөлгесен иңенә салып, дусларын һәм туганнарын йөреп чыга…

Технология укытучысы Надежда Кузьмина – традицион мари чигешләре буенча чын белгеч. Үз осталыгын мәктәптә укучы кызларга тапшырырга тырыша, әмма һәркем дә моны булдырырга сәләтле түгел дип саный ул. Мин исә аның эшләрен игътибар белән карыйм һәм кул эшләренең матурлыгына шаккатам.

– Бу махсус мари җөе, – дип аңлата миңа Надежда. – Үзем дә ай-һай озак өйрәндем аны! Безнең чигешнең үз символлары бар. Чиста геометрия! Түгәрәкләр, почмаклар, шакмаклар – алар барысы да аерым мәгънәгә ия. Менә, мәсәлән, киң таралган бүрәнкә формасы йорттан җен-пәриләрне җыя…

Менә ул кулына «Ош Поро Кугу Юмо…» («Якты Игелекле Ак Ходай…») дигән язулы вымпелны алды. Сүз уңаеннан, борынгы заманнарда марилар табигать көчләренә табынганнар. Шушындый чигешләр белән дога кылырга җыелган җирләре – изге Кюсото агачлыгын бизәгәннәр. Иске Күклюкның өлкән кешеләре әле әбиләренең, корылыклы елларда яңгыр сорап, авылны гарасатлардан саклауларын ялварып, әйберләр китергәннәрен хәтерлиләр. Әле 2003 елда гына чыгышы белән Иске Күклюк кешесе Леонид Шабалин борынгы изге йолаларны торгызырга ярдәм иткән. Ул мариларның традицион диннәре каһине – җирле карт булып киткән.

– Безнең төп бурыч – яшьләрне үзебезнең барлык традицияләр белән таныштыру, – дип сөйли Николай. – Өстәл артында җыелганда көнбатыш көйләрне тыңлау түгел, үзебезнең милли җырларны җырларлык булсын иде.

– Ә бу хәзерге заманда аларга кирәкме соң? Глобальләшү укчагә баса – риза булып кабул итү җиңелрәк түгелме?

– Бер-беребездән бөтенләй аерылып тормас өченме? Үз тамырларыбызны җуяр, телебезне югалту өченме?! – дип кызып китә Мельниковларның кечесе, һәм мин шуны аңлыйм: юк, Күклюкта моңа юл куймаячаклар.

КАСПИЙ ДИҢГЕЗЕ БАШЛАНГЫЧЫ

Иске Күклюкта барлыгы биш йөзгә якын кеше теркәлгән, ә чынлыкта ике йөздән бераз артыграк кеше яши. Өй арты өйне узабыз. Буш йортлар да аз түгел…

– Яшьләр институтларга керә, шәһәргә ияләшә һәм авылга әйләнеп кайтмый, – дип уфтана Николай.

– Ә сезгә үзегезгә күңелсез түгелме монда?

– Миңамы? – дип гаҗәпләнә ул көтелмәгән сорауга. – Юк! Мин авылда яшим, ләкин бу миңа актив тормыш алып барырга, республика яшьләр форумнарында катнашырга комачауламый.

Ул безне үзе яшәгән күрше Черкас авылына алып китә. Капка төбендә эт көтә, янәшәдә лошемобиль тора…

– Әнә теге күрше йорт та безнеке. Авыл туризмы өчен сатып алдык. Узган елны беренче туристларны кабул иттек. Тагын бер йортны арендага алырга телибез – анда кечкенә генә авыл кунакханәсе ясарга ниятлибез. 2016 елда Иске Күклюк һәм Черкаска 500дән артык кеше килеп киткән.

Ерак түгел генә табыну хачы тора. Без әле эреп бетмәгән кар көртләрен аралап чишмәгә төшәбез. Чиста суда кулларыбызны юабыз. Бирегә диңгез – Каспий диңгезе башлангыч ала икән. Һәрхәлдә, Мельниковлар шулай дип раслый.

– Минем тагын бер идея бар – бирегә кәнәфи ясап кую. Килгән туристлар утырып, теләкләрен теләсеннәр, – дип елмая Николай. – Кыскасы, фикер кирәкле юнәлештә хәрәкәт итә!



PRESSA.RU

IT-БУЫН

Мәгълүмати технологияләрне кешелекне серле киләчәккә алып бара торган ашкынулы агым белән чагыштырып була. Без әлеге агымны буйсындырырга тиешле яшьләрнең ничек ярышуын һәм камилләшүен күрдек.

Автор:
Ксения Сёмина

АДМИН ӨЧЕН ТОЗАК

Икенче бөтендөнья сугышы вакытында легендар Блетчли-парк – Британиянең шифровкалау баш подразделениесе хезмәткәрләре фашист командованиесенең хәбәрләрен укый алучы машина уйлап табуга берничә ел сарыф иткән. Бу кешеләр 77 елдан соң үзләре сугыш елларында шифрлаган һәм шифрын ачкан барлык мәгълүматны 20 яшьлек техникум студентлары берничә секунд эчендә эшкәртер, дип фаразлый алдымы икән?

Әмма Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы аудиторияләренең берсендә уза торган WorldSkills-2017 Бөтенроссия сайлап алу ярышларында хәзер нәкъ менә шуның белән шөгыльләнәләр дә инде.

– Күз алдыгызга китерегез: сез үзегезнең коммерция буенча партнерыгызга әле генә үзегез уйлап тапкан ноу-хауны сурәтләгән хат җибәрәсез, ди. Ул сезнең көндәшләр кулына эләгә – һәм проект юкка чыгу куркынычы алдында кала, – дип сөйли «Челтәрле һәм системалы идарә итү» компетенциясе мәйданчыгы буенча белгеч Денис Букин. – Безнең компетенция кысаларындагы биремнәрнең берсе буенча, челтәр җиһазларын көйләүче яшьләр андагы мәгълүматларны шифрлау мөмкинлеген оештыра, һәм аларны кемдер кулга төшергән очракта да шифрны ачу, уку өчен еллар таләп ителәчәк.

Мәгълүматларны шифрлау – бәйгедә катнашучылар «Челтәрле һәм системалы идарә итү» компетенциясендә башкарырга тиешле эшнең кечкенә «өлеше» генә.

Фото: Ната Смирнова





– Бирем өч төп өлешкә бүленгән. Беренчесе челтәр җиһазлары белән эшкә карый. Конкурста катнашучыларга виртуаль предприятие һәм аның ике офисы бирелә, аларны үзара бәйләргә һәм алар арасында мәгълүмат алмашу өчен барлык челтәр инфраструктурасын оештырырга, әлеге челтәрне сакларга, анда кулланучыларга кирәк урынын булдырырга һәм аларга тиешле хокукларын бирергә кирәк, – дип сөйли Денис Александрович. – Икенче өлеш Windows операцион системасын көйләүгә багышланган. Мәгълүм булганча, компания хезмәткәрләренең барлык тышкы коммуникацияләре – электрон почта җибәрү, интернетка чыгу һ.б. – аның аша эшләнә. Өченче өлеш компьютерлы эш урыннары яки предприятиенең санлы җиһазлары белән идарә итү өчен кирәк булган Linux операцион системасын көйләүгә кагыла. Төбәк чемпионатыннан аермалы буларак, һәр блокка нибары өчәр сәгать вакыт бирелә, һәм бу конкурсантлар өчен үзенә бер тозак булып тора. Барысы да катгый тайминг кысаларына сыешырмы? Сүз уңаеннан, бу яшьләрнең күпчелеге – инде тәмам җитлеккән диярлек югары дәрәҗәле һөнәрмәнд, күбесе шул белгечлек буенча эшлидер, дип уйлыйм.

«Челтәрле һәм системалы идарә итү» компетенциясе – иң күп санлылардан берсе. Аудиториядә егермеләп кеше эшли, алар – үз төбәк этапларында җиңгән Россия техникум һәм колледжлары студентлары. Һәм бу – барлык катнашучыларның яртысы гына. Икенче төркем тәнәфестән соң киләчәк, таймер күрсәтүенчә, билгеләнгән вакыт бетәргә инде 8 минут кына калган.

Монитор, клавиатура һәм маршрутизаторның кара тартмасы торган өстәлдән конкурсантларның берсе читкәрәк тайпыла һәм, уйчанланып, экрандагы мәгълүматны өйрәнә. Таймер туктаганнан соң, мин аның янына килеп сорашам.

– Моннан җиде ай элек мин бу белгечлекне үзләштерә башладым гына әле, – дип сөйли Илья Серов. «Мәгълүмати системалар» белгечлеген ул Әлмәт политехника техникумында ала. Казанда февраль башында үткән төбәк чемпионатында Илья 500 баллы бәяләү системасы буенча 528 балл җыйган. – Әлегә мин кайсы белгечлекне һөнәр итеп сайлаячагымны хәл итмәдем. Ничек булса да, мин, эшләгән эшеңне ярат һәм аны бик яхшы итеп башкар, дигән принцип буенча яшим.

PRESSA.RU

КМТЭТ данын яклаучы конкурсант, төбәк чемпионаты җиңүчесе Виталий Осокин.

Март уртасында WorldSkills-2017 Бөтенроссия сайлап алу ярышлары үткәрелде, аның нәтиҗәләре буенча май аенда Краснодарда узачак WorldSkills Russia «Яшь профессионаллар» V Милли чемпионатының финалында катнашучылар ачыклана. Сайлап алу ярышлары РФнең 7 шәһәре мәйданчыкларында, шул исәптән Казанда, Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы (КМТЭТ) территориясендә дә уздырылды. 2015 елның декабрендә техникум базасында мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләр тармагында Төбәкара компетенцияләр үзәге (ТКҮ) төзелде. Биредә ачылган полигонда 2016 елның ноябреннән бирле WorldSkills Russia милли җыелмасында катнашучыларның «Мобиль роботлар техникасы», «Веб-эшкәртү», «Мәгълүмати кабель челтәрләре» компетенцияләре буенча күнекмәләре үтә. Татарстан мәгълүмат тармагының әйдәп баручы предприятиеләре ярдәмендә ТКҮ WorldSkills Russia чемпионатлары кысаларында ярышлар оештыра һәм үткәрә. ТКҮ-КМТЭТ мәйданчыгында 23–28 мартта «Мәгълүмати кабель челтәрләре», «Бизнес өчен ИТ-программалы чишелешләр», «Веб-эшкәртү», «CAD инженерлык дизайны», «Челтәрле һәм системалы идарә итү» компетенцияләре буенча үткәрелгән WorldSkills-2017 Бөтенроссия сайлап алу ярышларында Россиянең 62 төбәгеннән 133 конкурсант һәм 148 эксперт катнашты.

МӘГЪЛҮМАТ – ЯКТЫЛЫК, НУР!

Эчендә оптик җепселләр булган үткәргечләр бәйләме конкурсант кулында мәкерле һәм ерткыч гидрадай боргалана. Бернечә минутлык көрәштән соң егет көндәшен җиңә һәм аны махсус металл әрҗәгә – кросска салып куя. Читтәрәк торган өстәлләрдә – кичәге «сугышның» нәтиҗәләре. Миңа Казан Кадрларны һөнәри әзерләү үзәге директоры һәм WorldSkills-2017 Бөтенроссия сайлап алу ярышларында «Мәгълүмати кабель челтәрләре» компетенциясендә катнашучыларның судьясы Руслан Гәрәев аңлатуынча, ярышның беренче көнендә конкурсантлар кеше чәче юанлыгындагы оптик җепселне эретеп ябыштырудагы күнекмәләрен күрсәткән. Әмма башта аны кабельне «сүтеп» эчтән тартып алырга, ягъни башта аның тышлыгын, аннары изоляциясен, аннары бакыр бронясын һ.б. салдырырга кирәк булган.

– Компетенция биргән тасвирлама буенча, кабель ул – мәгълүмат тапшыру өчен чара. Кулланучы, ягъни чынбарлыкта сезнең белән без, алачак мәгълүматның сыйфаты конкурсантның аны никадәр оста итеп «эшкәртүенә» һәм сузуына бәйле, – дип төшендерә Руслан Госман улы. – Оптик җепсел – мәгълүматны яктылык импульслары рәвешендә тапшыруның иң заманча һәм нәтиҗәле коралы. Шул ук вакытта ул бик уалучан да. Оптик җепсел белән эшләү бик зур игътибар һәм пөхтәлек сорый. Моннан тыш, аның саксыз эретеп ябыштырганда барлыкка килгән механик кимчелекләре тапшырыла торган мәгълүматның тизлеген һәм күләмен киметә. Әлеге тизлекне үлчәп, без конкурсантка йә баллар өстибез, яки, киресенчә, балларын киметәбез.

КМТЭТ мәйданчыгында үтә торган ярышларда «Мәгълүмати кабель челтәрләре» компетенциясендә нибары алты конкурсант ярыша.

Миңа экспертлар аңлатуынча, бу специфик компетенция, аңа әзерләнер өчен тулы бер «полигон» кирәк. «Күпканаллы телекоммуникация системалары» һәм «Элемтә челтәрләре һәм коммутация системалары» юнәлешләрендә белгечләр әзерли торган Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумында барлык кирәкле ресурслар да бар.

– Бирем биш модульдән тора, аларның кайберләрендә «кара тартмалар» – сюрпризлы биремнәр бар, аларны үтәү өчен конкурсантка тапкырлыгын күрсәтергә кирәк булачак. Гомумән, мәйданчыктагы эшне планлаштыру һәм оптимальләштерү күнекмәләре күрсәткән өчен өстәмә баллар бирелә, – ди Руслан Гәрәев. – Ә инде техника куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуны – перчаткасыз эшләү, күзлексез эретеп-ябыштыру һ.б. – теркәсәк, баллар киметелә. Шул рәвешле, яшь белгечләрдә үз эшләрен төгәл үтәү алгоритмы формалаштырыла.

– Биредә һәр хәрәкәт исәпләнгән һәм җитештерү зарурлыгы белән акланган булырга тиеш. Ярышларга әзерләнгәндә, без бу компетенция буенча WorldSkills стандартларын өйрәндек. Оптик җепселле элемтә монтажлауның бүген киң таралган практикасыннан аермалы буларак, алар бик югары таләпләр куя, – ди КМТЭТ данын яклаучы конкурсант, төбәк чемпионаты җиңүчесе 19 яшьлек Виталий Осокин. Ул WorldSkills Russia милли җыелмасы составына керә, запастагы катнашучы булып Әбу-Дабидагы чемпионатка барачак һәм 2019 елда Казанда үтәчәк WorldSkills чемпионатында төп катнашучы буларак чыгыш ясаячак.

Виталийның иманы камил: әлеге һөнәрнең киләчәге бар.

– Без әле интернетның телефон линиясе буенча – максималь тизлеге секундына 10 Мбит булган коаксиаль кабель аша тоташтырылган вакытларны хәтерлибез. Бүген исә оптика абонентка секундына 100 мегабит җиткерү мөмкинлеге бирә! – ди ул. – WorldSkills ярышлары заманнан калышмаска, бу юнәлештә башка илләрнең ничек үсүен күрергә булыша. Моннан тыш, үзебез «чыгыш ясаган» җиһазларны без шул ук вакытта тикшерәбез дә. Моны республика мәгълүматлаштыру тармагының әйдәп баручы предприятиеләре контрольдә тота һәм аннары шундый ук җиһазларны киң куллану өчен дә сатып ала.

КЕМ КЕМНЕ КИРЕ КОДКА САЛА

Бер егет 2017 елның маенда Краснодарда уздырылачак WorldSkills Russia «Яшь профессионаллар» V Милли чемпионаты финал ярышларын оештыру һәм үткәрү өчен программа эшләнешенә техник биремне өйрәнә. Үзенең бу финалда беренчелек өчен көрәшүчеләр арасында булу-булмавы аның әлеге программа продуктын ничек әзерләвенә бәйле.

– Бирем мөмкин кадәр гамәли булсын өчен, анда тормыштан алынган мисаллар файдаланыла. Бу мәйданчыкта конкурсантка чемпионатны оештыручылар өчен программа төзергә тәкъдим ителә, анда әлеге чарадагы бөтен кеше – судьялар да, волонтерлар да, катнашучылар да теркәлергә тиеш, – дип аңлата «Бизнес өчен программа чишелешләре» компетенциясе мәйданчыгында барган хәлләрнең асылын аның Татарстандагы баш эксперты һәм шул ук компетенция буенча WorldSkills Russia милли җыелмасы тренеры Эмиль Сабитов. – Һәр төркемнең үз критерийлары бар, алар да программага кертелергә тиеш. Ягъни, конкурсант программаның кодын гына язып калмый, бәлки аны төрле мәгълүмат базалары белән бәйли һәм аның өчен үзенә бирелгән брендбук стилендәге интерфейс эшли.

– Биремне утәүнең соңгы этапларыннан берсендә бәйгедә катнашучылар үз программаларының презентациясен эшләргә тиеш. Әмма ул гади слайдлар җыелмасы түгел, төп продукт белән эшкә тәфсилле күрсәтмә дә булган мини-программа булырга тиеш, – дип сөйли Эмиль Рәшит улы. – Шул рәвешле, конкурсант программа белән тәэмин итү эшләнмәләренең төрле сфераларын үзләштерә һәм әкренләп универсаль белгечкә әйләнә. Төбәк этабында шул ук компетенциягә тагын бер бирем – заказчы белән аралашу да кертелгән иде. Хәзер күп программист фрилансер булырга омтыла, һәм аларның базарда «исән калуы» клиентны тыңлый белү, аның ихтыяҗларын аңлап, продукт төзегәндә аларны исәпкә алу сәләтенә бәйле.

Эксперт фикеренчә, колледж һәм техникум студентларының WorldSkills чемпионатларында катнашуы аларның үз күнекмәләрен генә шомартып калмый, бәлки IT өлкәсендә белем бирү үсешенә дә уңай йогынты ясый.

– Кызганычка, программистлар һәм мәгълүмат тармагының башка белгечләрен әзерләүче уку йортларының күпчелеге теориягә басым ясый. Ә бит инде базар бик нык алга китте, һәм бүген, көндәшлеккә сәләтле булып калыр өчен, айтишник даими камилләшергә һәм күп төрле гамәли күнекмәләрне үзләштерергә тиеш, – ди Эмиль Сабитов. – Белүемчә, IT белән бәйле WorldSkills компетенцияләре буенча баш милли экспертлар хәзер югары һәм махсус-урта уку йортлары студентлары өчен актуальләштерелгән мәгариф программалары төзи. Аларны кертү вуз һәм техникум тәмамлаучы айтишникларның эш белән мәшгульлеген арттырыр, дип өметләнәм. Кызганыч ки, хәзер аларның бик азы гына чын эшкә әзер.

– Мин программалаштырырга яратам, һәм күп нәрсәне үзлектән өйрәнәм. WorldSkills чемпионатында катнашу ул – барыннан да элек, тизлеккә ярышу. Өстенлек шунда – син эшнең ахыргы нәтиҗәсен генә күрсәтәсең, шунлыктан экспериментлар ясарга була, – ди Данир Хәбибуллин, Әлмәт политехника техникумының «Мәгълүмати системалар» белгечлеге буенча 3 курс студенты. – Әмма ярыш барышында без интернетка керә һәм андагы мәгълүматларның кодларын файдалана алмадык. Чынбарлыкта шартлар гадирәк. Киләчәктә нинди юнәлешне үзләштерәсемне төгәл белмим әле. Минемчә, хәзер программалар төзүгә караганда интернет-ресурслар эшләүгә ихтыяҗ зуррак. Әмма, әлбәттә, мөмкинлек булганда, мин WorldSkills стандарты буенча ярышларда катнашуымны дәвам итәчәкмен. Чемпионат биремнәрен мин үз-үземне сынау дип кабул итәм.

PRESSA.RU



КАЙГЫҢНЫ ҮЗЕҢ ГЕНӘ ЙОТМА!

Аяныч статистика: югалган кешеләр яз аенда күбрәк табыла. Тагын бер үзенчәлек: яз, көз айларында югалучылар саны арта. Бу ике хакыйкать арасында нинди бәйләнеш бар? Кеше ни сәбәпле, кайсы очракта өйдән чыгып китә? Һәм кая бара алар?

Автор:
Руфия Фазылова

УРМАНГА, ЙӘ КЫРГА КИТКӘНДӘР, ДИБЕЗ

Республикада көн саен бер кеше югала. Сәбәпләре төрле: өйдәге конфликтлар, акча эшләргә дип чыгып китү, җинаять корбанына әйләнү, спиртлы эчемлекләр куллану, төрле күңелсез хәлләргә юлыгу, сектага әләгү, акылны югалту һәм башкалар. Минзәлә районы Түбән Тәкермән авылында яшәүче 1939 елгы Миннәхмәт Баһаутдинов соңгы очракка карый. Альцгеймер чиреннән җәфаланган (гадәттә ул өлкәннәрдә очрый, кеше хәтерен югалта, вакыт аралыгында бутала башлый) бабай 6 март көнне югалган. Миннәхмәт абый өстенә бушлат, башына бүрек, аягына галош киеп, иртәнге биш-алтылар тирәсендә өеннән чыгып киткән. Үзе белән бер документ та, акча да алмаган. Элегрәк тә шулай югалгалып торган булган, балалары берничә тапкыр авылның читеннән табып алып кайткалаган үзен.

– Дәү әти югалганга ике атна узды, – дип сөйләде март урталарында Миннәхмәт абыйның оныгы Йолдыз Гобәйдуллина. – Элек алар урманда яшәп алганнар, шунда чыгып киткәндер, дип уйлыйбыз. Эзләмәгән җир калмады, «снегоход»лар белән якын урман тирәләренә дә бардылар, аяк эзләре күренми. Полициягә хәбәр иткәч, этләр белән дә килделәр, очына чыга алмадылар. Аның кешегә керә торган гадәте юк иде. Урман-кыр тирәсенә киткәндер, дибез.

Миннәхмәт абыйның улы, ике кызы бар. 57 ел тормыш иптәше Рәйсә апа белән яшәгән. Тик гомер иткән хатыны өч ел элек вафат булган, бу югалтуны бабай бик авыр кичергән. Аннан улы Нияз гаиләсендә тәрбияләнгән.

– Дәү әти белән шундый хәл булгач, әнинең йокысы качты, – ди Йолдыз. – Дәү әнинең вафатын Нияз абый да бик авыр кичергән иде, тынычланып кына килгәндә, менә тагын зур сынау. Дәү әтиебезнең исән икәнлегенә ышаныч көннән-көн кимесә дә, күңел һаман могҗиза көтә! Табылыр, бәлки, берәр җирдә адашып кына йөридер. Без инде Чаллыга барып, сукбайлар арасыннан да эзләп карадык аны. Тик күрүче булмаган.

Көн аралаш Миннәхмәт абыйның хәле белән кызыксынып тордым. Хәбәр һаман да юк. 26 март көнне иртәнге якта Йолдыз язып җибәрде: «Могҗиза булмады: дәү әтине таптык, ташландык фермалар янында басуда яткан...» 27 мартта Миннәхмәт бабайны җирләделәр. Хәле бетеп егылганмы, йөрәге туктаганмы – бабайны кар күмеп киткән булган.

Яз көне табылган кешеләр исемлеге менә шундый очраклар хисабына арта. Көзен урманга дип чыгып киткән гөмбәчеләр, карлы юлда адашып калган юлаучылар – барысы да кар эрегәч «пәйда» була.

«СӨЙЛӘМЕ АҢЛАШЫЛМЫЙ ИДЕ»

Миннәхмәт абый югалган вакытта Буа районының Казма авылында Илназ Шибаевны да эзләделәр. 14 яшьлек үсмер малай икенче төркем инвалид, акыл үсешендә тоткарлыклар булган. Тирә-юньне карап чыкканннан соң, тикшерүчеләр, үсмер малайны Зөя елгасыннан эзләргә кирәк дигән нәтиҗәгә килләр. Казма авылы Зөягә терәлеп үк тора. Җитмәсә, Илназның елгага таба баруын да күрүчеләр булган, аяк эзләре дә бар.

– Илназ югалган көн – 15 марттан бирле авыл халкы хафага төште, – дип сөйләде Казма авылы мәдәният йорты мөдире Гөлфия Гыйниятуллина. – Гаиләдә биш бала алар, Илназ – иң төпчеге. Әнисе Гөлшат, әтисе Илгизәр исемле. Алар элек читтә яшәделәр, күп балалы гаилә ике ел элек Гөлшатның әти-әнисе нигезенә кайтып төпләнде. Илназның сөйләме бик аңлашылып бетми, үзе болай ачык күңелле, бөтен кешегә елмаеп карый иде.

Югалган үсмер Буа шәһәрендәге Мулланур Вахитов исемендәге гимназиянең коррекцион сыйныфында укыган. Илназ, гадәттә, авылга атна азагында гына кайта торган булган. Ә бу юлы, язмышмы-ялгышмы, Гөлшат ханым улын атна уртасында үзе белән Казмага алып кайтып китә.

– Эшләрем белән Буага барган идем, – дип искә алды ул көнне Гөлшат Шибаева. – Улым: «Авылга китик», – дип бик сорады. Мин аны элек тә шулай берничә тапкыр алып киткәнем булды. Аннан иртән мәктәп автобусына утыртып җибәрә идем. Өйдә кайтып чәйләр эчкәч, урамга чыгып китте. Аның шулай йөреп керә торган гадәте бар иде. Кичке бишләрдә күренмәгәч, борчылып эзли башладым. Күршеләр, авылдашлардан сораштык, тик улым беркайда да күренмәде...

Илназ элек Зөя елгасына якын бармаган, судан курка торган гадәте булган. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, малайны җирдән эзләгәннәр. Берәр машинага утырып китмәдеме, дип тә уйлаганнар, чөнки Илназ абыйсы белән күрше авылга кибеткә йөргәләгән. Юлда очраган машинага утырып, кире үз авылларына кайткалаганнар.

Бүген Илназны водолазлар көн-төн диярлек Зөя елгасыннан эзли. Көннәр җылы тору сәбәпле, март аенда ук боз катламы калын булмаган. Шуңа күрә үсмер малай суга төшеп киткән, дигән фараз бар.

«ТӘҮЛЕК УЗГАННЫ КӨТМӘГЕЗ!»

Илназ Шибаев кебек өеннән чыгып китүче үсмерләр саны узган ел 377 булган, сүз 18 яше тулмаган малай-кызлар турында бара. Бу яшьтәге гражданнарга игътибар аеруча зур.

PRESSA.RU

– Бала, үсмер югалу турында хәбәр булуга, тиз арада бөтен бүлекләрне аякка бастырабыз, – дип сөйләде ТР Эчке эшләр министрлыгының кешеләрне эзләүне координацияләү бүлеге җитәкчесе урынбасары Альберт Йосыпов. – Олылар белән хәл икенчерәк, кемдер хатынынан, иреннән яки кредит бурычларынан качып йөрергә мөмкин. Ә балигъ булмаган бала тик торганнан гына юкка чыкмый, иң мөһиме – ул үзен яклый алмый. Өлкән яшьтәге кешеләр белән дә шул ук хәл, ул акылга җиңеләергә, хәтерен югалтырга мөмкин. Тәҗрибә күрсәткәнчә, Эчке эшләр министрлыгына кеше югалу турында хәбәрне тизрәк хәбәр иткән саен, аны исән-имин табу мөмкинлеге зуррак. **Халык арасында шундый фикер яши: кеше югалганнан соң гаризаны 1-3 тәүлек узгач кына алалар. Ләкин бу дөреслеккә туры килми. Күңелдә шик бар икән, якыннары юкка чыкканга берничә сәгать кенә узса да, кичекмәстән полиция бүлегенә барырга кирәк.** Тәүлек узганны көтсәң, берәр бәхетсезлек очрагы килеп чыгарга да мөмкин. Безнең тәҗрибәдә андый мисаллар күп.

ТР Эчке эшләр министрлыгына караган әлеге бүлектә мисаллар чынлап та күп. Әлмәт районында көздән бирле бер ханымны эзләгәннәр. Дачасына дип чыгып киткән булган. Һәм күптән түгел генә табылган: нәкъ менә дачага бара торган юл өстендә яткан. «Кыш көне кар чистартканда ничек гәүдәсен трактор измәгән», – дип гаҗәпләнгән тикшерүчеләр. Ә 2010 елда югалган егет узган ел пәйда булган. Баксаң, кредитларыннан качу өчен, машинасында кан эзләре калдырып юкка чыккан. Шул рәвешле үзен «үтергәч», егет алты ел Мәскәүдә яшәгән, эшләгән, яңа дуслар тапкан. Якыннары алты ел ут йотып яшәгән. Ә алты елдан соң, бер нәрсә булмагандай, кайтып төшкән. Хәзер «яңадан туган» егеткә, кредитларын түләмәгән өчен, суд юлын таптарга туры килмәгәе.

– Балаларны, кешеләрне әгъзаларга сату, «кара базар» турында еш сөйлиләр. Татарстанда мондый хәлнең булганы бармы? – дип сорыйм Альберт Әкрамовичтан.

– Әйе, халык арасында андый имеш-мимешләр йөри. Әле кайчан гына Казанның бер сәүдә үзәгендә баланы урлап, бер бөерен алып, кире китереп куйганнар икән, дип сөйләделәр. Болар дөреслеккә туры килми. Һәрхәлдә, ТР Эчке эшләр министрлыгына бер генә ата-ана да килмәде, бер гариза да кермәде. Бездә кешене әгъзаларга сату очраклары юк, ишетергә дә язмасын.

«ЭФИРДА БӘХЕТЛЕ ОЧРАКЛАРНЫ ГЫНА КҮРСӘТӘЛӘР»

Илгизәр Шәрәфетдинов – «Жди меня» тапшыруының ирекле ярдәмчесе, Казандагы вәкиле дисәм дә, дөрес булыр. Уналты ел эчендә 1700ләп кешегә якыннары белән табышырга, кавышырга ярдәм иткән. Аны белгән кешеләр минем белән килешер: гаҗәеп ачык, яхшы күңелле кеше ул.

– «Жди меня» тапшыруын эфирга чыга башлаган көннәрдән үк бик кызыксынып карап бара идем. 2000 елда Мәскәүгә хат яздым: «Амур өлкәсендә яшим. Бәлки, безнең яклардан да берәрсен эзлиләрдер...» Озак та үтмәде, тапшыруның продюсеры Сергей Кушнеревтан җавап хаты килде. Амур өлкәсе буенча югалган дип саналган утызлап кеше теркәлгән исемлекне җибәрде. Бер атна дигәндә, шуларның унга якынын таптым. Бу эшкә бер кереп киткәч, кире чыгып булмый икән. Һәр көнне эштән кайткач, компьютер каршысына утыра идем. Интернет булмаган авылларга исә телефоннан шалтыраттым.

2001 елда Илгизәр абый туган ягына – Казанга кайта. Амур өлкәсендә башлаган эшен Татарстанда да дәвам итә. Быел гына йөзләп кешене тапкан. География киң: Украина, Казахстан, Белоруссия... Сугыш чорында югалучылар, 1960–1970 нче елларда союздаш республикаларга бәхет эзләп чыгып китүчеләрнең туганнарыннан мөрәҗәгатьләр бик күп икән. Ата-аналары, абый-сеңелләрен эзләүчеләр дә шактый.

– Төрле очраклар бар, – ди Илгизәр Шәрәфетдинов. – Сәрхүш, кешелектән чыккан атаны күреп: «Бу балага әтисен табу кирәк идеме соң?» – дип тә уйлап куясың. Тагын икенче төрле аяныч язмышлар да бар: улы яки кызы әтисен эзли, ләкин аның инде икенче гаиләсе бар. Очрашу иргә кирәк түгел, чөнки теге бала очраклы гына туган, бу хакта законлы хатыны белергә тиеш булмаган... Әйе, төрле язмышлар бар. «Жди меня» тапшыруының эфирында исә, гадәттә, азагы бәхетле тәмамланган очракларны гына күрсәтәләр. Күп нәрсә кадр артында да кала.

ЮГАЛМАГЫЗ...

Кеше югалу якыннары өчен бик зур фаҗига. Бигрәк тә сүз балалар, өлкәннәр турында барганда. Казан шәһәренең 18 нче дәваханәсенең клиник психоло-

гы Миләүшә Хисмәтуллина әйтүенчә, үсмер бер тапкыр өеннән чыгып китә икән, хәвефләнергә урын бар, тиз арада чарасын күрергә кирәк. Ата-ана баласы белән вакытында сөйләшеп, проблеманың асылына төшенми икән, бу тагын кабатланачак, дигән сүз. Үсмер тик торганнан гына өеннән чыгып китми, димәк, олылар күрми яки аңламый торган җитди сәбәпләр бар. Иң беренче ата-ана үзе өчен ул сәбәпләрне күрергә, аңларга тиеш. Әгәр бала белән өлкән кеше уртак тел таба алмый икән, психологларга мөрәҗәгать итәргә кирәк.

«Өлкәннәр югалган очракта, җавапсызлык, эгоизм турында сүз бара», – ди психологлар. Кешеләр төп ике сәбәп белән юкка чыга: эшкә дип яки берәр кешедән, проблемадан кача. Беренчеләре, эшләре барып чыкмаса, туганнарыннан оялып, кыенсынып, якыннары белән элемтәгә керми башлый. «Хәлләрем әйбәтләнгәч шалтыратырмын», – дип уйлыйлар. Ә хәле беркайчан да яхшырмаска мөмкин. Шулай итеп, кеше акрынлап үзен үзе упкынга этәрә: туганнары белән элемтәне югалта, ярдәм кулы сузучысы да калмый. «Якыннарыннан качу очраклары еш кына законлы ир белән хатынга кагыла», – дип аңлаттылар ТР Эчке эшләр министрлыгында. Хәл, гадәттә, болай килеп чыга икән: бергә яшисе килмичә, ир яки хатын өеннән китә. Хәләле кайтмагач, икенчесе аны эзләп, полициягә хәбәр итә. Тиз арада шул ачыклана: ирнең (хатынның) гаиләсенә кайтасы килми. Мондый очракта тикшерүчеләр, гариза язган кешегә ире яки хатынының исән икәнлеген генә әйтә алалар. Гражданин үзе ризалык бирмәсә, полиция хезмәткәрләре, законлы иренә (хатынына) да аның кайдалыгын әйтә алмый, законда шулай каралган. ◘

Якыннарын эзләүчеләргә Илгизәр Шәрәфетдинов киңәшләре

- Иң беренче эш итеп Федераль миграция хезмәтенең ТР буенча Идарәсенә барыгыз. Ике арадагы туганлыкны раслаучы белешмә алыгыз;
- әгәр сез туганыгыз, танышыгызның элеккеге эш урыннарын беләсез икән, архивтан шул оешманың документларын соратып алыгыз. Шул рәвешле аның гаиләсе, балалары турында өстәмә мәгълүмат белә алачаксыз;
- әгәр хатын-кызны эзлисез икән, ЗАГС идарәсенә барып, фамилиясе алышынганмы, юкмы икәнен тикшерегез;
- якыныгызның кайсы авылда туганлыгын белсәгез, җирле үзидарә советларына мөрәҗәгать итегез. Аларның адреслары Интернетта бар;
- сез эзләгән кешенең конкрет укыган, яшәгән елларын белсәгез, танышларын социаль челтәрләр аркылы эзләгез.

Сергей Королев, ТР Эчке эшләр министрлыгының кешеләрне эзләүне координацияләү бүлеге җитәкче:

– Кайчак полиция хезмәткәрләренә: «Берни дә эшләмисез», – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Ләкин безгә эзләү ысулларын ачарга ярамый. Кешене тапмыйча мәгълүмат та бирә алмыйбыз, «таптык» яки «тапмадык» дип кенә җавап бирергә туры килә. Югалган кешеләрнең 90 проценты санаулы көннәр эчендә табыла. Калган 10 процентын эзләү озак елларга да сузылырга мөмкин. Күп очракта соңгылары җинаять корбанына әйләнгән була.

Конкрет саннарга килсәк, 2016 елда ТР Эчке эшләр министрлыгына 4 мең 413 гариза керде. Югалучыларның 377се балигълык яшенә җитмәгән балалар. 1 апрельгә әлеге 4 меңнән артык кешенең 46сының язмышы билгесез. Мөгаен, карлар эреп беткәч, сулыклар ачылгач, аларның шактые табылыр. Сүз мәетләр турында бара.

2017 елның беренче кварталында якыннарын эзләүче кешеләрдән 901 гариза керде, 1 апрельгә шуларның 853е табылды.

PRESSA.RU

ЭКОЛОГИЯГӘ КЕРТЕМ – КИЛӘЧӘККӘ ИНВЕСТИЦИЯ УЛ

2017 ел Россиядә Экология елы дип игълан ителде. Моңа кадәр РФ Президенты Владимир Путин аны аеруча саклана торган табигый территорияләр елы буларак билгеләгән иде инде. Татарстанда әлеге вакыт аралыгында җәмәгать урыннарына да махсус игътибар бирү планлаштырыла.

Экология темасы яңа түгел һәм бүген гаять популяр. «Кибернетиканың әткәсе» дигән исем йөртүче күренекле Америка математигы Винер Норберт кайчандыр бик төгәл билгеләгән булган: «Без үзебез яши торган тирәлекне шулкадәр үзгәрттек ки, хәзер аңарда яши алыр өчен, үзебезгә дә үзгәрергә кирәк булачак». Һәр кешегә һәм, гомумән, җәмгыятькә дә.

Сүз уңаеннан, 2013 ел да әйләнә-тирә мохитне саклау химаясе астында узган иде. 2015–2016 еллар исә республикабызда парклар һәм скверлар, су саклау зоналары елы булды. Никадәр яңа парк һәм сквер пәйда булды – аларны ел дәвамында төзеделәр, искеләрен тәртипкә китерделәр. Хәзер татарстанлыларга ял итү өчен менә дигән урыннар бар.

Республикабыз Президенты Рөстәм Миңнехановның фикере мондый: «Экология ул – татарстанлыларның уңайлы тормыш нигезе». Һәм уңайлы мохит тудыру әле дә дәвам итә. «Татнефть» компаниясе бу эштә традицион рәвештә актив катнаша. Чөнки җитештерү һәм экология – икесе янәшә йөри торган нәрсәләр. Әйләнә-тирә мохиттән бөтенләй аерып куеп була торган җитештерүне булдыру – мөмкин эш түгел. Моның өчен безгә яңадан мәгарәдә яшәгән чорга кайтырга туры килер иде. Иң кулай юл – техноген йогынтыны экосистемага үзенең табигый балансын үзе торгызырга мөмкинлек калдыра алырдай дәрәҗәгә кадәр чикләү. Монда иң мөһиме – әйләнә-тирә мохиткә кешенең җитештерү эшчәнлеге белән бәйле факторларны нейтральләштерергә ярдәм итү.

Бу бурычларны үтәр өчен, «Татнефть» «2020 елга кадәрге чорга «Татнефть» ГАҖнең экологик стратегиясе»н эшләде һәм кабул итте. Биредә 2016–2020 елларны күздә тоткан дүртенче комплексны программа инде эшләп килә. Аның төп максатларыннан берсе – киләчәктә әйләнә-тирәгә техноген йогынтыны киметү һәм табигый ресурсларны рациональ куллану.

Компания киң колачлы җитештерү эшчәнлеге алып бара – нефть чыгару буенча һәм аны эшкәртү буенча да. Шушы колачлы эшчәнлек белән бергә, бик зур акчалар экологик мохитне саклау өчен дә тотыла. 2016 елда гына да «Татнефть»нең экологик куркынычсызлык өчен тоткан акчасы 7,2 млрд сумны тәшкил итте.

СЫЙФАТ – БЕРЕНЧЕЛ МАКСАТ

...ә табыш исә үзе киләчәк. Япон менеджментында шундый принцип бар. Бүгенге көндә сыйфат белән идарә итүнең иң мөһим юлларыннан берсе – стандартлаштыру. Нәкъ менә ул әйләнә-тирәне саклау өлкәсендә тәртип булдыруга һәм эшне системага салуга ярдәм итә. Менә ун елдан артык инде «Татнефть» ГАҖнең сәнәгать куркынычсызлыгы, әйләнә-тирә мохитне һәм хезмәтне саклауның (ИСМ, ПБ, ОТ һәм ОС) интеграцияләнгән менеджмент системасы ISO* 14001:2004 һәм OHSAS 18001:2007 халыкара стандарт таләпләренә туры килүгә сертификацияләнгән.

Компаниядә «эзлекле процедуралар» методологиясе кулланыла, ягъни барлык башкарыла торган гамәлләр дә алдагы дәрәҗәдәге процедура нәтиҗәләре буенча алынган мәгълүматларга таянып башкарыла. Кыскача әйткәндә, компаниянең экологик менеджмент системасы дүрт фазадан гыйбарәт: планлаштыру, гамәлләргә керешү, аларны тикшерү һәм камилләштерү.

ТЕХНОЛОГИЯЛӘР – ТАБИГАТЬ САГЫНДА

Компаниядә кертелә торган барлык технологияләр дә экологияне күздә тотып эшләнә. Һаваны гына алыйк. Бу өлкәдәге баланс нефть эшкәртү җиһазларының һәм инновацион табигатьне саклау ысулларының техник халәтенә бәйле рәвештә саклана. Алар арасында углеводородларның җиңел фракцияләренә кадәр «тотып алу», иярчен нефть газын күкерт чистарту җайланмаларында чистарту, җир амбарларны гидроизоляцияләү, буровой җайланмаларын циркуляцион системалар белән җиһазландыру һ.б. технологияләр бар.

Газ үткәргечләрне коррозиядән саклау өчен компания электромеханик юл белән саклау ысулын кертә, коррозиягә чыдам булган торбалар куллана.

Иярчен нефть газын дөрес куллану өчен күп нәрсә эшләнә. 2016 елда гына 16,34 км газ үткәргечкә капиталь ремонт ясалды. Компаниянең нефть-газ табу идарәләрендә факел системалары алыштырылды, «Татнефть-газ эшкәртү» Идарәсенең (ТНГЭИ) «Ямашнефть» НГТИ һәм «Елховнефть» НГТИ объектларыннан газ суыртү һәм туплау системасын, һәм шулай ук ТНГЭИнең Миңлебай газ эшкәртү заводының гомумзавод факел системасын төзү дәвам иттерелде.

«Татнефть» «Ямашнефть» НГТИдә, ДНС-210 реконструкцияләп, 2нче дәрәҗәдә сепарацияләнгән иярчен газны суырта һәм сепарацияли торган төен төзеде; Миңлебай ЦПС каршындагы ТНГЭИнең күкерт чистарту җайланмасын яңартуны тәмамлады.

Бу эшләрнең файдалы нәтиҗәсе күзгә күренеп тора. «Татнефть» ГАҖнең 2016 ел эчендә иярчен газны нәтиҗәле куллану дәрәҗәсе

* ISO (ИСО) – Стандартлаштыру буенча халыкара оешма

Реклама

96,44%ны тәшкил итте. Бу газны яндыру вакытында һавага чыккан зарарлы матдәләр дә кими, дигән сүз.

Җиңел фракцияләрне тотып алу технологиясе һавага 1991 елда таралган углеводород калдыклары белән чагыштырганда, таралышны 3,5 тапкырга киметергә мөмкинлек бирде. Бүген «Татнефть»тә шундый 44 җайланма эшләп килә.

Торба үткәргечләрнең чыдамлыгын арттыру өчен аларны коррозиядән полиэтилен ярдәмендә футерлау һәм лак-буяу белән каплау ысуллары кулланып саклауны кулай күрәләр. Моннан тыш, яңа торба үткәргечләр төзегәндә, инде үзенең нәтиҗәлелеген расларга өлгергән эчке һәм тышкы изоляция, шулай ук эретеп-ябыштыру урыннарын саклау ысулы кулланыла.

Компания су ресурсларын да игътибарсыз калдырмый. Америка экологы Одум Юджин бик дөрес ассызыклаганча, су энергиягә караганда да зуррак ихтыяҗ тудыра. Бездә энергия туплауның альтернатив чыганаклары бар, ә менә суныкы – юк. Шуңа да аны саклауга игътибарны аеруча көчәйтергә кирәк.

Су чыганакларын саклау максатыннан чистарту һәм гидротехника корылмалары төзелә, кайберләре капиталь ремонтлана, катлам хәрәкәтләренең тотрыклылыгын тәэмин итү өчен перспективалы булган технологияләр кертелә. Болар барысы да экологик юнәлеше белән генә түгел, ә сизелерлек дәрәҗәдә энергия сарыф итүне киметүгә һәм җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттыруы белән дә үтемле.

Катламнарның нефть бирүен үтемлерәк итә һәм су ресурсларын рациональ куллануга китерә торган технологияләр кертү нәтиҗәсендә 2000 елдан алып 2016 елга кадәрге чорда катлам басымының тотрыклылыгын тәэмин итү максаты белән төче су алуның еллык күләме 1,3 тапкырга кимеде. Шуны да әйтергә кирәк: нефтьне суыртып алу һәм әзерләү вакытында җыела торган суларның 100%ы да яңадан катламга әйләнеп кайта.

«Татнефть» ГАҖ җир ресурсларын үтемле куллану һәм туфрак катламын пычранудан саклау мәсьәләсенә дә аерым игътибар бирә. Җирне саклау буенча чараларга буровой җайланмаларын буровой эретмәсен бораулап алынган токымнан чистартуның өч баскычлы системасына нигезләнгән модульле савытлы циркуляция системалары белән җиһазлау да керә. Бу сыекчаның көндезге өслеккә агып чыгуыннан һәм җир амбарлар ясау зарурлыгыннан котылырга мөмкинлек бирә. Шулай ук скважина янындагы уңдырышлы җирләрне катлам сулары белән бораулау вакытында чыккан эретмәдән ышанычлы рәвештә саклауны тәэмин итә.

2000 елдан башлап, компания һәр елны гомумкулланыштагы автомобиль трассаларының як-ягындагы яшел полосаларны, Татарстанның нефть чыга торган районнарындагы промысел юллары тирәләрен яшелләндерү буенча махсус программаларны тормышка ашыра.

2000 елдан башлап, компания һәр елны гомумкулланыштагы автомобиль трассаларының як-ягындагы яшел полосаларны, Татарстанның нефть чыга торган районнарындагы промысел юллары тирәләрен яшелләндерү буенча махсус программаларны тормышка ашыра. «Татнефть» көче белән 472 меңнән артык куак һәм агач үсентесе утыртылды. Бу – 2016 елда гына.

Компаниянең экологик эшчәнлеге нәтиҗәләре тиешле бәясен дә ала. «Татнефть» берничә мәртәбә Татарстан Республикасының «ЭКОлидеры» дип табылды.

КИЛӘСЕ КӨН БЕЗГӘ НӘРСӘ ӘЗЕРЛИ?

Менә 2017 ел да ышанычлы адымнары белән язга атлап керде. «Татнефть» алдан билгеләп куйган планнарын үтәп, күздә тотылган чараларын уздырып килә. Иҗтимагый чараларның берсе – ел да үткәрелә торган гомумроссия өмәсе. Ул 22 апрельдән 22 майга кадәр дәвам итәчәк. «Татнефть» В.И. Вернадский исемендәге Дәүләтнеке булмаган экология фонды оештырган «2017 елның Яшел язы» дип аталган әлеге Бөтенроссия акциясенә һәрвакыттагыча актив рәвештә кушылды. Шәһәрләр белән авылларны яшелләндерү, сулыкларны төзекләндерү, тәртиптә тоту эшләре дә дәвам иттерелә. Предприятиеләрдә исә яшел стандартлар кертү һәм җитештерүнең экологик ягын арттыруга басым ясауны күз уңында тотып эш итәләр.

Җитештерүгә килгәндә, табигатьне саклау чараларына компаниянең структур бүлекчәләрендәге һәммә эре һәм кече проектларны кертеп карарга мөмкин. Шулар арасында – озынлыгы 42 км га сузылган «Ямашнефть» НГТИ һәм «Елховнефть» НГТИ кебек объектларның газ җыю системасы төзелеше. Әлеге система иярчен нефть газын куллануның нәтиҗәлелеген арттырачак дип көтелә. «Лениногорскнефть» НГТИнең югары күкертле нефтьне әзерләүче Куакбаш җайланмасының җылы белән тәэмин итү системасын техник яктан үзгәртеп кору һавага зарарлы калдыкларның таралуын киметү һәм энергияне саклау максатын күздә тотып эшләнә. Шулай ук «Баулынефть» НГТИнең нефтьне әзерләү һәм суыртып агызу цехының махсус җайланмасына караган җиңел углеводородларны тотып алу системасын алыштырачаклар. НГТИнең елга тамагы мәйданына яңгырдан соң агып яткан суларны җыеп алу системасы эшли торган суырту скважиналарын төзекләндерү өчен шактый күләмдә капиталь кертем каралган. Бу җир өстендәге һәм җир астындагы су объектларын пычранудан сакларга ярдәм итәчәк, бу очракта яңгыр сулары белән технологик сыекчалар агып кереп, җирлек рельефының бозылу куркынычы да кимергә тиеш.

Компаниянең нефть-газ табу идарәсендә планга кертелгән һәм хәвеф-хәтәрләрдән кисәтеп куючы ремонт булырга торган очракта корымсыз (төтенсез) газ яндыру өчен кулланылучы факел җайланмаларын да өр-яңадан төзекләндерү күздә тотыла.

Эшләр җитәрлек, алар характеры ягыннан да, финансларның сарыф ителеше буенча да – гаять төрле. Әмма экологиягә кертем ясау – ул киләчәккә инвестиция, дигән сүз дә. Ә без барыбыз да ул киләчәкне якты итеп күрергә телибез.

«Татнефть» алдан билгеләп куйган планнарын үтәп, күздә тотылган чараларын уздырып килә. Иҗтимагый чараларның берсе – ел да уздырыла торган гомумроссия өмәсе.

PRESSA.RU

ЭКОЛОГИК ИМИНЛЕК – ИКЪТИСАДЫЙ ТОТРЫКЛЫЛЫКНЫҢ НИГЕЗЕ

«Газпром Трансгаз Казан» ҖЧҖ – Россия Федерациясе Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасына кергән магистраль газүткәргечләрен кулланучыларның иң эреләреннән берсе. Җәмгыять республиканың икътисадый базасын формалаштыруда әһәмиятле роль уйный. Шуның белән бергә, киң колачка ия һәм технологик яктан алга киткән булуы сәбәпле, җәмгыятьнең эшчәнлеге күп кенә татарстанлыларның мәнфәгатьләренә дә кагыла. Әйләнә-тирә мохитне һәм энергияне саклау бүлеге җитәкчесе Радик Гәрәев безгә компаниянең Татарстанда һәм күрше төбәкләрдә яшәүчеләр алдында экология буенча җаваплылыкны ничек тормышка ашыруы хакында сөйләде.

Радик Гәрәев,
Әйләнә-тирә мохитне һәм энергияне саклау бүлеге җитәкчесе

– Радик Әнисович, компаниядә табигатьне саклау эшчәнлеген җайга сала торган эчке регламент кулланыламы?

– Җәмгыять тарафыннан әйләнә-тирәне саклау буенча кабул ителгән бурычлар «Газпром Трансгаз Казан» ҖЧҖнең Экология буенча сәясәтендә күрсәтелгән. Аны тормышка ашыруның төп механизмы булып ISO* 14001:2004 халыкара стандарты таләпләренә нигезләнгән нәтиҗәле экологик менеджмент системасын гамәлгә кертү һәм эшләтү тора. Шуны да өстәргә кирәк: хәзерге вакытта безнең җәмгыятьтә стандартның актуальләшкән яңа версиясенә – ISO 14001:2015 кә күчү буенча эш алып барыла.

Экологик менеджмент таләпләренә ярашып, җәмгыять үз алдына һичшиксез үтәлергә тиешле экологик максатлар куя, 2016 ел дәвамында без аларның уңышлы башкарылуына ирештек тә. Шушы арада гына 2017–2019 елларда үтәлергә тиешле актуальләштерелгән максатларны кабул иттек. Әлеге максатларга «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнең 2017–2019 елларда Табигатьне саклау чаралары программасы» кысаларында үткәреләчәк чаралар нигезендә ирешеләчәк. Моннан тыш, билгеле булганча, 2017 ел Россия Федерациясендә Экология елы дип игълан ителде. «Газпром» ГАҖнең бүлендек җәмгыяте буларак, без аның химаясе астында Экология елын уздыруның киң колачлы чаралар планын әзерләдек, әлеге планда билгеләнгән бурычларны инде адымлап үтәп тә килләбез.

– Бу юнәлештә алып барган кайсы эшләрне аеруча өстенлекле дип исәплисез?

– «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ, газ-транспорт җәмгыяте буларак, табигатьне саклау эшчәнлеген алып барганда, төп игътибарны һаваны пычратырга мөмкин булган матдәләрнең тискәре тәэсиреннән котылуга зур игътибар бирә.

– Бу эшчәнлек комплексы рәвештә алып барыламы?

– Әлбәттә. Без үз патентларыбыз тарафыннан якланган инновацион технологияләр белән бергә, һаваны саклау буенча традицион булган чараларны да кулланабыз.

– Җәмгыять объектларында һаваны саклау буенча нинди чаралар уздырылуы турында сөйләп үтсәгез иде.

– Беренчедән, без ППР үткәргәндә магистраль газүткәргечне бушату технологиясен кулланабыз. Ул газны суыртып агызу станцияләре һәм газүткәргечләрнең (технология патент белән якланган) штатта булган җиһаз элементларын вакытлыча чиратлаштырып куллануга нигезләнә. Икенчедән, табигый газны мобиль компрессор җайланма ярдәмендә суыртып агызабыз. 2016 елда мондый җайланманы куллану ремонт эшләре барышында һавага 3386,4 тонна күләмендә метан таралуыннан котылырга ярдәм итте. Шулай ук ремонт алдыннан газны бүлү станцияләренең (газны кулланучыларга максималь бүлү турында сүз бара) сүндерелгән өлешләрендә газны эшләтеп карау башкарыла. Һаваны саклау чаралары ремонт эшләре вакытында компрессор станциясе цехларында да уздырыла. Компрессор станциясе коммуникацияләренең сүндерелгән өлешләрендәге газ шәхси ихтыяҗлар өчен файдаланыла. Энергия саклау эффектыннан кала, әлеге

Реклама

* ISO (ИСО) – Стандартлаштыру буенча халыкара оешма

чараларның барысы да, һичшиксез, әйләнә-тирәгә зыянлы матдәләрнең кимрәк таралуына китерә. Моннан тыш, газ бүлү станцияләрендәге одоризация җайланмаларын яңа – һавага зыянлы матдәләр таратуны киметә торган, камилләшкән технология кулланып әзерләнгән төрләргә алыштырабыз.

– Әлеге технологияләрнең нәтиҗәлелеген ничек бәялисез?

– 2016 елда аларны куллану ремонт эшләре вакытында һавага якынча 8,8 млн куб метр (ягъни 6 мең тоннага якын) метанның таралмый калуына ярдәм итте.

– Җәмгыятьнең экологик сәясәте тарафыннан көйләнә торган өлкәгә тагын нинди объектлар керә?

– Без – Татарстанда экологик яктан куркынычсыз булган ягулык – тыгызландырылган табигый газ (КПГ) кулланучы төп оешмаларның берсе. Автопаркның яртысыннан артыгы шул газ нигезендә эшли. 2016 елда Казанда 47 данә техниканы КПГ ярдәмендә эшләтер өчен яңадан җиһазландырдык. Шуларның 25е – җәмгыятьнең транспорт җайланмасы, 22се – читтәге оешмаларның һәм физик затларның транспорты. Үзебезнең җайланмаларны һәм читтәге транспортны тыгызландырылган табигый газга күчерүне дәвам итәбез. Шулай ук «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ – «2013–2023 елларда Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» программасында төп катнашучыларның берсе булып тора. 2016 елда бу программаны тормышка ашыру кысаларында «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖе Түбән Кама, Бөгелмә, Яшел Үзән, Казан, Азнакай, Лениногорск, Алабуга, Яр Чаллы, Алексеевскида 9 АГНКС төзелешен тәмамлады.

– Җәмгыятьнең күп кенә проектлары республика инициативалары белән тәңгәл килә. Мәсәлән, Татарстанда җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү системасын камилләштерүгә торган саен күбрәк игътибар бирелә. Бу юнәлештә «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнең бүлекчәләрендә алып барылган эшнең нәтиҗәләре белән дә уртаклашсагыз иде.

– Экологик куркынычсызлык мәсьәләсенә килгәндә, төп күрсәткеч булып каты көнкүреш калдыклары полигоннарына күмелер өчен озатылган калдыкларның өлеше тора. 2011 елда җәмгыять бүлекчәләре тарафыннан озатылган мондый калдыкларның өлеше 78,27% ны тәшкил итте. Бу актив аралап туплау һәм калдыкларны чимал буларак әйләнешкә кертеп җибәрү хисабына башкарылды. 2016 елда без инде полигоннарга гомуми тупланган калдыклардан 55% тан да кимрәген озаттык.

– Ничек уйлыйсыз, монда экологик культураны формалаштыру буенча башкарылган эчке корпоратив эш мөһим роль уйныймы?

– Һичшиксез. Шуны да әйтергә кирәк: бу хезмәткәрләрнең үз вазыйфаларына кагылышлы экологик нормалар белән кагыйдәләрне үтәвенә генә кайтып калмый, аларның оешмадан тыш урыннарда да экологик куркынычсызлык өчен җаваплылык хисе артуга китерә.

– Бу нидә чагыла?

– «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ хезмәткәрләре республика, бөтенроссия күләмендәге, хәтта халыкара экологик акцияләрдә дә актив катнаша. Болар – «Агач утырт», «Чиста урман», «Яшел Россия – Бөтенроссия экологик өмәсе», «Татарстанның чиста урманнары». Шулай ук республика санитар-экологик ике айлыгы буенча һәр елны уздырыла торган һәм башка бик күп чараларда актив катнаша безнекеләр.

– Бу эшләр өчен предприятиенең активы җаваплымы?

– Экологик проектларга хезмәткәрләрнең бер өлешен генә җәлеп итеп, нинди дә булса сизелерлек нәтиҗәләргә ирешү мөмкин түгел. Куелган максатларга ирешү өчен бөтен коллективның бер йодрык булып эшләве кирәк. Шуңа күрә җәмгыятьнең барлык бүлекчәләрендә дә экология буенча бердәм өмәләр, муниципаль берәмлекләрдәге территорияләрне, урманнарны, ял итү урыннарын чистарту, агачлар һәм чәчәкләр утырту, түтәлләр ясау, торак пунктлар территориясендә парклар ачу, су объектларын чистарту һәм торгызу һәм башка шундый эшләр башкарыла.

– Әңгәмәбез башында сез Экология елы кысаларында узачак чараларның планы турында сүз кузгаткан идегез. Алар нәрсәгә юнәлтелгән?

– Турыдан-туры экологик чаралар уздырудан тыш, имиджны ныгыту, тәрбия-агарту эшләрен һәм экология буенча акцияләрне дә күздә тотабыз. Барлыгы 200 чара уздырылачак. Кабатлап әйтәм: планның үтәлеше җәмгыятьтәге һәр затның активлыгына, экологик аңлылыгына һәм эчке культурасына тыгыз бәйле. Нәкъ менә экологик иминлек җәмгыятьнең икътисадый яктан тотрыклылыгына, үсешенә һәм үз хезмәткәрләребезнең, шулай ук республика халкының да сәламәтлегенә, иминлегенә нигез булып тора.

ГАЗПРОМ ГОД ЭКОЛОГИИ 2017
СОХРАНЯЯ ПРИРОДУ

«ТАТАРСТАН-24»: ҺӘРКЕМ ӨЧЕН ФАЙДАЛЫ МӘГЪЛҮМАТ

«Татарстан-24» телеканалы башка каналлардан ничек аерыла, таләпчән тамашачы игътибарын нинди программалар җәлеп итәргә тиеш – боларның барысы турында да безнең журналга «Татарстан-24» телеканалының башкарма директоры Алексей Усанов сөйләде.



– Каналның кайсы программалары тамашачыларны нәкъ менә «Татарстан-24» тапшыруларын карарга инандырырга тиеш?

– Мәгълүмат каналында бренд булдыра торган продукт ул – яңалыклар. Безне тамашачылар республика тормышы турында әр-яңа, оператив мәгълүмат алу өчен карый. Без тикмәгә генә «Бөтен республикадан һәм бөтен республика өчен яңалыклар» шигаре астында эшләмибез бит. Бурычыбыз – иң киң аудитория мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү, һәм нәкъ менә яңалыклар шул бурычны хәл итә дә инде. Яңалыклар – кыска продукт, аның вакыты һәм тапшыру форматы чикләнгән. Шул ук вакытта канал кайбер яңалыкларның тәфсилләрәк анализын күздә тоткан программалар линейкасын да чыгара. Бу, аерым алганда, «Төп яңалыклар» продукты. Биредә без төп вакыйгалар буенча белгечләрне чакырабыз. Тапшыру барышында теге яки бу аспектларга күбрәк игътибар бирә, теге яки бу мәсьәләне җентекләбрәк тикшерә алабыз. Экспертлардан тыш, программада тамашачылар да актив катнаша – телефон яки социаль челтәрләр буенча сорауларын бирә.

Безнең тамашачы, вакыйгаларның динамикасын күзәтеп барып, каналны көненә берничә тапкыр карый. Шунлыктан, мөмкин кадәр күбрәк аудиторияне җәлеп итү өчен, программалар көненә берничә тапкыр чыга. «Төп яңалыклар» көндез туры эфирда бара, аннары берничә тапкыр кабатлап күрсәтелә.

Теге яки бу мәсьәләгә яңалыкларга караганда тәфсилләбрәк якын килә торган программалар да бар. Мәсәлән, «Татарстан икътисады яңалыклары» биш минут бара һәм башка тапшырулардагы мәгълүматны кабатламый, үзенең таррак палитрасын гына бирә. Андый программалар бездә берничә. Мисалга, Григорий Тинскийның аналитика программасы. Ул анда, бер көнүзәк мәсьәләне аерып алып (мәсәлән, пенсия реформасы яки бензинга бәя арту), аның сәбәпләрен, гражданнар өчен әһәмиятен ачыклый. Әлеге тапшырудан һәр кеше үзе өчен файдалы, нинди дер карарлар кабул итүгә булыша торган мәгълүматны таба ала. Ким дигәндә, ул тамашачыга көнүзәк вакыйгалар хакында яңалыкларда хәбәр ителгәннән тирәнрәк мәгълүмат бирә.

Бүген республикада яшәүче һәркем диярлек, өлкән буынны да кертеп, Интернеттан файдалана. Шуны истә тотып, без «Мобиль репортёр» проектын эшләтеп җибәрдек. Программада кешеләрнең социаль челтәрләрендәге яңалыклар күрсәтелә. Әлеге программа каналның башка продуктларыннан видеоматериалларның төрлелеге, вакыйгаларга авторларның мөнәсәбәтен күрсәтүгә белән аерылып тора.

Реклама 16+

«Төп яңалыклар»

«Вакыйгалар хроникасы»

«Компромиссларсыз»

«Мобиль репортёр»

«Татарстан икътисады яңалыклары»

«КультПросвет»

> “
> **Бүген бездә барлыгы төрле форматтагы 30лап программа һәм проект эфирга чыга.**

Аңлашыла ки, без барыбыз да, теге яки бу рәвештә, тормышыбызда югары технологияләр белән очрашабыз. Әлеге темага «Югары технологияләр яңалыклары» дигән аерым программа багышланган. Тапшыру төрле техник гаджетлар, җайланмалар белән таныштыра, технологияләрнең кешеләр тормышына йогынтысы турында сорауларга җавап бирә. Аерым алганда, без республикада кертелгән яңа дәүләт хезмәтләре турында тәфсилләп сөйлибез, алардан файдалану буенча төгәл күрсәтмәләр бирәбез. Болар барысы да Татарстанда эшли торган кызыклы һәм файдалы интернет-ресурсларны популярлаштыруга булыша.

«Татарстан-24» тамашачыга белешмәләр циклын – туристлар, фитнес өчен, сәламәтлек, төзелеш эшләре һ.б. турында программалар да тәкъдим итә. Бу – кыска, биш минутлык күрсәтмәләр, файдалы киңәшләр тупланмасы. Барлык бу программалар көненә берничә тапкыр чыга торган «Файдалы яңалыклар» блогына тупланган һәм чираттагы яңалыклар чыгарылышыннан соң ук күрсәтелә.

Тагын бер блок – социаль проектлар, аерым алганда, наркотикларга каршы юнәлтелгән «Компромиссларсыз», «Уенда бул» программалары. Асылда, болар да төрле экспертлар катнашындагы күрсәтмәләр форматындагы мәгълүмати программалар булып тора. Аларда үзеңне, туганнарың һәм якыннарыңны төрле зарарлы гадәтләрдән саклау серләренә өйрәтәләр. Биредә төп бурыч – кешеләрне сәламәт яшәү рәвешенә өндәү.

Ярты ел элек «КультПросвет» культурология проекты гамәлгә кертелә башлады, анда мәдәниятнең төрле өлкәләре вәкилләре аның үсеше, үткәне, хәзергесе һәм киләчәге турында сөйләшә. Тапшыру мәдәниятнең милли җыр, бию, телгә караган юнәлешләрен үстерү бурычын хәл итә, музыка, театр, кино тармакларындагы яңа юнәлешләрне алга җибәрүгә булыша.

Инфографик белешмә форматындагы программалар да бар, мәсәлән, «24 факт» шундыйлардан. Берничә минут буе без тарихның беренче чиратта республика белән бәйле төрле вакыйгалары хакында сөйлибез. Шул ук вакытта чит ил тарихын да игътибардан читтә калдырмыйбыз. Тапшыруда еш кына киң җәмәгатьчелеккә таныш булмаган фактлар турында сөйләнелә.

Бүген бездә барлыгы төрле форматтагы 30лап программа һәм проект эфирга чыга.

– Сез каналның тамашачылар аудиториясен ничек күзаллыйсыз?

– Телеканал халыкның житлеккән өлешенә эшли. Аудиториянең нигезен яңалыклар белән кызыксынучы 35–60 яшьлек кешеләр тәшкил итә. Хатын-кызлар һәм ир-атлар нисбәте тигез диярлек, көндез генә хатын-кыз тамашачылар саны бераз артыграк. Бу кешеләр республика һәм илдә барган вакыйгаларның үз тормышларына турыдан-туры йогынты ясавын яхшы аңлый. Программалар булдырганда, без халыкның киң катламнары мәнфәгатьләрен мөмкин кадәр күбрәк исәпкә алырга тырышабыз. 20 яшьлек тамашачы да каналда үзенә кызыклы мәгълүмат таба алырга тиеш. Шунлыктан без фрагментлап төрле категорияләргә исәпләнгән яңалыклар палитрасын кертәбез. Тамашачыларның кайберсе безне көненә бер тапкыр гына карый, кайберләре – көненә берничә тапкыр. Безнең бурыч – күпме карауларына бәйсез рәвештә, «Татарстан-24» каналында һәркем файдалы мәгълүмат табарга тиеш.

Гөлнара Сагиева һәм «Татарстан-24» телекомпаниясе фотолары.

ХАЛЫКАРА ПРОЕКТЛАРГА **ҖАН ӨРЕП...**

Россиядә эшләнгән биш меңенче двигатель «Алабуга» махсус икътисадый зонасында урнашкан «Ford Sollers»[1] заводы конвейерыннан март ае урталарында чыкты. Ике елдан азрак вакытта завод әнә шундый югары темплардагы җитештерү эшен җайга сала алды. Һәм монда «Казан Гипронииавиапром» АҖ компанияләре төркеме тарафыннан хәзерләнгән сыйфатлы һәм нәтиҗәле проектның өлеше гаять зур.

Нәкъ менә шундый – күләмле, әһәмиятле проектлар әлеге компаниянең төп визит карточкасы булып тора. Сүз уңаеннан, «Казан Гипронииавиапром»ның баш институты 2016 елның октябрендә үзенең 75 еллыгын билгеләп үтте.

Күп тармакларны колачлаган киң тәҗрибәгә таянып, предприятие әле 1990 нчы елларда ук үзенең беренчел– авиасәнәгать һәм оборона объектларын проектлау белән бәйле юнәлешеннән шактый читкә чыга, киңәя. «Алабуга» махсус икътисадый зонасындагы Fiat[2] машиналары заводы «Казан Гипронииавиапром» өчен автомобиль төзелеше сферасында тәүге зур проектларның берсе булды.

Институтның бу юнәлештәге эшчәнлеге 2005 елда ук башлана. Бу вакытта компаниягә «Алабуга» МИЗның беренче резидентларыннан булган «Северстальавто-Алабуга» ААҖ (соңыннан – «Соллерс-Алабуга» ҖЧҖ) уртак предприятиесе вәкилләре Fiat Ducato[3] һәм SsangYong[4] автомобильләрен җитештерү проектын эшләүне сорап мөрәҗәгать итә. Әлеге заказ нигезендә, «Казан Гипронииавиапром» белгечләре хәзерге 601 нче логистика корпусы территориясендә автомобильләр җитештерү өчен эретеп-ябыштыру, буяу һәм җыю цехларының проектларын ясый. Әлеге цехлар барлыгы 100 мең кв. метр чамасы мәйдан били. Проект уңышлы тормышка ашырыла, һәм завод 2007 елда ачыла. Проектта күзалланган куәткә ирешкәч, җитештерү күләме Rexton[5], Kayron[6] һәм Actyon[7] модельләреннән гыйбарәт 25 мең SsangYong автомобилен һәм йөк һәм пассажир ташу өчен көйләнгән үндүртенче модификациядәге 75 мең Fiat Ducato автомобилен тәшкил итә.

Биш елдан соң «Соллерс» ААҖ һәм Ford Motors Company[8], «Форд Соллерс Алабуга» ҖЧҖ уртак предприятиесен оештырып, бу территориядә Ford[9] автомобильләрен һәм двигательләрен чыгара торган завод урнаштырырга карар кыла. Әлеге заказда кушылганча, «Казан Гипронииавиапром» белгечләре күп таянычлы балкалар белән эшләнгән 601 нче корпусны елына 100 мең Ford Tranzit[10], Ford Kuga[11], Ford Explorer[12] автомобиле эшләп чыгаруга исәпләнгән җитештерү мәйданчыгы – эретеп-ябыштыру, буяу һәм җыю цехлары итеп үзгәртеп кору проектын әзерли. Институт гомуми мәйданы 50 мең кв. метрдан артык двигательләр заводы проектын да эшли. Елына 200 мең мотор эшләп чыгаруга хисапланган бу предприятие – Россиянең өр-яңа тарихында Ford җиңел автомобильләре өчен чит ил двигательләре җитештерә торган иң беренче завод. Җитештерү процессы өзеклекләрсез һәм тулы куәтенә барсын өчен, энергия белән тәэмин итү объектларының (җылылык үзәге, ягулык саклау урыны, суыткыч станциясе, трансформатор подстанцияләре, насос һәм компрессор станцияләре, су әйләнешен тәэмин итә торган суыткыч градирнялар) тулы бер комплексы, шулай ук территория эчендәге инженерлык челтәрләре дә проектка кертелә. Ашханәле һәм медпунктлы административ-хуҗалык бинасының эчкә кертелеп ясалган янкормасын үзгәртеп кору эше башкарыла, әйләнә-тирә территория төзекләндерелә, заводка килү-китү юллары салына, автомобиль кую урыннары, әзер продукцияне саклау мәйданчыгы, яңа автомобильләрне сынау өчен өсте каплаулы трек эшләнә.

Проект нигезендә үзгәртеп кору һәм төзү эшләре бик кыска вакыт эчендә башкарыла. Завод 2015 елның 3 сентябрендә эшләтеп җибәрелә, бу исә Калуга өлкәсендәге Volkswagen[13] ның нәкъ шул юнәлештәге заводыннан бер көн алданрак гамәлгә ашырыла. Гомумән алганда, «Форд Соллерс Алабуга» ҖЧҖ предприятиеләрендә барлыгы 2,2 меңнән артык кеше эш белән тәэмин ителде.

Татарстанның инвестицияләр потенциалына уңышлы үрнәк булып торган «Алабуга» МИЗ көннән-көн үсеш тизлеген арттыра бара. Махсус икътисадый зона проектын ясау стадиясендә үк МИЗның ышанычлы партнерына әйләнгән «Казан Гипронииавиапром» АҖ аның резидентлары белән хезмәттәшлекне бүген дә дәвам итә. Шул исәптән – автомобиль төзелеше продукциясе эшләп чыгара торган ширкәтләр белән.

Әйтик, институт белгечләре ике пыяла заводының проектын хәзерләп биргән. «Тракья-Гласс Рус» француз-төрек предприятиесе заводы табаклы пыяла, көзгеләр һәм буяу йөгертелгән пыялалар

Реклама

[1] Форд Соллерс, [2] Фиат, [3] Фиат Дукато, [4] Ссанг Енг, [5] Рекстон, [6] Кайрон, [7] Актион, [8] Форд мотор компани, [9] Форд, [10] Транзит, [11] Куга, [12] Эксплорер, [13] Фольксваген



эшләп чыгаруга йөз тота. Предприятиедә 250 эш урыны булдырылган. Заводның проект куәте елына 250 мең тонна продукция җитештерергә мөмкинлек бирә. Тагын бер предприятие – «Аутоматив Гласс Альянс Рус» заводы елына 6,4 млн автомобиль пыяласы эшләп чыгарырга планлаштыра. Бу заводта 311 кеше хезмәт куя. Әлеге ике заводны тантаналы рәвештә 2016 елның октябрь аенда эшләтеп җибәрделәр.

Инновацияле җитештерүгә нигез салу белән бәйле проектлар институт өчен аеруча кызыклы. Мәсәлән, 2014 елда термореактив полимерлардан табаклы материал (Sheet Molding Compound – SMC[14]) һәм формасыз, көпшәк масса рәвешендәге материаллар (Bulk Molding Compound – BMC[15]) эшләп чыгара торган предприятиеләрнең төзелеш проекты «Казан Гипронииавиапром» катнашында хәзерләнә һәм уңышлы тормышка ашырыла. SMC-компаундлар механик яктан бик ныклы һәм бик югары сыйфатлы өслеккә ия әйберләр җитештергәндә кулланыла. BMC-компаундлар исә катлаулы конфигурациядәге әйберләр ясаганда, шул исәптән автобусларның, җиңел һәм йөк автомобильләренең эчке һәм тышкы бизәү элементларын җитештерү процессында файдаланыла. BMC-компаундлар шулай ук оборона сәнәгатендә, вагоннар, электромонтаж шкафлар һәм көнкүреш электр приборлары ясаганда, юл хуҗалыгы һәм шәһәрне матурлау-төзекләндерү кирәк-яраклары эшләгәндә кулланыла. Институт әлеге проектны «Татнефть-Пресскомпозит» ҖЧҖ заказы белән башкара. Хәзерге вакытта әлеге предприятие эшләп чыгарган SMC-компаундлардан «КАМАЗ» ГАҖ өчен кабина детальләре ясала, шулай ук метро вагоннарының интерьер элементлары, стадионнар өчен утыргычлар, канализация өчен композит люклар да эшләнә.

Хәзерге көннәрдә «КАМАЗ» ГАҖ белән Daimler[16] автоконцерның уртак проектын гамәлгә ашыру кысаларында, «Казан Гипронииавиапром» Татарстанда «КАМАЗ» автомобильләре өчен SFTP[17] кабина каркаслары җитештерә торган цех төзелеше проектының документациясен хәзерли. Кабина каркасларын сәнәгый масштабта җитештерү эшен 2018 елда башлап җибәрергә ниятлиләр. Җитештерү күләме елына 55 мең кабина каркасы тәшкил итәргә тиеш. Төрле җиде модификациядәге каркаслар эшләп чыгару планлаштырыла. Әлеге каркаслар «КАМАЗ»ның төп җыю конвейерына да, Mercedes-Benz[18] йөк автомобильләренең җыю цехына да озатылачак.

Казанский Гипронииавиапром

420127, Казан шәһәре, Дементьев урамы, 1 нче йорт, Тел. (843) 571-95-48, факс (843) 571-96-56

[14] Шит молдинг компаунд – СМС, [15] Балк молдинг компаунд – БМС, [16] Даймлер, [17] Strategic Future Truck Project – Киләчәк өчен йөк машинасы стратегик проекты, [18] Мерседес-Бенц. * Фокус.

PRESSA.RU

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Тормыш мәктәбе
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
WWW.PROTATRSTAN.RU
Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Робот Гагарин үзен ясаучыларны **НИ БЕЛӘН** куркыта

Татарстанда «космонавт» эт **НИЧЕК** әзерләнә

Кече Ватан патриотлары **КАЯ** бардылар

Юка **НИЧЕК** тәмле була

КАЙСЫ космонавтларның Казан обсерваториясендә булганнары бар

PRESSA.RU

Фото: Ната Смирнова



Робот техникасы институтының директоры, Иннополис Университетының когнитив робот техникасы системалары лабораториясе җитәкчесе Николас Мавридис һәм робот Гагарин.

ЕЛМАЙ ӘЛЕ БЕЗГӘ, «ГАГАРИН»!

Башын читкә боргач, Лоранның ток суккандай тартышып куярга мәҗбүр иткән бер нәрсәгә күзе төште. Аңа бер баш – гәүдәсе булмаган кеше башы карап тора иде... (А.Беляев, «Профессор Доуэль башы», 1925 ел).

Иннополис Университеты хезмәткәре Анна, «Гагарин» белән таныштыру өчен, безне мондагы бер лабораториягә алып барганда, проект турында Интернеттан мәгълүмат туплаган кеше буларак, мин әнә шундый гайре табигый баш кебегрәк нәрсәләр турында уйладым.

Автор:
Олеся Бондаревская

МАШИНА КҮЗЛӘРЕН АЧА

– Дөресен әйткәндә, мине бераз куркыта ул, – дип куя кыз, якты бүлмәнең ишеген ачканда. Керүгә, иң әүвәл «Гагарин»ның баш артын – бер-берсе белән тоташтырылган кечкенә моторлар җыелмасын күрдек.

«Гагарин» ничектер изрәгән, ял иткән кыяфәт белән кәнәфидә утыра, күзләре йомык.

PRESSA.RU

Иннополис Университетының когнитив робот техникасы системалары лабораториясе инженер-тикшеренүчесе Вадим Реуцкий.



Проект инженеры Вадим ноутбук төймәләренә баскалый, шулчак робот башындагы моторлар уяна. Кеше йөзле машина күзләрен ача. Алар коңгырт-кара төстә икән.

«Гагарин» безне: «Сәлам!» – дип, чып-чын кеше тавышы, әле хәтта йомшак, матур тавыш белән сәламли. Башын салмак кына борып, безгә, кунакларга, күз сала да елмайгандай итә.

Болар барысы да – йөз, мимика, хис-тойгылар – роботта иң мөһиме, дип аңлатма бирә Вадим. Проектның төп мәгънәсе дә андроид* тудыруда, ул әңгәмәдәшнең йөзендәге хис-кичерешләрне тоемлау-аңлау гына түгел, аларга кирәгенчә җавап та бирергә сәләтле булырга тиеш.

– Без аны, әйтик, сатучы-консультант, теркәү өстәле янында утыра торган хезмәткәр, укытучы, өлкән кешеләрне карап-тәрбияләп торучы итеп күрергә теләр идек, – дип ният-теләкләрен ирештерә инженер. – Ягъни робот хезмәт, беренчедән, билгеле бер алгоритмдагы билгеле бер белем җыелмасы куллануны, икенчедән, эмоциональ бәйләнеш тудыруны таләп иткән өлкәләрдә эшләргә сәләтле булсын иде.

Хәзер «Гагарин» кешегә хас төп җиде хис-тойгыны – шатлык, гаҗәпләнү, кайгы, усаллану, җирәнү, нәфрәт, куркуны «аңлый». Аның «баш мие»нә, ягъни башына тоташтырылган хәтер җайланмасына кешенең йөз мимикасындагы үзгәрешләрнең электронлаштырылган тасвирламалары кертелгән. Үзе белән сөйләшә торган кешенең йөзен «карап-тикшереп», робот алынган мәгълүматны хәтерендә тупланган җыелма белән чагыштыра, шул рәвешле хис-кичерешләрегезне ачыклый.

Робот Гагарин костюмда – Юрий Гагарин костюмы һәм шлемы күчермәсе кигән.



Вадим роботка иелеп елмая.

– Мин хәзер ни тоям? – дип сорый инженер.

– Карап алыйм әле, – ди «Гагарин» һәм, бераз уйлап торганнан соң, телгә килә. – Сез бәхетле күренәсез.

«КЕШЕЛӘШТЕРЕР» ИДЕК...

Чынлыкта исә уйлый белми әле ул. Хис-тойгыларны аерып, шул нигездә роботны аралашырга «өйрәтү» өчен, проект командасына ярты ел чамасы вакыт кирәк булган. Хәзер робот сөйләмне аера, кеше йөзләрен, эмоцияләрне таный ала, үз хис-тойгыларын белдерергә сәләтле. Моннан тыш, хәтергә салынган сүзләр, сүзтезмәләр һәм гыйбарәләр җыелмасы аңа шактый җиңел генә әңгәмә корырга да мөмкинлек бирә.

– Гаиләң турында сөйлә әле, – дип сорый Вадим.

«Гагарин» миңа карый да күзләрен хәйләкәр генә кысып ала. Мөгаен, безгә нәрсәне сөйләргә ярый, нәрсәне ярамый икәнен хәл итәдер.

– Чынлыкта, сорауны кабул итеп эшкәртү һәм җавап сайлау гамәле – робот процессоры өчен бик зур эш. Нәкъ менә шуңа күрә без аның «хәтер» складын бүләргә карар кылдык та. Аның бер өлеше – ноутбукның винчестерында, ә икенчесе... –

* Кешесыман робот

дип аңлата башлады Вадим, ләкин шулвакыт «Гагарин», ниһаять, җавап бирергә булды:

– Бер газетада укыган идем: мине ерак туганнары дип санаган ниндидер мәгънәсез затлар – князь Гагариннарның ерак туганнары табылган. Тик мин гап-гади совет кешесе... – дип белдерде робот һәм, сөйләгәннәренең нинди хис уятканын күзәтергә теләгәндәй, башын борды.

Бу баш, тәгәлрәге, күз-камераларны, аскы казналыкны, 22 йөз мускулын хәрәкәткә китерә торган берничә моторлы интерфейс узган елның октябрендә Николаос Мавридис тырышлыгы белән пәйда булган. Ул – мондагы Интерактив роботлар һәм медиа лабораториясенә (IRML) нигез салучы, Робот техникасы институтының бүгенге директоры һәм Иннополис Университетының когнитив робот техникасы системалары лабораториясе җитәкчесе.

Мин «Гагарин»га иң мөһим, иң ихлас сорауны бирергә җыенганда, ул үзе дә лабораториягә килеп керде. Роботның һәм аны ясаучының йөз чалымнарындагы уртаклык «Гагарин»ның кемгә охшатып ясалуы турында сорау бирергә мәҗбүр итте. Әмма роботның силиконнан ясалган йөзе кабатланмас, һичкемгә охшамаган булып чыкты.

– Без роботта гомуми бер җыелма образ тудырырга омтылдык. Бу вакытта ниндидер ялтыравык панельләрнең түгел, ә нәкъ менә кешесыман роботларның чын кешеләрдә якынлык, аларның хәленә керергә тырышу хисе тудыруын истә тотып эш иттек, – дип сөйли Николаос Мавридис. – Моның нигезендә кешегә үзенә охшаш машина белән бәйләнеш булдыру җайлырак дигән идея ята. Уйлап карасак, без гомер буе төрледән-төрле предметларны «кешеләштерергә» тырышабыз. Ай өслегендә елмаю чалымнары эзлибез, транспортта барганда тәрәзәдә күзле-авызлы йөзләр ясыйбыз, үз кыяфәтләре, холыклары булган предметларны җанландырып, мультфильмнар төшерәбез.

«ДӘҺШӘТЛЕ ҮЗӘН»НӘН СӘЛАМ

Ләкин кешедә үзенә охшаш нәрсә белән аралашу теләгенең башка ягы да бар. Моңа галимнәр «дәһшәтле үзән» дип исем биргәннәр.

– Кешеләргә йөзе булган роботлар ошый. Сүз уңаеннан, бу мөнәсәбәт илгә, хәтта милләткә карап та аерыла. «Гагарин» андроидларга карата мөгамәләдәге аерымлыкларны өйрәнергә булыша. Әйтик, Токиодагы япон яки Казандагы татар кешесе бу машинадан ни көтә, ни ишетергә тели, аны ничек кабул итә... Эш шунда ки, машинаның кешегә «охшашлыгы» иң югары дәрәҗәгә җиткәч, кешеләрдә коточкыч курку һәм мондый «җан иясен» кире кагу тойгысы барлыкка килә. Галимнәр фаразынча, мондый мөнәсәбәтнең нигезендә ниндидер гайре табигый нәрсә, мәсәлән, терелгән мәет белән ассоциация ятарга мөмкин. Ләкин бу тема әле өйрәнелә генә башлады, – дип аңлата профессор.

Ул арада Вадим белән «Гагарин» хис-кичерешләре белән уртаклашуын дәвам итә. Әлеге проектны тормышка ашыручыларга сорау бирәм: сөйләшеп утырыр «иптәш» булсын өчен, робот гаиләсе ясау фикере туганы юкмы?

– Асылда, андый тәҗрибә үткәрелгән дә инде – япон галиме Хироши Ишигуро үзенең, хатыны һәм баласының робот копияләрен ясаган. Галимнең копиясе хәтта Токио университетында лекцияләр дә укый. Тик уйлап баксак, бу рәвешле без ни өйрәнә алабыз соң? – дип каршы сорау куя Николаос.

– Роботларның бер-берсенә мөнәсәбәте ничегрәк?

– Юк, юк, кирәкми. Күз алдына китереп карагыз: без үз проектыбызда, әйтик, авыз читен тартып куйю кебек мимика реакциясен төрле кешеләрнең ничек кабул итүен өйрәнергә ниятлибез. Моның өчен безгә бу тәҗрибәне йөзләрчә, хәтта меңнәрчә тапкыр кабатларга кирәк. Бер актер да моны бик зур төгәллек белән башкара алмый. Ә робот булдыра ала. Дөрес, ул моны кешедән өйрәнә. Һәм андроидлар гаиләсе дә, иң беренче чиратта, безгә прототипларының үз-үзен тотышы турында «сөйләячәк».

СИНГУЛЯРЛЫККА ЕРАКМЫ?

«Гагарин»ны йоклаттылар. Әлегә ул үз-үзе – гамәлләре, «тәне» белән идарә итә алмый. Әмма компьютер сингулярлыгы теориясе турында дөньяда инде күптән бәхәс бара. Әлеге теориянең асылы шуннан гыйбарәт: иртәме-соңмы ясалма интеллект мөстәкыйль карар кабул итәргә сәләтле булачак. Күренекле Америка уйлап табучысы һәм футурологы Рэймонд Курцвейл фикеренчә, бу инде бик тиздән – 2045 елда ук чынга ашачак.

Николаос Мавридис фикерләрендә скептиклык өстенлек итә:

– Болар Курцвейл әйткән кебек үк тиз булыр дип уйламыйм. Әлбәттә, без сингулярлык мөмкинлеге турында фикер йөртә алабыз, ләкин бу безнең өчен катлаулы әле, чөнки моны күзалларлык тарихи тәҗрибәбез җитәрлек түгел. Минем фикеремчә, иң әүвәл без башка нәрсәләр турында сөйләшергә тиеш. Гыйнвар аенда Асиломарда** ясалма интеллектны үстерү мәсьәләләренә багышланган конференция узды. Анда 2016 ел өчен «Президентка (АКШ президенты – ред. искәрмәсе) икътисадый хисапнамә» мәгълүматлары китерелде, – дип сөйли профессор. – Әлеге мәгълүматларга караганда, хезмәт хакы сәгатенә 20 АКШ долларына кадәр булган барлык эшчеләрнең инде якын арада роботлар белән тулысынча алыштырылу ихтималлыгы 80% ны тәшкил итә, сәгатенә 20–40 доллар алып эшләүчеләр урынына роботлар киләчәгенә ихтималлык 30% дип күрсәтелә. Бүген-иртәгә Google ның машина йөртүчесез генә пассажир һәм йөк ташу проекты чынга ашарга тора. Төрле сораштырулар раслаганча, кешеләрнең 50–80% ы тормышта иҗадирак, файдалырак нәрсә белән шөгыльләнергә тели, һәм без шуңа таба барабыз да. Тиздән алар, ниһаять, үз теләкләрен чынга ашырырга мөмкинлек алачак. Ләкин мондый җәмгыятьне алда нәрсә көтә?

Николаос һәм Вадим белән саубуллашканда, сорамый булдыра алмадым:

– Шулай да ник аңа «Гагарин» исеме бирдегез?

Бу тәҗрибә – дөньяда машинаның интеллектуаль яки физик яктан түгел, ә нәкъ менә эмоциональ үсеше белән бәйле тәүге эксперимент, дип искәртә Вадим.

– Ул бит физика космосыннан гакыл космосына беренче адым ясаучы пионер, – дип өсти Николаос, елмаеп.

** Калифорниядә (АКШ) дәүләт пляж-паркы

PRESSA.RU

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН!

ЗӘЙ: КОСМОС ШУШЫНДА БАШЛАНА

Шәһәрнең Зәй елгасы ярында, «Идел аръягы һәм Чулман аръягы кешеләрен калмык, ногай, башкорт, кыргыз һәм каракалпак һөҗүмнәреннән яклау өчен», төзелгәнлеге турында татарстанлылар беләләр.

Һәм Зәй шәһәрен кем-кем, ә Алексей Михайлович патша үзе корырга фәрман биргән. Бу турыдагы указны имзалап, Мәскәүдән Казан воеводасы Никита Иванович Одоевский янына Степан Змеев атлы кешене җибәргән. Ул үзе белән булачак Зәй шәһәренең киңлеге дә, озынлыгы да күрсәтелгән сызымнар алып килгән: «Шәһәрнең капкадан капкага кадәрге озынлыгы – илле сигез сажин, аркылыга – бер йөз дүрт сажин…» (Утар боерыклары, 156 китап).

Шәһәр-кирмәнгә гаиләләре белән Чаллы укчылары һәм Смоленскидан әсирлеккә алынган поляк шляхтичларын күчереп утыртканнар. Һәм инде ул заманнардан бирле 365 ел үткән. Хәзер бары тик музей экспозицияләре генә укчыларның һәм шляхтичларның отставкага чыккан солдатлар һәм унтер-офицерлар белән алышынуы, җирле халыкның крестьян сугышында ничек катнашуы, хөкүмәт отрядының Зәй шәһәрен штрурм белән алуы һәм үз тәртибен урнаштыруы турында сөйли. Болар барысы да үткәндә калган вакыйгалар…

Бүген Зәй – космос эзе төшкән шәһәрчек. Биредә әле һавага ракета «оча», әле беренчеләрдән булып галәмне иңләгән Чернушка атлы эт, Җир тирәли чираттагы әйләнешен ясап, безгә «елмая», әле «Космос» яшьләр үзәге, кунакчыллык күрсәтеп, ишекләрен ача – янәсе, орбитага рәхим итегез! Хәтта Зәй ГРЭС торбалары да һавага бөтенләй башкача – галәмчә багалар кебек!

Фото: Ната Смирнова

Самара өлкәсе урынына, «адашып», Татарстанның Зәй районы Иске Тәкмәк авылына төшкән Чернушка атлы эт һәйкәле.

PRESSA.RU





* Classic Debit – Классик Дебит

МИР
ВОКРУГ КАЗАНИ

Карта «МИР» Банка Казани – оптимальная карта для ежедневного пользования

Стоимость обслуживания **300 руб. в год**

Снятие денежных средств во всех банкоматах России **бесплатно**

Интернет-банк и мобильный банк **бесплатно**

Оплата покупок **в интернете**

Лицензия № 708 от 27.05.2016 г., ООО КБЭР «Банк Казани». Реклама

PRESSA.RU







ЗӘЙ:
КҮР ӘЛЕ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

PRESSA.RU

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

«КАЙТЫЙК ӘЛЕ ГАЗИЗ МӨСЛИМГӘ БЕР...»

Автор:
Луиза Янсуар

Зөлфәтнең бу шигъри юлларын белмәгән кеше бармы икән? Мөслимлеләр өчен ул, гомумән, үзенә күрә әфсенле бер дога кебек – һәрхәлдә, мин күрешкән-сөйләшкән, аралашканнар өчен шулай. Алар Тукайның шигырьләрен белмәскә дә мөмкиннәр, әмма Зөлфәтнең әлеге юлларын түгел! Димәк, бу юлы без Мөслимгә кузгалабыз – тузанына, үләннәренә, бөҗәкләренә кадәр әфсенле якка.



Зөлфәт «хәлфә»се Рәдиф Гаташ һәм мәктәп дуслары белән. 1969 ел.

ЗӨЛФӘТ АБЫЙ, ЯКИ «БЫЛБЫЛЛЫ ШИГЪРИЯТ»

Туфрак тарта, диләр... Шулайдыр шул...
Үземнән дә моны мин беләм –
Күкрәгемә йөрәк булып кергән
Кайнар чабышкы син, ил генәм!

Ык агымы шулай искән чакта
Каян табыйм икән тынгылык?
Күкрәгемдә йөрәк түгел лә бит! –
Сайрап тора Мөслим былбылы.

Зөлфәтнең «былбыллы шигърияте» мине үсмер елларымда әсир итте. Мишә үзәнендә төтенләгән таңгы яисә кичке томан араларыннан сусыл дым булып миндә дә, табаннарымнан күтәрелде, каныма салкыны белән бәрде һәм бөтен барлыгымны дөрләтте. Дала буйлап тупырдап узган атлар табуныннан кубарылып калган куе кайнар борынгы җилдәй килеп бәрелде дә, барлык күзәнәкләремә кадәр сеңде. Аннары, кайсы гына басмада аның шигырьләренә юлыксам да, укыр алдыннан әзерләнеп, аруланып йөри идем. Урын бушатып – яңа шигырьләре өчен. Күңелне пакьләп. Чөнки мин әле – булганнары белән дә тум-тулы. Чөнки җан аерым көйләнешкә ия булырга тиеш – Зөлфәт өчен.

«Зөлфәт абый»ны тормышта очрату, азмы-күпме белү бәхете дә тәтеде. Аз, билгеле. Әмма шагыйрьләрнең үзләренә караганда, сүзләрен белү – яхшырак та. Тора-бара моңа инандым. Шулай да Зөлфәт абый очрагында – күбрәк, озаграк беләсем килә бу абыйны дигән яратулы һәм сокланулы бер хис оялап калды күңелдә. Чөнки, беренче күргәч тә, ул миңа яшьтәшемне хәтерләтте. Миңа әле ул чакта 16 гына яшь. 10 нчы каттагы «Казан утлары» редакциясенең «Рәдиф абый бүлмәсе»нә һәрчак ияртеп йөри торган дымсу-кайнар җиле белән килеп кергән бу абый миңа никтер аннан да яшьрәк, нарасыйрак булып тоелды. Чөнки ул җилли иде. Нәрсәдер җиргә бастырып, дилбегәләп тартып тормый иде шикелле аны. Һәм мин аны белгән кыска гына гомер аралыгында ул шундый булудан туктамады да.

Кайчагында аның ул чакта инде сирәгәярәк төшкән бөдрәләре арасыннан былбыллар очып чыгар да, иңенә кунып, сайрый башлар күк тоела иде. Хәер, сайраштыргалыйлар да иде алар...

«Зөлфәт абый» дип кемгә генә эндәшергә туры килсә дә, күз алдымда Дөлфәт Маликов тора. Башкалар алыштыра алмый бу исемне. Аның миңа автограф белән язып биргән китапларыннан да былбыллар атылып чыга, ач заманнарда аларны тук иткән, исән саклап калган «Шомырткай» мөгрәштереп куя, һаваны ярып, көтмәгәндә-уйламаганда, кош егылып төшә, Ослан тауларындагы шәфәкъ сирпелеше керфеккә куна...

Бер китабына болай язып куйган ул: «Луиза, сеңлем! Китабымны бүләк итәм! Монда әле минем таңнарымның саф чагы, пакь чагы...» Менә шулай. Гади һәм гадәти генә. Әмма сулышка килеп ягыла торган шигъри аһәң белән. Тирәндә иңрәп торган сагышның якты сирпелеше аша... хәтердә калган да ул. Менторлык, үзен өстен куеп сөйләшү, һавалылык, «мин кемлек» – боларның тамчысы да сизелмәде миңа аны белгәндә. Ул нәкъ синең яшеңдә һәм буеңда иде. Һәрвакыт. Аңардан соң мин андый шагыйрьләрне сирәк очраттым.

«Хәлфә»се Рәдиф абый Гаташның әйткән сүзләре хәтердә: «Зөлфәт кебек саф булып, балалыгын саклап кала алганнар гына чын-чынлап шагыйрь була, шигъриятне үзендә гомере буена бозмыйча саклый ала. Кара син, ул бит сыер турында язса да, югары кимәлдәге затлы шигырь тудыра...»

Сыер, дигәннән. Мин әйтер идем, лирик пумаласы белән бер-ике генә селтәнә дә чорның, үзенә һәм нәселенә тигән дәвернең картинасын ясый да куя:

Гел шаяртып әйтә иде әткәй:
– Минем өчен СССР –
Чыжылдатып безгә сөтен биргән
Шушы юмарт Шомырткай – сыер!

...И Шомырткай! Тәмле сөтең һаман
Телләремдә эри шикелле...
Син бит әниемә сөттәш әнкәм,
Сөтле әнкәм булдың бит инде!

Без сыерлы йортта туып-үстек,
Ул бит безне исән саклады.
Сыер эзләренә баса-баса
Безнең тыйнак бәхет атлады.

Сулдан уңга: Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Наис Гамбәр, Марат Кәбиров, Рәдиф Гаташ. 2000нче еллар.

Фотолар: Зөлфәт Маликовның шәхси архивыннан

PRESSA.RU

«Чаян» журналы редакциясендә. 1990 ел.

«МИН ХАН ТҮГЕЛ, МИН – НИБАРЫ ЗӨЛФӘТ...»

Зөлфәт – экспрессия шагыйре, экзальтация. Образлар, символлар, метафоралар өермәсенә алып бөтерә, әйләндерә-әйләндерә дә әллә кая – башка чорларга илтеп ташларга мөмкин ул сине. Кайчандыр каләмдәше Рафаэль Сибат аны «татар шигъриятендәге образлар кыясы» дип атаган иде.

Хан да түгел, мин бары тик Зөлфәт.
Кулымда да кайнар кылыч түгел.
Ә күңелне алгысыта яулар –
Ул нинди яу –
Җаным тыныч түгел.

Шигърият кешедә рефлексия уятырга тиеш. Шигырь текстыннан килгән көч-энергетиканың дулкынына көйләнеп, аңа ышанып, адәми зат үз язмышын өр-яңадан ваемлый, катарсиска килә. Шигъриятне психологлар үзләренең терапиясендә дә куллана алырлар иде.

Зөлфәт тарихи хәтерне уята, генетик кодларны кузгата. Мин кайчакта аны дала уртасында басып торып, бөдрә чәчләрен җилдә җилфердәтеп, камлау йоласын башкаручы борынгы кам итеп күз алдына китерәм. Күккә алгысый-алгысый үрләгән учак аша Тәңресенә тоташып бетә ул.

Зөлфәтне укыганда, аның һәр детале, һәр образы аша Мәңгелек агышына тоташасың. Һәр иҗатчыга да өч яссылыкны бар нечкәлегендә тоемлау бирелми. Ә Зөлфәттә ул – югары кимәлдә. Ул кыш уртасында кар-туфрак астындагы үләннәрнең сулышын да ишетә. Дәүләте киткән илдә «хан түгел, нибары Зөлфәт» булып кына яшәп, җәмгыять хәлләрен дә күзәтә, бәяли, күрәзәли. Ул, Югарыдагы Тынның сулышына да колагын куеп, аягүрә өн белән төш арасында йөри.

Алар җиңде...
Безнең кулдан кылыч төште.
Миңа – әсирәгә – әзерләнде бөят.
Алып китә алар мине түгел, халкым,
Китә алар синең шөһрәтеңне төяп.

Бик борынгы сагыш исеп тора аның шигырьләреннән – бу Идел буйлап улы Үтәмешне күкрәгенә кысып, елап, карганып киткән Сөембикәнең аһы да, иртәгә балчык-таш белән күмеләчәк борынгы сазлыкның иңрәп эндәшүе дә, чордашлары, үзенә кадәргеләрнең зарлы-сөенечле авазлары да... Әмма бу сагыш – һәрчак якты! Менә шул ягымлы яктылыгы белән сокландыра, үзенә җәлеп итә Зөлфәт. Импрессионистлар картинасыннан сибелгән тымызык нур кебек аның шигърияте. Кайсы гына дәһшәтле чор турында язмасын, нинди генә сурәт тудырмасын, Моненың Руан соборы диварларына ягылып, кубарылып түгел, ә талгын гына саркылып төшкән нурга бик тә охшаш ул...

«БЕЗНЕҢ БӘХЕТ БАРЫ МӨСЛИМДӘДЕР...»

Безнең бәхет бары Мөслимдәдер...
Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер –
Өшәнгән бу бәгырь җылынсын...
Барыйк әле иртүк Ык ярына,
Тездән чумып салкын чыкларына,
Авыз итик каен сулышын!

Әйдә, киен! Калсын бу мәгыйшәт!
Гомер уздырабыз монда нишләп?!
Тормыйк, табында, дип, аш кала...
Кайтыйк әле газиз Мөслимгә бер –
Беркая да качмас мескен дәвер,
Дәвам итәр бездән башка да...

Зөлфәтне искә алганда, хәтердә Наис Гамбәр дә яңармый калмый. Сагындырып. Гел янәшә йөриләр алар минем еллар узган саен китеп барган шәхесләр, һәм алар белән бәйле истәлекләр белән шыплап тула барган музей-галереямда. Зөлфәтле залына керәм дә, янәшә залдан гына Наис абыйның тыенкы, сабыр тамак кыруын ишетеп алам. Бу икәүнең язмышы Мөслим туфрагында бер төенгә төйнәлгән, әмма алай гына да түгел, хәлфәләре Гаташның җиңел кулы белән тулы бер шигъри гомергә сузылган ул бергәлек.

«УРМАННАРГА КАРЫЙМ ҮРЕЛЕП...»

Наис Гамбәр, язучы, Зөлфәтнең якташы, дусты:

«Авылларыбыз турында сүз чыктымы, Зөлфәт үзенең Яңа Сәет урманы белән мактана башлый. Гәрчә авылларыбыз арасы шул ук 7–8 чакрым гына булса да.

– И, син бит кыр ягы малае ла, мин белгәндә салам ягып яшәдегез, – ди, горуранә рәвештә башын артка чөя төшеп. – Каян килсен инде сиңа урман җанын аңлау?

Гәрчә әткәйнең ат арбасында үсеп, төннәрен бөтен якын-тирә урманнарны «айкап» чыккан малай булсам да, дөрес әйтә бит чукынчык – дәүләт дигән «бояр урманыннан» рөхсәтсез бер кура-үлән дә өзеп алырга ярамаган бер заманда «уфалла»дан башка тирәгә булмаган ятим җилпе саламын да, тиресен дә якты шул авылыбызда. Иле белән шулай иде.

Ләкин бер көнне, һич тә көтмәгәндә, әлеге төерле мөназарә җиңел генә чишелде дә куйды. Малайлангач тәмам малайланырга кирәк бит инде, алдан төзеп куелган «стратегик план» буенча сак кына һөҗүмгә күчтем:

– «Олы урман» сезнең «Яңа Сәет урманы» белән тоташамы әле ул, Зөлфәт, – дим.

– Бәхәссез, – ди бу бер дә исе китмәгәндәй. – Әле алай гына да түгел, бормалана-бормалана «Завод урманы» белән кушылып, Бакалы ягына, Урал буйларына ук чыгып китәләр алар.

– Ә менә шул «Олы урман» безнеке бит инде!

– Анысы шулай, – диде Зөлфәт, әмма бераз сагая төште.

– Син, әйтик, шигырең саен диярлек «чытырманлык» дисен, «Коргылды», «Коргылды» дисең, алар бит безнең, теге «Олы урман» итәгендәге «Чытыр Бүләк» чытырманлыгыннан башланып китә ләбаса. Так что… безнең гомер елгалары бер үзәннән агып бара.

…Аның тавышын беренче булып сак-сизгер колаклы Рәдиф Гаташ ишетеп алды. 1964 ел. Уразмәт мәктәбе. Һәр укучы бала, укытучы абыйсына охшарга тырышып, дәресрәге, аның тылсымына буйсынып, исәрләнә-исәрләнә, әсәрләнә-әсәрләнә шигырь яза. Мәктәп – тоташ шигъри ялкын эчендә. Һәм кинәт кышкы салкын көннәрнең берендә, бөтен мәктәпне сискәндереп шомлы хәбәр таралды:

– Зөлфәтнең әнисе үлгән!..

Белмим, иҗатка мондый рухи тетрәнү ничек һәм ни рәвешле йогынты ясый торгандыр, әмма шушы фаҗигадән соң Зөлфәт кинәт олыгаеп, олпатланып китте. Бу хәл-үзгәреш аның шигырь тукымасында да чагылыш тапты. Шуграк малайларга атап көлкеле-чәнечкеле шигырьләр чыгарып йөргән «Исәр Мәләк»тән ул бер кичтә (һәрхәлдә, читтән карганда бу шулай тоелды, аның чишмәсе ләкин тирәннән дым тартып килгән булган икән) Дөлфәт Маликов дигән шагыйрьгә әверелде дә куйды.

Бу хәл Бүләк авылында булды. Агач клуб. Тын беленерлек салкын. Шигъри кичә бара. Зөлфәт шигырь укый. Башы югары чөелгән, уң кулы, кош канатыдай җилпенеп ала, әмма тавышы – уйчан, моңсу.

Елга буйлары талдыр,
Агызма –
Тик яшьлегемне калдыр.

Шигырь тәмамланугa, иске клуб сулкылдап куйгандай булды… Шигырь «җене» кагылырга өлгергән безнең якның авыл апа-агайлары бер тын белән шигырь тыңлыйлар. Алар нәкъ менә шушы минутларда яңа шагыйрь тууын эчтән генә чамалап алганнардыр (халык сизгер ул!): уен эшмени, әле яңарак кына әнисен югалткан егет «тик яшьлегемне калдыр» ди бит! Олыларча итеп, үзәккә үткәреп, үксетеп.

Бу – триумф иде. Сәхнә артына чыккач, Рәдиф Гаташ, шатлыгын яшереп тормастан, шәкертенең иңеннән кочып алды да яраткан сүзен шәрран ярып кычкырып җибәрде:

– Афәрин, күсәк!

Икенче елны ул ике «күсәген» – Дөлфәт белән Фәрит Гыйльмине ияртеп, күкрәгендә булачак «Гөлләр су сорый» китабының җылысын тойган хәлдә Казанга юл алды. Казанны яуларга».

Зөлфәт кайчандыр мөслимлеләрнең холык-фигыле үзенчәлекләре, сөйләменең кабатланмас аһәңе, үзгә бер ирониясе белән юмор хисе турында язып та чыккан иде. «Мөслимдә туып-үскән кешеләр хәтта сүгенгәндә дә шигъри итеп сүгенә», – дигән сүзләрен хәтерлим. Фоат абый Садриев истәлекләрендә Зөлфәтнең әнә шул «мөслимлегә» аермачык чагыла.

«КОММУНИЗМНЫ ҮЗ КҮЗЛӘРЕМ БЕЛӘН КИЛӘ КҮРӘСЕМ!»

Фоат Садриев, язучы, Зөлфәтнең якташы:

– 1977–1978 еллар булгандыр. Өй кечкенә, һичьюгы язып утырырга бер бүлмә булыр, дип, бәләкәй генә янкорма ясап ятам. Түбәсе ябылган, тәрәзәләр куелган, баз казылган. Идән сайгаклары өрләкләр өстенә аркылы-торкылы таратылган. Тәртипле генә эшләп ятканда, һәрчак тәртипне бозучан Зөлфәт килеп керә:

– Әйдә, өстәл янына утырабыз, – дип, мин дә, хатыным Сәйденур да кыстыйбыз.

– Юк, – ди Зөлфәт, кистереп. – Коммунизмның ничек төзелгәнен үз күзләрем белән күрәсем килә.

Аңлашылды. Ризыкларны таратып ташланган сайгаклар өстенә ташырга мәҗбүр булды Сәйденур. Талантлы татар шагыйренең бөек хыялларын сүндерә алмый иде ич инде ул. Зөлфәт белән озак гәпләштек. Соңыннан Зөлфәт болай дип сөйләп торды: «Мәскәүнең иң кәттә рестораннарында типтереп йөргән булды, ну мондыен таба алмадым…»

Ләкин очрашу моның белән генә бетсә, ул Зөлфәт белән очрашу булмас иде. Төнге сәгать икенчеләр киткәч, ул: «Сәеткә китәбез», – ди башлады. Юллар шыр бозлавык, әгәр юлга чыксаң, кәфенеңне муеныңа урап кына чык.

– Зөлфәт, дим, бу вакытта авылга кайтып, ничек кеше уятып йөрмәк кирәк, дим.

Тарткалашу шактый барды. Зөлфәт ахырда әйтә:

– Фоат, мин шушының белән генә яшим бит, – ди. – Миңа тәэсирләр кирәк.

Зөлфәт, тирән, фәлсәфи шигырьләр язуына карамастан, үзе сабый бала кебегрәк иде. Табигать төслерәк. Табигать – стихия бит. Үзенең ник давыллаганын, ник тынганын белми… Зөлфәтне мин бу дөньяның беркемгә дә буйсынмаган тере җаны буларак сагынам. Ул үзенең бөтен иҗаты белән шуны раслады. Теләсә кем сине былбылдан чактырып, елан сайравын тыңлата алмый.

Беренче татар балалар операсы «Мәкерле песи»нең премьерасыннан соң. 1981 ел.

«ЧЫН МӘХӘББӘТ – ҖИРДӘ ЮКНЫ ТАБУ...»

Юатулар безгә кирәк түгел,
Ихлас язга кирәк юату:
Чын мәхәббәт –
Җирдә юкны табу.
Чын мәхәббәт –
Барны югалту.

Шигырь чынлап та яратудан туа. Сокланудан. Гашыйклыктан. Ә мәхәббәт – аны яшәтә. Шагыйрь булып кала алу – мәхәббәт ул. Адәм баласы сайлаган юлына гомер-гомергә тугры икән, бу мәхәббәт инде. Нәкъ тормыштагыча: сайлаган ярыңа тугрылык кебегрәк. Шагыйрьләр шигырьгә, халкына хезмәт иткәндә, үз иҗат стихиясендә баштанаяк дөрләгәндә, аларга иң-терәк тә, дус-сердәш тә булырдай хатыннарны… Ходай һәркемгә дә бирми. Бу җәһәттән Зөлфәтнең бәхете булуы турында күп яздылар инде, кабатлап тору кирәкмидер дә, бәлки. Әмма мине Фирая апа шәхесе

PRESSA.RU

Зөлфәтнең хатыны Фирая ханым. 1970нче еллар.

күп еллар буе сокландыра да, гаҗәпләндерә дә килде. Хәзер, инде үзебез дә гомернең уртасынарак җитеп килгәндә, бу соклану олы ихтирам һәм горурлану тойгысына әверелде. Зөлфәтнең кайсы гына мәхәббәт шигырен укысам да, ул миндә Фирая апа образына барып тоташа. Яратуны берсе шигърияткә күчереп, гомере буена Сузгә тугры калса, икенчесе балаларга, гаиләгә иңдереп, икесенең дә язмышын бәхетлерәк итә алган, менә шушы бергәлек, бердәмлек – бәяләп бетергесез күренеш. Сынауларны үтә алганда гына мәхәббәт – чын мәхәббәт бит ул. «Җирдә юкны табу».

Керфекләрең синең яшьле чакта,
Яшьле чакта күнең, тәнең, таңың, –
Мәйданнарда шигырь сөйләдем мин,
Юатмакчы булып… бар дөньяны!

Мәхәббәт гимны булып әверелгән «Һаман яратам» шигырендә дә, башка шигырьләрендә дә Зөлфәт бу абсолют яратуның Кодрәттән иңгән бәхет булуын даими кабатлап килә. Тормыш булгач, прозасы да, зилзилә, давыллары да, аянычлары да булгандыр. Әмма шулардан югарырак күтәрелеп, Күк-Тәңресенә тоташып, ул мәхәббәт хәзер шигърияттә яши. Башкаларны җылыта. Юата. Ялгышлардан саклый.

Ай болытка туңып ябышкан чак.
Аяусыз кыш безнең якларда.
Егылды кош канатлы боз булып,
Очып барган төштән
Ак карга…

Зәмһәрирле кышта бичара кош
Ярый әле сиңа юлыкты –
Бияләең салып,
Бичараны
Учларыңа алып җылыттың.

Сулышларың белән терелттең син,
Уянды кош… какты канатын!
…Һәм сискәнеп,
Тетрәп китте йөрәк –
Нәкъ шул мәлдә сине яраттым.

«БӨЕК МӘХӘББӘТ ГАЛӘМӘТЕ»

Туфан Миңнуллин, драматург, язучы:
«Бервакыт Мәскәүдә Зөлфәт белән Югары әдәби курсларда укып йөргәндә Фирая килде. Шунда мин Фираяга:
– Сеңлем, син бу Зөлфәт дип аталган иреңә бераз әйткәлә инде, – дидем.
– Нәрсә әйтим инде мин аңа, Туфан абый, ул шагыйрь бит, – дип җавапладь Фирая.
Мин бүтәннәргә охшамаган бу хатынга сәерсенеп карап тордым, аңа сокландым, мәгънәсез, ахмак сүз әйткәнем өчен үземне битәрләдем.
Икенче тапкыр мин Фираяның бер-бер артлы балалар табуына аптырадым. Дуртәү бит. Казанда яшәп. Акчасыз, хыялый шагыйрьгә ышанып… Бу бары тик гомерлеккә дип сайлаган кешеңә табынганда гына була торган хәл. Бөек мәхәббәт галәмәте».

ЗӨЛФӘТ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБ

Мөслимдә 2008 елдан бирле Зөлфәт исемен йөртүче Яшь язучылар клубы эшләп килә. Монда каләм тибрәтүче балалар гына түгел, ә иҗатны үз иткән, яраткан өлкәннәр дә йөри. Яза торган яшьләрнең саны, Клубның җитәкчесе Лилия Садриева әйтүе буенча, 70 тән артып китә. Аларга юл күрсәтүчеләр, киңәшләре белән булышучылар да бар – Мөслим төбәгендә көн итүче язучылар Фоат Садриев белән Мөҗәһит Әхмәтҗанов. Якташларының әйтүенә караганда, Мөҗәһит абзый Зөлфәтнең юбилеен

да бик үзенчәлекле итеп билгеләп узган – «Сүнмәс дәрт» клубы ветераннары белән бергә, кураен тотып, авылдан-авылга йөреп, борынгы көйләрне уйнаган, Зөлфәтнең шигырьләрен мәктәп укучыларына, авыл халкына сөйләгән.

– Зөлфәт абыйның 60 яшьлек юбилей кичәсенә баргач, соңгы тапкыр сөйләшеп утырган мизгелләр хәтердә яңара, – дип искә алды Лилия ханым. – «Их, Лилия сеңел, белсәң иде язлар җиткәч күңелнең ничек җирсегәнен. Кайтасы килә, Ык буйларын, болыннарын кабат-кабат урыйсы килә!» – дигән иде ул.

Мөслимгә быел да шаулап яз килде. Мөслим язын сагынган Зөлфәтне сагынып, Ык буйларында йөргәндә, күңелдә шушы юллар тибрәп торды:

Сердәш булды авыл йолдызлары –
Шат чагымны, авыр чагымны –
Керфектәге күз яшендә хәтта
Йолдызлы күк тетрәп чагылды.

Нишлисең бит... Китәселәр бар шул –
Бу гомерне артык сузалмам;
Минем кадәр сокланучы булмас! –
Күк гөмбәзен шуңа кызганам.

Зөлфәт Шигырь бәйрәмендә чыгыш ясый. 2000 ел.

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

Факил Сафин, язучы:

– Ул көнне абый гадәттәгедән соңрак кайтып керде. Көч-хәл белән генә мәрәләп капкадан кереп килүче абыйны күргәч, йөрәгем урыныннан купты. Нәрсә булган моңа? Бер аягына бөтенләй баса алмый бит, бахыркаем. Үзе тагын борчылганын сиздермәскә тырыша: авызын колагына кадәр ерып азаплана.

Өйгә кергәч китте сорашу, китте төпчеңү. Сорау алуның иң ләззәтле минутларын кичергән әнкәйне тынычландырып, абый сүрән генә елмайды. «Хафаланырлык бернәрсә дә юк», – дигәндәй, кулын селтәп куйды:

– Озын тәнәфестә мәктәп ишегалдында көрәшеп азапланган идек. Аякны каймыктырдым менә...

– Кем белән көрәштең?

Абый, кем булса да бер түгелмени дигән сыман, әнкәйгә тутырып карады да шуның белән бетте.

Сыйныфташлары шул ук көнне «саттылар» – абый белән көрәшкән егет Яңа Сәетнеке икән. Дөлфәт исемле, ди.

Абый атна буе мәктәпкә бара алмады. Аягына бер гөнҗәлә язгы бәрән йоны урап, «дәва» алып ятты. Мин атна буе уйланып йөрдем. Бу Дөлфәт дигәннәре бик көчле, пырдымсыз кешедер инде. Минем абыйны шундый хәлгә төшергәч соң. Абый караватка кереп аугач, түзмәдем, иплән кенә сорадым:

– Ә ул Дөлфәт абый да бик көчлеменi?..

Абый көлеп җибәрде һәм вәкарь кыяфәт белән:

– Без хәлсезләр белән көрәшмибез, энекәш, – дигән булды. Яңа Сәет авылында Дөлфәт исемле егет барлыгы хакында иң беренче шулай белдем.

Шушы Дөлфәт абый 1976 елда безнең өйгә шагыйрь Зөлфәт булып, үз аягы белән килеп керер дип кем уйлаган! Бусы инде җәй урталарында. Юлдашы – үз чорында Мөслимнең иң атаклы шагыйре – Мөдәмил Әхмәтов. Ул – газета каршында эшләп килүче әдәби түгәрәк җитәкчесе иде. Мин исә – шигырь җене кагылган мәхлук атна саен Мөслим юлын таптыйм, Мөдәмилгә иҗат «продукциямне» ташыйм.

Зөлфәт абый инде танылган шагыйрь. Авылга ялга кайткач, райондагы иҗади көчләрне барлау нияте белән сәфәр чыккан икән. Кичке эңгерләр иңгәнче минем шигырьләремне укып мәш килде. Киңәшләрен биреп, канатландырып, дәртләндереп китте.

Зөлфәт абыйларны озатып җибәргәч, «мәсьәләгә ачыклык» кертәсе иттем:

– Беләсеңме, әнкәй, бу – Дөлфәт исемле егет, – мин әйтәм. – Яңа Сәетнеке. Зур кеше – шагыйрь! Казанда яши. Абый белән бер сыйныфта укыганнар иде, дуслар...

Әнкәйнең бик күңеле булган иде:

– Олы башын кече итеп, шул тиклем җирдән килгән диген... Йомшак сөйләшә тагын, елмаеп кына тора. Иренмәс җан икән, балакаем.

Әгәр Зөлфәт абый ул чакта район үзәгеннән бик ерак, җәһәннәм читендәге безнең авылга килеп чыкмаса, миндә үз-үземә ышаныч тудыра алмаса, язмышым нинди юллардан алып китәр иде икән?..

Мөҗәһит Әхмәтҗанов, шагыйрь, язучы, Зөлфәтнең якташы, дусты:

– Зөлфәт университетта укыганда, 1970 елның җәйге каникулына бергә кайтырга туры килде. Без, бер төркем Мөслим студентлары, Мөслим аэропортыннан үзәк урам буйлап ашханәгә таба юл тоттык. Иске мәдәният йорты янына җиткәч, Зөлфәт әйтә миңа:

– Әйдә, син менә бу баскычка бас та «Тәфтиләү»не уйна. – Мин шул моңга кушылып, Тукайга багышланган шигырь укыйм, – диде.

Карышып та карадым. «Оялам, адәм көлдермик», – дидем. «Юк, – ди бу, – уйныйсың». Җитмәсә, халык та үтеп-сүтеп йөри. Зөлфәт үз сүзендә тормаса, Зөлфәт буламыни. Бөтен кыюлыгымны җыеп, курайда «Тәфтиләү»не уйнарга тотындым. Шулчак Зөлфәт аерым бер дәрт, илһам белән, кулларын чын шагыйрьләрчә болгый-болгый, Тукайга багышланган шигырен укыды.

Безне кем тыңлагандыр, ул шигырь һәм курай моңнары кемгә кирәк булгандыр, ул кадәресен белмим. Ләкин бүген шуны бик еш искә төшерәм: Тукай рухы ул көнне бик шат булгандыр. ■

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
Обращение
к народам всего мира
Татарстан
СПУТНИК
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
ЛЕНИНА
и история РКП(б)
ТАТАРС

ЯЛКЫНЛЫ ЮКА!

Юка дигән тәмле ризык республикабызның күп кенә районнарында юк. «Нәрсә соң ул?» – диләр кайчак аптырап. Ә Апас, Кайбыч, Кама Тамагында яшәүчеләр бер генә мәҗлесне дә әлеге ризыктан башка уздырмый. Бу якларда аны гади халык «җука» дип әйтергә ярата. Нинди ризык соң ул? Аны ничек пешерәләр? Бу сорауларга җавапны Кайбыч районының Кошман авылында яшәүче Лира апа Шәйхетдиновадан алдык.

Автор:
Руфия Фазылова

ЮКА ӨЧЕН ЮКӘ ӘЙБӘТ

Лира апага 71 яшь. Кошманда аны иң оста юка пешерүче дип таныштырдылар. Үзенә күрә бер йолдыз ул биредә: янына газета-журналлардан, телевидениедән дә килгәннәре булган. Барысына да бәйнә-бәйнә сөйләп, юка пешереп күрсәткән.

– Камыр куйганчы, мичкә утыннарны әзерләдем, камыр куйгач, ут төртербез, җаным, – дип каршы алды безне Лира апа. (Бу якларда кешегә, якын итеп, шулай дип эндәшәләр – **авт.**) – Ялкында пешкән юканың тәме дә, кыяфәте дә икенче төрле була. Кайберәүләр хәзер аны газ мичендә генә пешерә, ләкин мин: «Бу сезнең юка түгел, «ләпүшкә»,» – дим.

Юка, чынлап та, «лепешка»га охшаган, ләкин мичтә пешкәненең тәме бөтенләй икенче: күбек кенә, авызда эреп китә. Лира апа камыр өчен кирәк булачак ризыкларны барлап чыкты: бармакларын бөкли-бөкли, 7 төрле әйбер санады.

– Сөтне җылытырга кирәк, алай итсәң, камыр тизрәк кабара да, уңа да, – дип, кызлар җитезлеге белән эшкә тотынды ул. Сөтне зур кәстрүлгә салып, чүпрәне изеп болгатты. Өстенә сыек май, тоз, шикәр комы, йомырка салып, аларны болгатып, камыр басарга кереште.

– Кулга камыр ябышмый башлаганчы, басам, – ди Лира апа. – Безнең әниләр дә шулай эшләгән, ипине дә куаз камыр (ипи камыры – **авт.**) кулдан төшкәнче басканнар.

Унбиш-егерме минут дигәндә, Лира апа камырны басып бетерде. Бер сәгатьтән әзер булачак икән. Ә ул арада мич янына килдек. Безнең өчен иң күңеллесе шушы мизгел булгандыр, мөгаен! Менә ул олы мич! Авыл кешесенең иң якты хатирәләре, мөгаен, мич белән дә бәйледер. Һәрхәлдә, минем шулай. Ял көннәрендә мич башына менеп утырасың да ялкында яңа пешкән юканы сындырып, сөт белән ашыйсың. Өйгә татлы бер ис таралган була. Ә аннан, утын күмергә әйләнгәч, минем әни аны казан астына тарта иде. Мич төбенә катлы бәлеш ясалган табаларны тезә. Ә миңа морҗаны ябарга куша. Аннан соң, зур эш башкаргандай, мич башыннан төшәсең. Бер мизгелдә балачакка кайтып килгәндәй булдым...

– Мичне дә үзегез ягасызмы? Балаларга кушасызмы? – дим Лира апага. Ни дисәң дә, Лира апа өлкән яшьтә бит.

– Утының булса, мич ягуның ние бар аның, җаным? Авыр эш түгел бит. Без кечкенәдән мич ягып үстек. Юка өчен юкә агачы әйбәт. Аны җәйдән балалар махсус әзерләп куя. Коры, юка утынга ут төртүгә, кабынып китә. Хәзер без аны...

Ул да түгел, Лира апаның мичe «гөлт» итеп кабынып та китте. Остабыз канәгать итеп елмаеп куйды.

– Юканы еш пешерәсезме? – дим.

– Еш, җаным. Әле менә җирле үзидарә рәисе килгән иде: «Лира апа, районга Казаннан кунаклар килә, юка пешереп бирә алмассыңмы», – ди. Пешереп бирдем. Аллаһы Тәгалә исәнлектән аермасын, бер авырлыгы да юк аның. Кызым Ризидәнең улы – оныгым Рушанның кызы туды, шуның бәби ашына да юка пешердем. «Әби, син бик бәхетле: оныкчыкларыңның бәби чәенә ризыклар әзерләп йөрисең», – ди оныклар. «Исән булсам, аларның балаларына да пешерәм әле, Алла боерса», – дип шаяртам.

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

Редакция кухнясы

ЛИРА ШӘЙХЕТДИНОВАДАН ЮКА РЕЦЕПТЫ:

1. Сөт – 1 литр
2. Йомырка – 6–7 данә
3. Сыек май – 200 г
4. Шикәр комы – 2–3 аш кашыгы
5. Тоз – 1 аш кашыгы
6. Чүпрә – 50 г
7. Он – 500 г

«ЯЗМЫШ КУШКАЧ, КАРШЫ КИЛМӘДЕМ»

Лира апаның миче ялкынланып яна башлады. Ни өчендер бу мөлаем, ачык йөзле апаның язмышын да шушы утка охшаттым...

Тигез тормышта гөр килеп өч бала үстергән чакта Тәвис абый кинәт чирләп китә, дөнья куя. Ул якты дөнья белән саубуллашканда, Лира апага 40 яшь кенә була әле. Балалары хакына үзен кулга алып, тормышын дәвам итә ул. Дөрес, каенанасы да ярдәм итә, 34 ел бергә яшиләр. Ә аннан яңадан кияүгә чыга, һәм... кемгә диген – кияүләренә!

– Тәвис үлгәч, янә ир хатыны булырмын димәгән идем, – дип сөйләп китте Лира апа. – Иремнең сеңлесе Нурфидә дә яшьли – 47 яшендә вафат булды. Апалары чирләгәндә, безнең балалар гел аларда булды. Зур эшләрне бергә башкардык. Нурияне җирләгәч, ире Фәргатька хатын эзли башладылар. Аларда да – өч бала, кечкенәсе әле мәктәптә укый иде. Ир-атка ялгыз башына тормышны алып бару авыррак. Танышлар: «Бер-берегезне беләсез, балаларыгыз да якын туганнар, кавышыгыз», – дип, мине димләделәр. Язмыш кушуы булганмы, каршы килмәдем. Фәргатьнең төпле кеше икәнен белә идем. Балалары да кызганыч булды. Үги әни булып кем килер дә, ничек булыр, дидем. Шулай итеп Фәргать белән яши башлаганыбызга 18 ел була, Алла боерса. Матур яшибез, балаларыбыз да башлы-күзле булды. Барысы да диярлек диндә. Безнең янда төпчек улыбыз калды. Тудырган аналары булмасам да, мине чит итмиләр, рәхмәт яусын, бик тәрбиялиләр. Үземнең балаларга да, Фәргатьнекеләргә дә кунакка еш барабыз. Кайтып алалар, китереп куялар.

Лира апа, сүзеннән бүленеп, кисәү белән янган утынны таратып җибәрде. Мичтән чаткылар чәчелде.

– Мичне махсус камыр пешерү өчен калдырдыгызмы? Авылда тагын мичле кешеләр бармы? – дим.

– Кошманлылар юканы һәр мәҗлескә пешерә, шуңа да күпләр мичне бетермәскә тырышты. Һәр йортта булмаса да, күп кешедә бар әле ул. Олы кунак җыйганда, мичсез кешеләр күршеләренә, аралашып йөргән кешеләренә кереп пешерә юканы. Бик җайлы бит ул: башта ялкында юка, кабартма пешерәсең, аннан, күмерен тарткач, бәлешләр тыгасың. Мичкә берьюлы дүрт-биш таба сыя. Камыр кабарып, шәп булып пешә.

«ӘБИ, ЯНМЫЙМЫ ӘЛЕ?»

– Һи, күрче, җаным, ничек эшләпәләнеп тулды, – дип, Лира апа төреп куйган камырын күтәреп алды. – Пешерә башларга кирәк, югыйсә камыр картая.

– Картаю ничек була ул? – дим.

– Камырны кабаргач та, пешерергә кирәк. Соңарсаң, юка пешкәндә куырыла башлый. Матур кабармый.

Бер литр сөткә ясаган камырдан 15–16 юка чыга. Ялкында пешкән юканың камыры, чыннан да, юка булырга тиеш икән. Исеме дә шуннан алынган бит. Газ мичендә пешерүчеләр исә ул камырдан 12–13 юка чыгара, аларныкы калынрак була икән.

– Түгәрәкләрне уртача зурлыкта итәм, – дип, аңлатуын дәвам итә Лира апа. – Җәям дә табага салам, кабартып утырасы юк, ялкында үзе кабара ул.

Лира апа башта мичне көйләде: күмерне кисәү белән кырыйга этеп куйды. Аннан нәзек кенә телемләгән чыраны күмер өстенә атты: юка пешергәндә ялкын булсын өчен, моны махсус шулай эшлиләр икән. Ул арада Кошманның атаклы аш-су остасы табаны, кайнарлансын өчен, мичкә тыкты. Шуннан тиз генә түгәрәк җәйде.Табаны алып төбен майлады да өстенә түгәрәк җәймәне җәйде.

– Юка камырын мичкә тыгар алдыннан чәнечке белән берничә җирдән тишкәләп алырга кирәк, юкса ул кабарып китә, формасын югалта, – дип, пешерү нечкәлекләрен сөйләргә дә онытмады Лира апа. Һәм юканы мичкә тыкты. Теге чыралар гөрләп яна башлаган иде инде. Табаны әйләндереп торып, бер-ике минут дигәндә юкабыз пешеп тә чыкты. Асты да өсте дә килгән.

– Юкка мактамыйлар сезне, юкагыз бигрәк уңды, – дип, Лира апага соклануыбызны җиткердек.

– Төрле чак була, җаным. Кайчагында мич кызуырак булып, катырак кызарып та китә. Кунакка әзерләгән чак булса, андыйны табынга куймыйсың инде. Бала-чагага бирәсең. Шуңа күрә юка пешергән вакытта оныклар гел минем тирәдә бутала: «Әби, юка янмыймы әле?» – дип, сагалап торалар. Янмаса да, беренчесен башта аларга сындырып бирәм инде.

Кызык: юканы кисмиләр, кул белән сындырып кына ашыйлар. Аш вакы-

тында да аны табынга тәлинкәләргә түгәрәк килеш өеп чыгаралар. Безгә дә Лира апа кайнар юканы сындырып бирде. Авызда эри, үзе мамык кебек йомшак, үзе тәмле... Искиткеч!

Егерме минут дигәндә, Лира апа 12 юканы пешереп тә бетерде. Без бу күренешне елмаеп, сокланып күзәтеп тордык: «Мине тизрәк пешерегез, дип тора бит, җаным, көтеп тора», – дип, камыр белән «сөйләшә-сөйләшә» эшләде ул.

САБЫР АГАЧЫ

Лира апа чәй өстәле янына чакырды безне.

– Юка пешерергә кемнән өйрәндегез? – дим.

– Мәрхүм каенанам өйрәтте. Ундүрт яшемнән фермада эшли башладым, кияүгә чыкканчы, камыр ризыклары бик пешерми идем. Без күбрәк физик эштә идек. Әкрен-әкрен, каенанамнан карап торып, юканы үзем дә пешерә башладым. Кызларым, киленнәрем дә оста пешерә. Дөрес, төрле кешенең барыбер төрлечәрәк чыга, кулдан тора бит. Мин, мәсәлән, юканы баллы итмим. Ике-өч аш кашыгы шикәр комы җитә. Баллы булса, аны аш белән ашап булмый, чәй янына гына ярый торган була. Безнең авылда юканы бәйрәмгә түгел, ә гадәти көннәрдә ашар өчен дә пешерәләр, хәстәрләргә әллә нинди ризыклар кирәкми бит: сөт, күкәй һәркемдә бар, – ди Лира апа.

Өстәл артында сүзебез Кошманга барып тоташты. Кошман – Кайбыч районының иң борынгы авылларыннан берсе. Биредә атаклы бабачылар яшәгән. Уллары сөннәткә утыртырга дип, күрше районнардан да килгәннәр. Ләкин бүген инде авылда сөннәтче бабайлар калмаган. Заман шаукымына ияреп, ата-аналар малайларын дәваханәгә алып йөри башлаган.

– Соңгы сөннәтче бабайлар Хәлил, Шәкүр абыйлар иде, – дип, хатирәләре белән уртаклашты Лира апа. – Бу шөгыль буыннан-буынга күчеп килгән.

– Сөннәтче бабайлар беткәнгә ничә ел? – дим.

– Утыз еллар бардыр. Элек бит бәби табарга да дәваханәгә бармадык, сөннәткә утыртырга да. Аннан бу гамәлләрне өйдә эшләргә ярамый башлады, тыйдылар. Шулай итеп, сөннәтче бабайларның кирәге калмады. Менә шулай халыкның күп кенә йолалары югалып бара.

Кошман төзек авыл, район үзәгенә өч чакрым булгангамы, буш йортлар да юк биредә. Яшьләр дә авылда кала икән. Лира апаның үз оныгы Раушан да, өйләнеп, гаиләсе белән туган авылында, төп нигездә калган. Балалар бакчасына 25ләп бала йөри, ди.

– Халык зарланырга яратса да, тормышлар матур хәзер, җаным, – дия-дия, тагын бер чынаяк чәй ясады Лира апа. – Өйләр якты, газы-суы кергән, бәдрәф, душ та өйдә. Бер дә шәһәрдәгедән ким яшәмибез. Бабаем белән мәчеткә йөрибез. Кошманда ике мәчет эшләп килә, мәдрәсәбез дә бар. Ирләр, хатыннар, балалар – барысы да дин сабаклары укый. Безнең якта халык элек-электән тырыш булган. Бүген дә шулай. Кемдер өч сыер асрый, кемдер үз эшен алып бара. Өлкән яшьтәгеләр исә – дин юлында. Илләр тыныч, көннәр аяз булсын. Исән-сау булыйк. Калганы булыр. Пешербез юкасын да, бәлешен дә.

Лира апа безне озатырга чыккач, тагын бер акыллы сүзен әйтте:

– Оныгым Рушан бүген иртән сорый: «Әби, син күпне күргән. Ике ояда тормыш корган кеше. Гаиләдә тынычлык, иминлек булсын өчен нәрсә эшләргә кирәк?» – ди. «Улым, аның сере бик гади: гаиләнең нигезенә сабыр агачы салсаң, тыныч та, матур да яшәп була», – дидем. Сабыр итеп яшәсәң, барысы да була, сабырлык кирәк.

1. Камыр кабарган!

2. Бүләбез!

3. Җәябез!

4. Майлыйбыз!

5. Тишкәлибез!

6. Мичкә тыгабыз!

«ТАТАРСТАННЫҢ» АЛТЫН ЗАПАСЫ

Килешәсездер, йөз яшь гадәти генә итеп билгеләп үтелә торган бәйрәм түгел. Бигрәк тә сүз яраткан республикабыз турында барганда. Әйе-әйе, яшь һәм матур күренсә дә, Татарстанга тиздән, төгәл өч елдан, нәкъ бер гасыр була.

Исеме буенча гына түгел, рухы белән дә республиканың адашы булган журналыбыз юбилейга ФОТОБАНК әзерли. Аның сейфларында бәһасе булмаган хәзинәләр ята – олы тарихның әһәмиятле мизгелләре һәм шул тарихны тудыручы шәхесләр чагылыш тапкан аларда. Республика үзе һәм ул ирешкән уңыш-казанышлар һәм, гомумән, гап-гади тормышның бәхетле мизгелләре теркәлгән елъязма турында бара сүз.

Аклы-каралы фоторәсем проектларыннан соң, без Татарстанның иң яңа тарихына караган төсле фотоларга мөрәҗәгать итәргә булдык. 12 апрель кебек күренекле дата алдыннан Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясенә юл тоттык. Йолдызларга күз салу өчен түгел, аларның кайсылары биредә кунакта булганлыгын белү максаты белән. Анатолий Березовой, Георгий Гречко, Игорь Куринной, Александр Калери һәм, әлбәттә инде, Алексей Леонов – галәм масштабындагы йолдызлар!

Обсерватория директоры Юрий Нефедьев безгә әлеге «йолдызлы» визитлар турында сөйләде һәм үзенең фотоархивы белән дә уртаклашты.

2009 ел. Телескоп рефракторы гөмбәзе астында Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе директоры Юрий Нефедьев (уртада) космонавт Георгий Гречкога (сулда) обсерваториянең киләчәккә булган планнары турында сөйли. «Бүген шуны әйтә алам: әлеге киләчәк тормышка ашты», – ди, сигез ел үткәннән соң директор.

PRESSA.RU

Совет космонавты, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Георгий Гречко, орбитага 54 яшендә күтәрелеп, үзенчәлекле яшь рекорды куйган шәхес. Ул озак еллар дәвамында илдә галәмгә күтәрелгән иң олы кеше булып саналды. 2009 елда Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясендә ул татарстанлыларга үз «сәламен» калдырды. Космонавт утырткан эрбет үсентесе, сигез ел эчендә ныгып, агачка әверелде. Аны КФУ Планетарие янәшәсендә күрергә була.

2016 елның җәендә Казанга беренче мәртәбә Алексей Леонов (уртада) – легендар совет космонавты, тәүгеләрдән ачык галәмгә чыккан кеше килде. Татарстан башкаласында ул озакка тоткарланмады – бер тәүлек чамасы булгандыр, ләкин күп нәрсәгә өлгерде: Казан университеты белән танышты, Физика институты лабораториясенә күз салды, КФУ Планетариенә дә кагылды.



Алексей Леонов китапларында совет балаларының әллә ничә буыны тәрбияләнеп үсте. Күпләр «Выхожу в космос», «Загадки звездных островов» китапларын хәтерлиләрдер. Татарстанга космонавт буш кул белән түгел, әдәби бүләк белән килде. Аның «Земная и космическая живопись» альбомы Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе музее экспозициясен тулыландырды.

Казанга Леонов билгеле бер максат белән килде – ул «Айны өйрәнү һәм космик технологик мирас» Халыкара фәнни симпозиумына почетлы кунак сыйфатында чакырылган иде. КФУның актлар залында үз очышлары, ачык галәмгә чыгуы турында гаять кызыклы чыгыш ясады. Юрий Гагарин һәм Сергей Королев турында сөйләде. Әлеге вакыйгаларда турыдан-туры катнашкан кешенең үзен тыңлау өчен студентлар һәм мәктәп укучылары да килгән иде.

PRESSA.RU

Космик гаскәр ветераннары берлегенең Үзәк советы рәисе Игорь Куринной (сулда) һәм космонавт Анатолий Березовой (үзәктә) КФУ Планетарие нигезенә таш салу тантанасында. Әлеге чарада алар кулыннан «илебез космонавтикасын үстерүгә керткән шәхси өлеше өчен» мактау билгеләрен ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм КФУ ректоры Илшат Гафуров алды. «Космос хезмәтчәннәре өчен буләк» – «Җир шарындагы тормыш өчен» билгесен Анатолий Николаевич әнә шулай дип атады.

2009 елда Казанда «Астрономия һәм бөтендөнья мирасы: вакыт һәм континентлар аша» дип аталган халыкара конференция үтте. Сүз уңаеннан, форум БМО карары буенча Елның төп дөньякүләм вакыйгасы дип билгеләнде. Казан университетында дөньяның бөтен астрономик элитасы җыелды. Докладчылар арасында Георгий Гречко да бар иде. Ул беренчеләрдән булып конференциядә катнашучыларның ил җитәкчелегенә коллектив хатын имзалады. Хатта мәктәп программасына астрономия фәнен кайтарырга дигән таләп куелган иде.

«Кешеләр еш кына чиксезлек турында сөйлиләр. Әмма Җирдә аны әле беркем дә күрмәгән – мондый урыннар бездә юк. Чиксезлекне бары тик ачык галәмгә чыгып кына белергә була. Менә анда – чын чиксезлек!» Бу турында космонавт Александр Калери (сулда) Юрий Нефедьев белән әңгәмәсендә әйтте. Гомумән алганда, Александр Калери космоста 769 тәүлек була, 25 тәүлектән артыгы – ачык космоста. Казанга космонавт 2007 елда, «XXI гасырның космик чикләре» астрономик конференциясе ачылышына килгән иде.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Хәзәр каганлыгына **НИНДИ** кабиләләр кергән

«Китап киштәсендә» **НИНДИ** яңа әсәрләр бар

«Татарстан» журналының әдәби премиясе»ндә **КАЙСЫ** әсәр катнаша

Арча авыллары әнкәсе **КАЙСЫ** авыл

Үпкәләгән күл **КАЙДА** урнашкан

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

ХӘЗӘР КАГАНЛЫГЫ ҺӘМ БОЛГАРЛАР

Укучыларыбызны журналның алдагы саннарында таныштырып үткән һуннар белән төркиләр бүгенге көндә яшәп ятучы барлык төрки халыкларның уртак бабалары булса, Көнчыгыш Европа далаларына һуннар составында күчеп утырган Кубрат болгарлары исә Идел-Урал татарларының, Дунай болгарларының һәм Төньяк Кавказда яшәүче балкар, карачай халыкларының этник тарихында зур роль уйнаган, дигән идек. Кемнәр соң алар хәзәрләр, болгар тарихына аларның нинди катнашы бар? Мәкаләбездә шушы сорауларга җавап бирергә тырышырбыз.

Автор:
Фаяз Хуҗин

ХӘЗӘР КАГАНАТЫ ОЕШУ

Хәзәрләр дә, болгарлар кебек үк, Азов, Каспий һәм Кара диңгез далаларына һуннар белән күчеп утырганнар булса кирәк. Әмма аларның элгәреге тарихы Төньяк Кавказ, башлыча хәзерге Дагыстан җирләре белән бәйле. Биредә IV–V гасырларда ук Һун дәүләтенә кергән күпсанлы төрки телле халыклар – *барсиллар, савирлар, аварлар, болгарлар, хәзәрләр* яшәгән. VI гасырга караган язма чыганакларда Төньяк Кавказ җирлегендә оешкан Һуннар патшалыгы турында хәбәрләр сакланып калган. Аның башкаласы Дербент крепостеннан төньяктарак урнашкан Варачан исемле шәһәр булган. Гарәп тарихчылары калдырган язмаларда Сувар патшалыгы турында да хәбәрләр бар. VII гасыр урталарында Хәзәр дәүләте барлыкка килә. Хәзәрләр бер дәүләт чикләрендә үзләренә кадәр яшәгән барлык халыкларны берләштергәннәр.

Хәзәрләр турында иң борынгы язмалар VI гасырга карый. Алар башта тугандаш савирлар берләшмәсенә керәләр, соңыннан, көчәеп китеп, идарәне үз кулларына алалар. Хәзәр каганлыгының оешу тарихына караган кызыклы легендалар сакланып калган. Иоанн Эфесскийның «Тарих» дип аталган әсәрендә болай язылган: борынгы Скифия җирлегендә үзләренең ыруглары белән өч бертуган яшәгән. Араларыннан берсе, Болгар исемлесе, Рим империясе чикләренә яу белән чыгып китә, калган икесе алан кабиләләренең Берсилия дигән җирләрен яулап ала, һәм бу җирләрне Хазарик исемле өлкән туган хөрмәтенә «Хәзәр иле» дип атыйлар. *Савир, болгар* һәм *хәзәрләрнең* бер-берсенә якын телләрдә сөйләшүче тугандаш халыклар икәнен раслый торган тагын бер язма бар. X гасырда яшәгән хәзәр патшасы Иосифның Кордова хәлифәсе Абдеррахман III кә атап язган хатында, хәзәрләрнең Иафет улы *тогарма* ыруыннан (борынгы яһүдләр Тогарманы барлык төрки халыкларның нәсел башы дип санаганнар) килеп чыгулары турында әйтелә. «Тогарманның 10 улы арасында Хазар, Болгар һәм Савир исемлеләре дә бар иде», – дип яза Иосиф. X гасырда яшәгән гарәп географлары әл-Истахри һәм Ибн Хаукалның, болгар теле хәзәрләрнекенә бик охшаш, дигән сүзләре дә игътибарга лаек.

Хәзәр каганнары үзләрен Төрки каганатының, Ашина династиясенең дәвамчылары дип санаганнар. Төрки каганлык озак сугышлар нәтиҗәсендә хәлсезләнгәч, алар Кубрат хан үрнәгендә үз дәүләтләрен төзиләр. Бөек Болгар белән чагыштырганда, Хәзәр каганлыгы тормышка сәләтлерәк, озынрак гомерле булып чыга.

ХӘЗӘР КАГАНЛЫГЫ: БИЛӘМӘЛӘРЕ ҺӘМ ХАЛКЫ

Хәзәр дәүләте шактый зур территорияне биләп торган. Аның составына Каспий, Кара диңгез буе далалары, шул исәптән Кырымның зур өлеше кергән. Башында Кубрат хан торган Бөек Бол-

Фотолар автордан алынды

гар җирләре дә Хәзәр каганаты биләмәләренә әверелә.

Хәзәрләр илендә башлыча төрки телләрдә сөйләшүче төрле халыклар яшәгән. Тарихчы галимнәрнең бертавыштан әйтелгән фикеренчә, илнең төп халкын *болгарлар* һәм *аланнар* тәшкил иткән, дәүләт тотучы хәзәрләр исә сан ягыннан артык күп булмаган. Аланнар – иран телле *сарматларның* дәвамчылары, бүгенге осетиннарның бабалары – төркиләр дәүләтендә яшәп, ике теллелеккә өйрәнәләр, бер өлеше, *хәзәрләр* һәм *болгарлар* белән кушылып, милли йөзләрен югалтуга дучар ителә.

Хәзәр илендә яшәүче халыкларның бер өлеше күчмә, икенче өлеше утрак тормыш алып барган. Күчмәннәр башлыча мал асраучылык белән шөгыльләнгән, утрак тормышлы халык иген иккән, җиләк-җимеш һәм яшелчә үстергән. Шәһәрләрдә һөнәрчелек һәм сәүдә белән көн күргәннәр.

Каганлыкның беренче башкаласы Бәләнҗәр исемле булган. Аның археологик калдыклары – территориясе таш һәм кирпеч диварлар, биеклеге унар метрга җитә торган башнялар белән әйләндереп алынган Югары Чирюрт шәһәрлеге. Ул хәзерге Махачкала шәһәре тирәсендә урнашкан. Каганлык чикләре киңәя барган, аның үзенә дә көньяк күршеләре даими һөҗүм итеп торган, шул сәбәпле бераздан башкала төньяккарак, Сәмәндәр шәһәренә күчерелгән. Ләкин ул да үзенең башкала статусын озак саклап кала алмаган.

ГАРӘП-ХӘЗӘР СУГЫШЛАРЫ

Үсеп-көчәеп баручы яшь Хәзәр дәүләте Византия империясенең һәм Гарәп хәлифәтенең җитди көндәшенә әверелә. VII гасыр ахырларында ук ислам байрагы астында дөньяны яулап алырга омтылган гарәпләр Албанияне (хәзерге Азәрбайҗан территориясе) һәм Әрмәнстанны – хәзәрләрнең көньяк күршеләрен басып алалар. Чират хәзәр иленә җитә. VIII гасыр башында кабынып киткән гарәп-хәзәр сугышлары озакка сузыла, кан күп коела. Бик зур сугышларның берсе 737 елда була. 120 мең сугышчыдан торган гарәп гаскәрләре хәзәрләр җиренә бәреп керәләр һәм Сәмәндәр шәһәрен камап алалар. Басып алучылар бар халыкны Кавказ таулары итәгеннән һәм Каспий буе түбәнлегеннән кысрыклыйлар, төньяк тарафка куып чыгаралар. Хәзәрләрнең бик күп авыллары һәм шәһәрләре талана, яндырыла, халкы үтерелә.

Каган һәм аның гаскәрләре Дон елгасы тирәсенә, Түбән Идел буйларына качып китә. Алар артыннан туктаусыз сугышлардан арыган кабиләләр дә кузгала, яңа җирләргә күчеп утыра. Хәзәрләр бирегә элеккеге болгар җирләрен кулга төшерәләр. Шундый тынычсыз шартларда болгарларның бер өлеше, алар белән бергә *савир (сувар), барсил (берсил, берсула)* һәм *бәләнҗәр (бәрәнҗәр)* кабиләләре дә, үз җирләрен калдырып, Идел буйлап югарыга күтәреләләр. VIII гасыр уртасында алар хәзерге Татарстан җирләренә килеп чыгалар. Әмма болгарларның шактый өлеше Хәзәр дәүләте составында кала.

Нарын-Кала крепосте. Дербент. V гасырда фарсы патшасы тарафыннан салынган. VIII гасырдагы гарәп-хәзәр яулары вакытында аның ныгытмалары сугышның нәтиҗәсендә зур роль уйнаган.





Фил сөягеннән ясалган шкатулка. Кордова. Б.э. ның 966-968 еллары.

Көбәле хәзәр сугышчысы. X гасыр. М.В. Горелик реконструкциясе.

PRESSA.RU

Кордова хәлифәте тәңкәләре.
X гасырның икенче яртысы.

Саркелдагы казу эшләре вакытында табылган
пыяла мәрҗән һәм беләзекләр.

ХӘЗӘР КАГАНЛЫГЫНЫҢ ЧӘЧӘК АТУ ЧОРЫ

Дәвамлы сугышларда хәлсезләнгән дәүләтне тулысынча саклап калу өчен хәзәр каганы Гарәп хәлифәте белән солых төзи. Килешү шарты буенча ул ислам динен кабул итә. Яңа дин болгарлар арасында да тарала.

Илдә күптән көтелгән тынычлык урнаша. Иделнең Каспий диңгезенә коя торган урынында төзелгән Итил шәһәре дәүләтнең яңа – өченче башкаласына әйләнә. Ул каганлыкның иң зур һәм иң матур шәһәрләреннән берсе була. Иделнең бер кушылдыгы аны ике өлешкә бүлеп ага. Шәһәрнең бер өлешендә, үзенең бик зур һәм матур сараенда каган яши, шунда ук аның тугрылыклы хәрби дружинасы урнаша. Хан сарае тирәсенә балчык белән сылап эшләнгән өйләр һәм тирмәләр сыенып утыра. Шәһәрнең бу өлеше биек диварлар белән әйләндереп алынган була.

Елга аръягында һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр яши. Борынгы чыганакларда сакланып калган мәгълүматларга караганда, башкаланың бу ягында 10 меңләп мөселман яшәгән. Алар өчен биек манаралы Җәмигъ мәчет һәм тагын утызлап мәхәллә мәчетләре салынган. Шул тирәдә үк христианнар, яһүдиләр һәм мәҗүсиләр яшәгән, ягъни элеккеге Төрки каганатындагы кебек үк, хәзәрләрдә дә халыкка теләсә нинди дин тотарга рөхсәт ителгән. Кызганыч, Итилнең урнашкан урыны бүгенгә кадәр сакланмаган, күрәсең, ул Каспий диңгезенең чираттагы күтәрелеше (трансгрессиясе) вакытында тулысынча юылып юкка чыккандыр.

Тора-бара Хәзәр каганлыгы көчле, икътисады һәм мәдәнияте нык үскән дәүләткә әверелгән. Күрше славян кабиләләре – поляннар, древляннар, северяннар, вятичлар хәзәр патшасына салым түләп торырга мәҗбүр ителгәннәр.

Илнең хуҗалык тормышында игенчелек, терлекчелек һәм һөнәрчелек белән берррәттән, эчке һәм тышкы сәүдә зур роль уйнаган. Көнчыгыш Европада хәзәрләр иң беренчеләрдән булып көмеш акчалар суга башлаганнар.

Мәдәни үсешнең мөһим күрсәткечләреннән берсе – язмачылык. Хәзәрләрдә Көнчыгыш Европага борынгы төркиләр алып килгән рун язмасы киң тарала. Археологларга рун әлифбасы кулланып язылган балчык чүлмәкләр, бакыр-көмеш савытлар, сөяктән ясалган әйберләр еш очрый. Төзелеш кирпечләрендә дә рун тамгалары күп. Дагыстандага Хумара шәһәрлегендә рун язмалары таш плитәләрдә сакланып калган. Шунысы кызганыч, әлегә кадәр белгечләр ул язмаларны укый алмыйлар.

САЛТЫ-МАЯК АРХЕОЛОГИК КУЛЬТУРАСЫ

Хәзәр каганлыгында яшәүче халыклар калдырган матди мирас (шәһәрлекләр, торулык урыннары, каберлекләр) Салты-Маяк археологик культурасы истәлекләрендә ачык чагыла. Әлеге истәлекләре урнашкан мәйдан Хәзәр каганлыгы территориясе белән тәңгәл килә. Елга ярлары буенда урнашкан күпсанлы торулыкларны, шәһәр һәм крепость хәрабәләрен, каберлекләрне казыганда тупланган материаллар халыкның әкренләп күчмә тормыштан утрак тормышка күчүләре турында сөйлиләр, шәһәрләр барлыкка килү процессын күрсәтәләр.

IX гасыр башында хәзәрләр Византия осталары ярдәме белән Дон елгасының сулъяк ярында Шаркил (Саркел) дигән крепость-шәһәр төзиләр. Ул шәһәр почмакларында турыпочмаклы башнялар куелган кирпеч диварлар белән әйләндереп алынган. Шәһәр эчендә күпсанлы торак урыннары – ярымземлянкалар ачылды. Шаркилда башлыча гаскәриләр һәм һөнәрчеләр яшәгән. Сәүдәгәрләр Византия, Кырым, Кавказ арты, Урта Азия илләре белән сәүдә иткәннәр. Хәзәр сүдәгәрләре атаклы Бөек ефәк юлы белән Бөек Идел юлын тоташтыручылар сыйфатында эш йөрткәннәр.

Археологлар авыл тибындагы торулыкларны өйрәнгәндә сука төрәннәре, урак-чалгы ише авыл хуҗалыгы

Җайдак сыны. Салты-Маяк культурасы. IX гасыр. Ростов өлкәсе.

Хәзәр путалары. Алтын йөгертелгән көмеш. IX–X гасырлар.

кораллары табып алалар. Шуңа күрә, төрле чорларда Урта Идел буйларына күчеп утырган болгарлар күчмәннәр булмаган, алар игенчелек белән, гомумән, утрак тормыш белән күптән таныш булганнар инде, дип әйтә алабыз.

Салты-Маяк культурасына караган каберлекләрне өйрәнү хәзәрләр тарихының тагын бер үзенчәлекле сәхифәсен ачарга ярдәм итте. Күмү йоласының төрлелеге һәм күмелгән кешеләрнең антропологик үзенчәлеге ягыннан әлеге каберлекләр ике төркемгә бүленәләр. Беренче төркемгә караган долихокраннарны (озынча йөзлеләрне) катакомбаларда, икенчеләрен, брахикраннарны (уртача йөзлеләрне) гади чокырларда күмгәннәр. Белгечләр фикеренчә, үлгән кешеләрен катакомбаларда аланнар, гади чокырларда болгарлар күмгәннәр. Соңгы елларда тагын бер төркемгә караган каберлекләр ачылды. Биредә башларын изге Мәккәгә каратып мөселманнар күмелгән. Салты-Маяк культурасы җирлегендә мөселман каберлекләре ачылу гарәп язучыларының, хәзәрләр 737 елгы солых нигезендә ислам диненә күчәргә мәҗбүр ителде, дигән хәбәрләрен археология материаллары белән нигезләп куйды.

Шулай булса да, ислам дине хәзәрләрдә ныклап тамыр җәйгән, дип әйтә алмыйбыз әле, чөнки IX гасыр башында, Обадий каган идарә иткән чорда, илдә рәсми рәвештә яһүд дине кабул ителә. Обадийның бу реформасы болгарлар арасында кискен ризасызлык тудыра, чуалышлар башланып китә һәм болгарларның бер өлеше яңадан Урта Иделгә күчеп китәргә мәҗбүр була.

ХӘЗӘР ҺӘМ ИДЕЛ БОЛГАРЛАРЫ

Хәзәрләрнең Идел болгарлары тарихына ни катнашы бар, дигән сорауга төгәл җавап бирергә вакыт җитте. Хәер, игътибарлы укучы ул сорауга үзе дә җавап бирергә әзер дер инде. Гомумиләштереп, шуны әйтә алабыз: Хәзәр каганаты составында яшәп яткан болгар, савир, барсил, бәрәнҗәр халыклары төрле сәбәпләр аркасында Идел-Кама буйларына күчеп утыралар һәм IX–X гасыр чигендә барлыкка килгән Болгар дәүләтенең этник нигезен тәшкил итәләр.

Болгарлар үзләре белән бергә рун язмачылыгы һәм ислам дине кебек югары мәдәни казанышларны, төркиләрнең рухи дөньясына, идарә итү системасына караган борынгы традицияләрен дә алып киләләр.

970 нче елларга, ягъни Хәзәр каганатының җимерелүенә китергән рус кенәзе Святославның һөҗүменә кадәр Болгар иле хәзәр каганатына номиналь рәвештә булса да буйсынып яши. Әмма ничек кенә булмасын, хәзәрләр белән болгарлар арасында сәяси, икътисадый һәм мәдәни бәйләнешләр бервакытта да өзелеп тормый.

Хәзәр каганы Иосиф. М.В. Горелик реконструкциясе.

КЫЙПЫЛЧЫКЛАРДАН ҖЫЕЛГАН ТАРИХ

Автор:
Луиза Янсуар

Corpus* берсеннән-берсе затлы, мавыктыргыч китаплар белән даими сөендереп килә. Матур әдәбият булсынмы, non-ficton жанрымы – һәр басмасы үзенә бер затлы деликатес. Шуларның кайберләре белән бүлешергә булдым.**

* Corpus – нәшрият йорты.
** non-ficton – «уйлап чыгарылмаган», реаль вакыйгаларга нигезләнгән; әдәби жанр.

ТАРИХНЫ КЕШЕЛӘР ЯЗА...

БАРБАРА КИНГСОЛВЕР. ЛАКУНА.

Игътибарымны аннотациясе җәлеп итте: «Лакуна» каһарманы Гаррисон Шепардка гаҗәеп язмыш насыйп була: ул атаклы рәссам Диего Ривера фрескаларына акшар әзерли, аның тормыш иптәше, шулай ук рәссам Фрида Калоның якын дустына әверелә, Лев Троцкийның сәркатибе булып эшли. Алар белән үткән еллар аның өчен эзсез калмый, билгеле...»

Фрида Кало белән Диего Ривера исемнәре калкып чыкса, битараф кала алмыйм. Шулай да, бераз шикләнеп, исемнәр уйнатуга, аларны укучысын кызыктыру өчен генә кулланугa кайтып кала торган очсызлы бер китч булмасын, дип укый башладым да... баштанаяк күмелдем. Әсәр үзенең күптөрле катламнары, архитектоникасы һәм киеренкелектә тота белүе белән җәлеп итте. Һәм – үзироние, авторның фактлар, тарихи детальләр белән гаять сакчыл эш итә белүе белән дә. Биредә алар – бихисап. «Нью Йорк Таймс»тагы мәкаләләрдән башлап, китапта сурәтләнгән шәхесләрнең архив документларына кадәр җентекләп өйрәнелгән.

Барбара Кингсолвер дистәгә якын роман, шигырь җыентыклары, эссе һәм документаль жанрга караган китаплар авторы. Россиядә, дөрес, аның исеме киң катлам укучыга әллә ни таныш түгел. «Лакуна» әнә шул бушлыкны тутыруы белән дә игътибарга лаек.

«Фрида, вы всегда говорили, что самое важное в человеке – то, о чем не знаешь. Тогда и самый главный фрагмент любой истории – тот, которого не хватает».

Китапның төп лейтмотивы – кыйпылчыклардан җыелган тарих. Гап-гади бер адәм баласының язмышы ничек итеп кешелек тарихына барып тоташа да, дөнья картинасын үзгәртә. Әнә шул турыда сөйли безгә һәркемгә билгеле һәм бары тик китапта гына яшәүче персонажлар аша Кингсолвер. Гитлермы ул, Ленинмы, Генри Фордмы... – барысы да гап-гади кешеләр. Һәм дөньяны тетрәткән инкыйлабларны да, сугышларны да әнә шул гади кешеләр башлый. Фашизмга да алар нигез сала. Үлем лагерьларын да алар төзетә. Үзләре кебек үк башка адәми затларны да алар җәфалый. ЦРУ, ФБР, ФСБларга да алар нигез сала...



Әнисе Америкадагы ирен калдырып, кечкенә улын җитәкләп Мексикага килеп төпләнүдән башланып китә әсәр.

«Вначале были ревуны. Они всегда разражались воплями в первый час рассвета, когда кромка неба только принималась светлеть».

Акрынлап малай да, әнисе дә боларның нибары Мексикада киң таралган маймылларның бер төре генә булуын аңлап ала. Үсә төшкәч, Гаррисон инде алардан курыкмый да башлый. Әнисе белән бергә килеп урнашкан бай мексикалы Энрике йортында ул артык кашык булудан туктамый, билгеле, әмма биредә мәктәптә алмаган белемнәрне алыштырырлык китапханә булганлыктан, тормышыннан әллә ни зарланырлык сәбәпләр дә тапмый. Бай плантаторлар кичләрен җыелышып, дөнья хәлләре турында сөйләшәләр, тиздән дөньяны инкыйлаблар дулкыны басып алып, коммунизм киләчәгенә хафаланалар. Бер колагыннан кереп, икенче колагыннан чыкса да, бу хәбәрләр Гаррисонның аңына кереп урнашалар.

Әмма аны дөньяда хәзер барган вакыйгалар әллә ни кызыксындырмый. Ә менә борынгы Америка – бик нык дулкынландыра. Җитмәсә, өйләрендә пешекче булып эшләүче мексикалы яшь кенә егет Леандро да бу мавыгуга күмер өстәп тора. Ул әнисенә һәм үги әтисенә әллә ни кирәге булмаган үсмерне тәрбияләргә алына – аңа борынгы ацтеклар, майяларның риваятьләрен сөйли, җимереп ташланган тулы бер цивилизациянең аяныч калдыкларын күрсәтә, Мексика кухнясына караган ризыкларны әзерләргә өйрәтә.

Көн дә диңгезгә чумлап, су асты дөньясында гизүче Гаррисон шулай бервакыт сәер җир асты мәгарәсенә юлыга. Мәгарә аша йөзеп чыгып, борынгы ацтеклардан калган ярымҗимерек корылмаларга килеп чыга. Леандро ничек кенә ул урынга кермә, дип кисәтмәсен, Гаррисон инде тыелып кала алмый. Диңгездә

PRESSA.RU

су күтәрелгәндә томаланып торган, су төшүгә, яңадан юл ачылган бу борынгы дөньяны «лакуна» дип атый егет. Һәм Мексика тарихына тагын да тирәнгәрәк кереп чума. Ул конкистадорлар харап иткән бу дөньяны Америкада калган үз дөньясыннан да артыграк күрә башлый.

Ләкин көннәрдән бер көнне, көтмәгәндә-уйламаганда, әнисе аны кабат Америкага алып китә. Энрике йортыннан качып, Америкадагы бер бай әфәнде аларга алып биргән кысан гына фатирда яши башлыйлар. Монда Гаррисон үзен читлектәге җәнлек кебек хис итә. Әмма язмыш аны бу урынга юкка гына китермәгән булып чыга: йортларыннан ерак түгел генә урнашкан базарда ул бервакыт Мексика авылларындагы ханымнарча милли күлмәкләр киеп алган, чәчләрен толымлап үреп, баш очына төеп куйган бәләкәй генә гәүдәле хатын-кызга юлыга. Бу җитез ханымны базар хатыннары үз итеп бетерми: «Аның ирен кеше ашый дип сөйлиләр, – дип пышылдашалар. – Җитмәсә, революционер үзе...»

Әнә шулай итеп Гаррисон Фрида Кало белән очраша. Аннары, очраклы гына рәвештә, бу ханымның ямьнаты таралган ире Диего Ривера фрескалар ясаган бинага килеп чыга һәм аның акшар изүчесенә әверелә. «Каян акшарны болай әйбәт изәргә өйрәндең?» – дип сорый Ривера егеттән. «Мексика камыр ашларын әзерли-әзерли», – дип җавап бирә Гаррисон.

Барбара Кингсолвер вакыйгаларны шулкадәр гадәти итеп сурәтли, ялгыш кына да әсәрдәге хәлләрнең тормышчанлыгында шикләнмисең. Һәм тагын бер әһәмиятле үзенчәлек: без бер генә урында да Фрида, Диего һәм тиз арада роман тукымасына атлап килеп керәчәк Троцкийларның үзебез кебек үк гадәти кешеләр булуына аптырамыйбыз. Һәм менә шушы гадәтилек танылган шәхесләргә дә, алар тудырган тарихка да башка ракурстан карау мөмкинлеге бирә. Гадәти ракурстан.

Кингсолверның төп максаты да шул: Монтесумалар ничек ялгышса, конкистадорлар сәясәтен ничек корса, Ленин, Сталин, Порфирио Диаслар да – нәкъ шулай ук. Бернәрсә дә үзгәрми, тарих кабатлана гына. Кешелек ышанырга теләгән иллюзияләр кабатланган кебек үк. Кайчандыр Кортесны безгә яңадан кайтырга тиешле Аллабыз, дип кабул иткән ацтеклар коммунизмга табынучы Гаррисон замандашларыннан – Ривера, Троцкийлардан бернәрсәсе белән дә аерылмый.

«Это был настоящий задушевный разговор. О наших предках, чья жизнь возможно, была важнее и полнее нашей. А если нет, то как им удалось нас одурачить? Фрида предположила – им помогло то, что они ничего не записывали. По словам доктора Гамио, жители Теотиуакана не знали письменности.
– Поэтому нам не прочитать их дневников, – заключила Фрида, – и злых писем, которые они посылали неверным любовникам. Тут она права. Ни сожалений, ни мелочной зависти. Лишь каменные статуи богов и величественные здания. Нам доступна лишь их безупречная архитектура, а не несовершенная жизнь. Но художнику, чьи полотна сплошь исповеди и проповеди, спорить об этом странно. Без ревности и сожалений, они были бы пусты».

Фрида Кало яшь дустының көндәлекләр алып баруын хуплый. Аннан да бигрәк, аны күләмле әсәр язарга өнди. Икесе дә өзелеп яраткан борынгы дөнья – майялар белән ацтеклар Америкасы турында. Һәм Гаррисон, аянычлы вакыйгалардан, Троцкийның үлеменнән, Ривераларга төшкән бәлаләрдән соң, яңадан АКШна кайтып, ниһаять, озак еллар узгач, үзендә Фриданың васыятен үтәргә көч таба. Дустының: «Гринго» буларак язма безнең тарихны, хәер, син аны алай яза да алмаячаксың инде, син үзең дә Монтесумалар нәселеннән бит хәзер», – дип шаяртып әйткән сүзләре чынга аша.

Һәм менә шушы урында «лакуна» сүзенең мәгънәви спектрына мөрәҗәгать итәсе килә. Латинчадан турыдан-туры тәрҗемә итсәк, иңкүлек, чокыр дигәнне аңлата ул. Физиологиядә – чит-читләре булмаган тукыма белән органнар арасындагы бушлыклар, аралыклар. Анатомиядә – кеше органнарының өслегендәге чокырлар, әйтик, тез йомрысы. Лингвистикада – тексттагы бушлык, «ак тап», аңлаешсыз урын.

Димәк, мәгарә аша тарихның «ак таплар»дан торган ягына чыга да Гаррисон, аны яңабаштан яза башлый. Көндәлекләре дә әнә шуның өчен кирәк аңа, димәк, без культ, йә каһәр объектына әйләндергән шәхесләр артында кешеләр барлыгын янә бер кат ваемлар өчен. Яхшы гамәлләр кылганнармы алар, яман эшләрме – Барбара Кингсолвер хөкем карары чыгару тарафдары түгел. Ул – бушлыкны тутыру тарафдары.

РЕАЛЬ ШӘХЕСЛӘР ТУРЫНДА – РЕАЛЬ ВАКЫТТА

ПАТТИ СМИТ.
ПРОСТО ДЕТИ.
ПОЕЗД М.

Көнбатыш сәнгатенең соңгы ярты гасырдагы торышы, тарихы белән кызыксынучылар өчен Патти Смит исеме яхшы таныш. Аны «панк-рокның әнкәсе» дип атап йөртәләр. Шагыйрь, рок-җырчы, шул чорның атаклы фотографы Роберт Мэплторпның алыштыргысыз моделе, кыскасы, узган гасырның 70нче елларыннан башлап, Энди Уорхол, Аллен Гинзберглар белән беррәттән, Америка сәнгатенең культ дәрәҗәсендә исәпләнгән эре фигурасы бу ханым. Бездә аның иҗатын хәзер шулай ук үз итеп, танып киләләр. Гәрчә бу кызыксыну массачыл булмаса да.

Патти Смит очрагында Corpusның non-fiction жанрындагы басмасы хакында сүз алып барабыз, билгеле. Биредә сүз реаль шәхесләр турында реаль вакытта бара. Дөрес, һәр ике китап та соңыннан, инде күп еллар узгач, истәлекләр рәвешендә язылса да, аларның көндәлекләргә, үз замандагы язмаларга нигезләнгән булуы шик уятмый. Монда 60 нчы еллардагы Нью-Йорк, Энди Уорхолның атаклы «Фабрика»сы, Вудсток, шул чорның даһи шагыйрь-битниклары, музыкантлар... – барысы да бар. Патти Смит вакыйгаларны бер линиягә тезеп, горизонталь буенча үстерә кебек тоелса да, асылда, ул төрледән-төрле «иңкүлекләр»гә кереп-чыгып йөри – шул рәвешле ул чор тарихында әллә ни билгеле булмаган детальләрне, нюансларны үз урынына утыртып куя, ягъни бушлыкны тутыра. «Ак таплар» калдырмаска тырыша. Бер үк вакытта, бу тарихның бары тик үз күзлегеннән теркәлгән булуына – үтә индивидуаль иҗанлегенә дә басым ясый. Әмма ул шуның белән кызыклы да бит.

Дусты Роберт Мэплторпның үлеменнән башланып киткән китап безгә иң башыннан ук һичнинди битлек-киемнәрсез, йөз яшерүләрсез бар моңсу ялангачлыгында ачыла.

«О Роберте сказано много, а будет сказано еще больше. Юноши будут подражать его походке. Девушки будут надевать белые платья и оплакивать его кудри. Его будут проклинать и боготворить. Осуждать или романтизировать его крайности. В итоге правду о нем узнают через его творчество: произведения художника – это и есть его материальное тело. Тело, которое не чахнет. Тело, которое люди судить не властны: ведь искусство поет о Боге и, по большому счету, только Ему и принадлежит».

Патти Смит чыннан да, үзе яшәгән чорның бөтен яклары хакында да яшермичә сөйли, димәк, тарихи тукыманың буш калган урыннарына үз буяуларын да өсти. Безгә исә шул чор тудырган сәнгать тә, шәхесләр дә аңлаешлырак була бара. Кайсы образның ничек туганын, кемнәр тәэсирендә оешканын, текстларда, җырларда ярылып яткан интертекстуаль катламнарның «аргы якларын» – фонын күрсәтә ул безгә. Һәм бу – аның тарафыннан укучысына, тыңлаучысына карата бәяләп бетергесез әһәмияткә ия адым.

Патти Смит иҗатын яратучылар яхшы белә: ул чорлар арасындагы бушлыкларны өнәми, тамырларны барларга, хәтерне уяу сакларга өнди. Бу хакта сүзләре дә, гамәлләре дә сөйли. Рембо, Камилла Клодель, Жан Жене өчен йоклар алдыннан догалар укымый калмавы турында еш искә ала ул. Икенче китабында әлеге үзенә кадерле булган шәхесләрнең ватаннарына кылган сәфәре турында да, каберләренә килүе хакында да бәян итә. Без, Патти Смитка ияреп, Фрида Калоның Койоакандагы Зәңгәр йортында булып кайтабыз, Жан Жене, Сильвия Плат, Артюр Рембо, Юкио Мисима каберләрен зыярәт кылабыз.

Әмма... ничек кенә моңсу башланмасын, моңсулыкка урын юк бу китапларда. Гөрләп торган тормыш агышы, яшьлек дәрте һәм максимализмы, әзләнүләр, югалтулардан соң, яңадан алга ыргылулар. Чөнки алар үзләренең дөньяны үзгәртергә килгән затлар булуына ышаналар. Бер интервьюда Патти Смит китаплары хакында болай дигән иде: «Без ничек яшәдек, шул атмосфераны аз гына тудыра алсам, мин шат булыр идем. Җүләр булганбызмы, артык акыллымы, мөһим түгел, иң мөһиме – булганбыз. Һәм болар барысы да әле һаман минем хәтер тәлинкәмдә әйләнә...»

Бу буынны бездә, гадәттә, һәртөрле бозыклыклар белән бәйләп күзаллыйлар. Эчкечелек, наркомания, җенси тотнаксызлык һ.б. Әмма Патти Смит безне үзләре яшәгән дөньяның аргы ягына чакырып, аны бар ялангачлыгында күрсәтеп, гаҗәпләндерә генә түгел, ә сискәндерә дә: биредә иҗат кешесенең, тормыш чынбарлыгына яраклашырга теләмичә, камыт киюдән баш тартып, тырышып-тырмашып, сәнгатькә хезмәт итүе чагыла. Көннән-көн. Төннән-төн. Көндезләрен эш аты кебек җигелеп, фатир өчен тиен-миеннәр эшләп тапсалар, төннәрен иҗат итәләр алар. Бу – озакламый безгә киләчәк һәм дөньябызны тамырдан үзгәртәчәк капитиалистик чынбарлык картинасы.

Үзләре яшәгән мәмләкәткә карата карашлары анык, кискен Патти Смит буынының:

«Китай бушевал;
миром овладело безумие,
И юный Далай-Лама взирал
на свой мир, охваченный огнём.
Небесная Слава была разбита –
о, позор, позор!-
И так без конца...
Упавшая звезда Тибета,
Сострадание и мудрость
в разрушенной стране Шангри-Ла.
...Но, милый, – там, в земле Импал,
Мы, казалось, были в полном
порядке-
Потому что мы стали собой
и отрастили крылья
В 1959 году».

«Безгә бернәрсә дә җиңел бирелмәде. Һәм җиңел бирелергә тиеш тә түгел. Беркемгә дә». Бу сүзләрне ул үзләренә карата да әйтә, үзенә кадәргеләр хакында да. Китаплары аша төрле тукымаларны – шигърият, музыка, рәсем сәнгате, фотографияне берләштерә һәм, үткән белән бүгенге арасында күперләр салып, аларны тотыштыра алганы өчен генә булса да сокланам мин Патти Смитка. Ә инде без капиталистик һәм башкаларны таптап үтү сәясәтенә генә корылган цивилизация буларак кабул итәргә эяләшкән Америкада бүген дә шигърият белән барлык кешелек тарихына сакчыл, яратулы мөнәсәбәт яшәвен күрсәтә алуы өчен – рәхмәттән башка сүз әйтә алмыйм.

Ул һәммә нәрсәгә сәламәт акыл һәм билгеле бер дәрәҗәдәге ирония белән карарга өнди безне. Һәм бу китаптан соң, син үзеңнең дә шулайрак фикерли башлавыңа төшенәсең:

«– Салютую вам, Акутагава,
салютую вам, Дадзай, – сказала
я и осушила чашку саке.
– Не тратьте своё время
на нас, – словно бы сказали они, –
мы всего лишь бродяги.
Я снова наполнила маленькую
чашку и выпила.
– Все писатели – бродяги, –
прошептала я. – Пусть однажды
меня причислят к вам».

Патти Смит хаклы. Нигә артык катлауландырырга дөньяны. Без бит чынлап та – тарих буйлап узып баручы юлчылар гына. «Ак таплар» калдырып, һәм урыны-урыны белән бушлыкны тутырып...

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ



«Татарстан» журналының әдәби премиясе

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

PRESSA.RU

Айгөл Абдрахманова Кайбыч районы Борындык авылында туып-үсә. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетына укырга керә һәм филология белгечлеген үзләштерә. Бүгенге көндә «Ялкын» журналының әдәби мөхәррире булып эшли. Казан дәүләт университетының юридик факультетында һәм аспирантурада белем ала. Республика вакытлы матбугатында журналистик язмалары белән дә, хикәяләре белән дә даими күренеп тора. Сезгә аның конкурска юлланган ике хикәясен тәкъдим итәбез.

Айгөл Абдрахманова

КАРАШ

Атна дәвамында явымсыз һава торачак, дисәләр дә, төштән соң табигать кискен үзгәрде: күк йөзен тоташ болытлар каплап алды һәм пыскып кына көзге салкын яңгыр яварга тотынды. Кояш әле бер, әле икенче болыт артыннан үрелеп, җиргә нурларын сибәргә тырышты, җылы карашы белән кешеләрне иркәләргә теләде, әмма усал болытлар, алагаем олы куллары белән кояшның самими йөзен каплап, аңа тирә-юньне нурландырырга ирек бирмәделәр. Пыскып кына торган яңгыр отыры котырып көчәйде һәм ишеп-ишеп яварга тотынды.

Синоптикларны кисәтеп тә тормыйча килгән әлеге әрсез кунак бик күпләрне авыр хәлдә калдырды. Юка гына киенгән һәм кулчатырларын алырга кирәксенмәгән кешеләр коеп яуган яңгырдан качарга урын эзләп чабыштылар. Мин дә, үтәли җилдән һәм әрсез яңгырдан сакланыр өчен, үземне үзем кочаклап, тукталышка кереп ышыкландым. Гадәттә, гел вакытында йөрүче автобусым, бүген, миңа үч иткәндәй, соңара. Пәлтәмнең соңгы җебе юешләнде дигәндә, ниһаять, офыкта өзелеп көткән «якын дустым» – 47 нче маршрут автобусы күренде. Уку йортыннан чыкканда ук әзерләп куйган унсигез сум акчамны учыма кыстым да, автобусны каршыларга дип, юл кырыена чыгып бастым.

Ишекләр ачылды. Мин берничә секундтан җылы автобус эчендә идем инде. Озак сайланып тормыйча, шофёр янындагы буш урындыкка барып утырдым. Юл озын һәм күңелсез. Үземне бераз мавыктырырга дип, сумкамнан чыгарып, китап караштыра башладым. Бер бит, ике, өч... Кинәт үземдә кемнеңдер көйдергеч карашын сиздем. Берәү текәлептекәлеп миңа карый. Тагын бераз шулай барса, мине үтәли тишеп чыгачак бит бу! Күтәрелеп караргамы, әллә карашы белән үземне «ашатып» барыргамы? Мин, сизмәгәнгә салышып, китап битләрен актарырга керештем. Ләкин кайда инде сиздермәү?! Моңа кадәр салкыннан күшеккән тәнем кисәк кенә эсселәп китте, сулышым ешайды, яңакларыма ут капкандай дөрләп янарга тотынды, карашымны китап битенә юнәлдерергә никадәр генә тырышсам да, керфекләрем мине тыңламады һәм күзләрем үзләреннән-үзләре сихри караш иясенә төбәлделәр.

...Менә ул! Менә ул – минем хыялымда йөргән сөйгән яр! Имәндәй нык гәүдә, озын буй, төпсез кара күзләр, сызылып киткән кара кашлар, дулкын-дулкын кара чәчләр... Мин, сихерләнгәндәй, егеттән күземне ала алмыйм. Кешегә шулай карап торырга ярамаганлыкны акылым белән аңласам да, йөрәгем тыңламый. Шулай да, бар ихтыяр көчемне туплап, карашымны автобус эчендәге реклама кәгазьләренә юнәлтәм. Ниндидер таныш хәрефләр, таныш сүзләр. Мин аларны укыган булам, ләкин нәрсә турында булулары аңыма барып җитми.

...Өстемдә һаман шул ук караш. Түзмәдем. Кабат күтәрелеп карарга булдым. Безнең карашларыбыз тагын очрашты. Юл буе читтә басып барган чибәр егет минем каршыма килеп басты. Хәлиткеч мизгелнең – танышуның котылгысызлыгын уйлаудан йөрәгем күкрәк читлегеннән чыгып очардай булып тибәргә тотынды. Санаулы вакыт аралыгында, хыял канатларына утырып, күккә ашкандай булдым, егетнең күзләреннән сирпелгән нурларда коендым, икебезнең арага сузылган аллы-гөлле салават күпере аша хыялыма таба атлап китәргә җыендым. Егет күзләремә туп-туры карап елмайды да:

– Туташ, гафу итегез, сез билет алмадыгыз һәм инде кайчаннан бирле минем урынымда утырып барасыз. Әлеге урындык кондукторлар өчен махсус куелган, – диде.

Көтелмәгән сүзләрдән мин өнсез калдым. Күкнең җиденче катында адашып йөргән хыялым, баскыч таба алмаганлыктан, дөбердәп җиргә егылып төште һәм мин, миңгерәгән кешедәй, шаккатып, егеткә төбәлдем. Кондуктор минем җавапсыз торуыма ачулана ук башлады. Йөзе кырысланды. Шулай да итагатьле булырга тырышып:

– Урынымны бушатыгыз әле?! – диде.

Әлеге сүзләр аңыма барып җиткәндә, дикторның «Академик Парин тукталышы» дигән игъланы яңгырады. Учымда килгәнлектән юешләнгән унсигез сумны кондукторга тоттырдым да, ишеккә атылдым. Ничек автобустан төштем, ничек юл аркылы чыктым – берсен дә хәтерләмим.

Җәяү кайтып барганда гына оялудан кызарып чыкканлыгымны сизеп алдым. Кайта-кайта, юләрлегем үземә үк көлке булып тоела башлады. Йөземә ирексездән елмаю җәелде.

PRESSA.RU

ҖӨЙ

Гөлназ елга буена кер чайкарга төшкәндә, августның салкын кояшы, кул изәп, офык артына кереп бара иде инде. Көтү күптән кайткан, капка төбендә утыручы әби-бабайлар да, салкын төшә башлагач, өйләренә кереп киткәннәр, ә яшьләр кичке уенга чыкмаган әле. Авылда – тынлык. Көндез тәмамланмаган эшләрне төгәлләү өчен менә дигән вакыт.

Җәйнең соңгы көннәре булуга карамастан, җилнең әсәре дә юк. Шунлыктан елга өсте тып-тын, чип-чиста. Көзгене хәтерләтә. Гөлназ су өстендәге сурәтенә күз салды: көрән чәчләр, җәядәй бөгелеп торучы кашлар, туры борын, яшел күзләр, яңа пешкән күмәч кебек күпереп торучы алсу иреннәр... һәм сул як битендә, бу дөньяның гел матурлыктан гына тормавын искәртеп, өстән аска сузылган җөй. Әлеге җөй – якын дусты Миләүшәнең «бүләге».

...Гөлназ белән Миләүшә кечкенәдән якын дуслар булдылар. Балалар бакчасында да, мәктәптә дә гел бергә йөрделәр. Миләүшә шаянлыгы белән гел игътибар үзәгендә, ә Гөлназ дустының шәүләсе кебек кенә иде. Мәктәпне тәмамлаган елның җәендә авылга кунак егете Марат кайтты. Зәвыклы, үзен шәһәрчә тотучы егет күп кызларның йөрәгенә ут салды. Билгеле ки, ике дус кыз да шул учакның ялкынында яндылар. Миләүшә егетне үзенә каратыр өчен ни генә эшләмәде. Максатына ирешкән дә кебек булды, чөнки Марат, клубка чыгуга, иң беренче алар янына килә, сөйләшеп утыра иде. Әмма көннәрдән бер көнне Марат клубтан Миләүшәне түгел, ә Гөлназны озата кайтты. Гөлназ, дустының да егеткә гашыйк икәнлеген белсә дә, Маратның үзен сайлавына сөенеп туя алмады. Егет белән кыз арасында дуслык җепләре үрелә башлады, ә бераздан алар, бер көнгә дә аерылмас дәрәҗәгә җитеп, бер-берсенә ияләштеләр. Миләүшә дустының мәхәббәтен үзенә хыянәт дип кабул итте. Тора-бара ике кыз арасындагы дуслык суынды, ә аннан бөтенләй юкка чыкты. Күрше урамнарда гына торсалар да, сирәк очраштылар, сирәк аралаштылар.

Август ахырында Гөлназга 18 яшь тулды. Бу истәлекле вакыйганы дуслар белән табигатьтә билгеләп үтәргә булдылар. Гөлназ әле кайчан гына җан сердәше булган Миләүшәне дә туган көненә чакырмый булдыра алмады.

Котлаулар, бүләкләр, дуслар, учак, шашлык – заманча туган көн хәзер шулайрак уздырыла бит. Гөлназның көне дә шундый булырга тиеш иде. Башта барысы да әйбәт кенә барды. Бер кат ашап, кәефләнеп алган яшьләр музыка астында хәрәкәтләнә башладылар. Биеләр, ә нәкъ менә хәрәкәтләнделәр. «Табын» янында Гөлназ үзе, энекәше һәм Миләүшә генә утырып калды. Гадәттә гел елмаеп кына торучы Миләүшәнең йөзе бик борчулы күренә иде. Ул, ни эшләргә белмәгәннән генә, алмага үрелде. Аны кулында әйләндергәләп утырды-утырды да, пычак алып, кабыгын әрчи башлады. Аннары, бер карарга килгәндәй, Гөлназны аулакта сөйләшергә чакырды. Як-ягына ялт-йолт каранучы кыз ышаныч уятмаса да, Гөлназ бернинди шик-шөбһәсез дус кызы артыннан агачлар арасына, ешлыкка кереп китте.

– Кәмит уйнап туймадыңмы әле?

Бу сорауны биргәндә Миләүшә имтихан алучы кырыс укытучыны хәтерләтте. «Нинди кәмит?» – дип кайтарып сорау башны җүләргә салу булыр иде. Гөлназ әңгәмәдәшенең ни турында сүз алып барганын яхшы аңлады. Ул, бу сөйләшүне күптәннән көткән булса да, Миләүшәнең сүзләренә ни дип җавап бирергә, үзен кая куярга белмичә аптырады. Аннан, кулларын кесәләренә тыгып, әңгәмәдәшенә карамыйча, әкрен генә сөйли башлады.

– Беренчедән, юк, туймадым. Икенчедән, бу кәмит түгел, ә чын тормыш. Телисең икән, театр. Без тамашабызны уйный башладык кына әле. Беренче пәрдә, бәлки, туй белән тәмамланыр, – диде.

Шундый әрсез җавап ишетергә әзер булмаган Миләүшә ачуыннан кызарып чыкты, күзләрендә нәфрәт уты кабынды, һәм, һич көтмәгәндә, кулындагы пычагы белән Гөлназның йөзенә кизәнде. Бары бер хәрәкәт һәм Гөлназ битенең меңкисәкләргә бүлгәләнгәндәй авыртуын, әрнүен сизде. Үзәк өзгеч авырту һәм кан. Миләүшә эшләгән эшеннән курыкты булса кирәк, пычагын аяк астына ташлап, авылга таба йөгерде. Ә Гөлназ, битен учы белән каплап, дуслары янына чыкты. Аннан хастаханә, табиблар һәм җөй. Мәңгелек җөй. Башта гел кызарып торган битеннән оялып, кеше күзенә күренмәскә тырышса да, соңрак Гөлназ яңа кыяфәтенә ияләште.

Җөй Маратны куркытмады, киресенчә, кызга ныграк кына бәйләде. Бүген Гөлназның атсыз бармагында шул бергәлек билгесе булып алтын балдак ялтырый. Укып бетереп, эшли башлагач, егет белән кыз өйләнештеләр...

Су өсте әле дә чип-чиста. Бары Гөлназның кулындагы сөлгеләр генә елганы дулкынланырга мәҗбүр итәләр. Әллә хатирәләргә бирелеп онытылып киткәннән, әллә эшне тиз тотканга, керләр тиз чайкалып бетте.

Басмадан чыгып китәр алдыннан, Гөлназ кабат су өстенә – көзгегә күз салды. Кара әле! Чибәр икән бит ул! Бөтен җире килгән. Хәтта җөе дә бик сөйкемле икән. Юк, җөй түгел ул. Ә иптәш кызының туган көн «бүләге»! Бу дөньяда матурлык белән янәшә явызлык та, көнчелек тә яшәвен искәртеп торучы гомерлек истәлек!

PRESSA.RU

СЕЗ БЕЗНЕ ЮГАЛТМАДЫГЫЗМЫ?

«Татарстан» журналы архивыннан теләсә кайсы номерны алдыру өчен, milyaushanb@tatmedia.com электрон адресына түбәндәге мәгълүматны күрсәтеп заявка юллагыз: бандероль алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, почта индексы, китерү адресы, кирәк журналның номеры.

Заказыгызны алганнан соң, редакция журналны «Россия почтасы» ФДУП аша Сезгә җибәрә. Бандероль Сез күрсәткән адрес буенча киләчәк. Аның килеп җитүе турында хәбәр алганнан соң, Сез, элемтә бүлекчәсенә барып, акча түләргә тиеш буласыз: бер данә журнал өчен 150 сум + китерү бәясе. Бәяләр 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә. Тулырак мәгълүмат түбәндәге телефон номеры буенча: (843) 222-09-79 (өст. 14-48).

03, 2017

12, 2016



08, 2016

07, 2016

06, 2016



05, 2016

03, 2016

01, 2016

12, 2015

05, 2015

11, 2014

02, 2014

08, 2011

03, 2011



02, 2011

10, 2010

07, 2010

05, 2010

Реклама 16+

⟨ ИСКЕ МУ АВЫЛЫ ⟩

«Татарстан» журналы, кызыклы атамалы татар авылларын, аларның тарихын һәм бүгенге яшәешен яктырту максаты белән, яңа сәхифә башлады. Сез дә безгә үз авылларыгызның хикмәтле яклары, гыйбрәтле хәлләре, уңган-булган кешеләре турында яза аласыз.



Арча районы Иске Му авылы

PRESSA.RU

АВЫЛЛАР ӘНКӘСЕ

Без, журналистлар, – «могезле» кешеләр, кызыклы хәлләр турында язарга яратабыз. Арча районының Иске Му авылына барыр алдыннан шундый үзенчәлекләрне сораштык. «Әйе, безнең авылда гаҗәп бер кеше бар», – диделәр. Күрәзәче-фәлән түгелме дип уйлаган идем, юк, бөтенләй мин уйламаган, гайре табигый бер көч турында сүз барган икән.

Фото: Ната Смирнова

Автор:
Руфия Фазылова

АСФАЛЬТ БУЛГАНДА, БЕТМИБЕЗ!

Иске Му (төрле чыганакларда төрлечә языла: «Муй» да «Му» да – **авт.**) бик борынгы авыл. Әле Казан ханлыгы төзелгәнче, биредә удмуртлар яшәгән. Бу турыда рәсми документлар сакланып калган. Казан ханлыгы оешканнан соң удмуртлар, татарлар йогынтысына бирелеп, ислам диненә күчкән. Кесмәс елгасы янынарак урнашыр өчен, якын-тирәдән татарлар бу тирәгә күченеп килгән. Авыл татарлашса да, аның исеме элеккечә калган: «Му» – удмуртча «су», «муй» «җир» дигәнне аңлата, ягъни Иске Су, яки Иске Җир. 1600 нче елларда Иске Му авылы бик зур булган. Крестьяннарга җир җитми башлагач, кешеләр арырак китеп урнашкан. Күрше Чөмә Елга, Гөберчәк, Мөрәле, Сеҗе, Курсабаш һәм башка авылларның әнкәсе булып нәкъ менә Иске Му тора, диләр. Бу турыда тарихи документлар да сөйли. Авылның урнашу урыны да кызыклы: Иске Му уртада утыра, тирә-якта, Мудан ике-өч чакрым ераклыкта, башка авыллар тезелеп киткән.

Инде авылның бүгенгесенә килсәк, Иске Му зур түгел: 47 йорты бар, йөздән артык кеше яши. Биредә мәктәп, балалар бакчасы, мәчет, кибет, ФАП та юк, соңгысы гомумән беркайчан булмаган да икән. Ә менә башлангыч мәктәп агымдагы уку елында гына ябылган.

– Безнең балалар үскән 1990 нчы елларда, башлангыч мәктәп гөрләп эшләде, – дип сөйләде миңа Иске Муга утыз дүрт ел элек килен булып төшкән Галия апа Хисаметдинова. – Һәр гаиләдә диярлек өчәр бала үсте. Алар барысы да үзебезнең мәктәптә укыды. Бишенчегә исә Курсабаш урта мәктәбенә йөрделәр, өч кенә чакрым ул безгә. Тик ул буын үсеп беткәч, авылда балалар азайды. Бүген бездән Курсабашка тугыз бала укырга йөри. Башлангыч мәктәпнең бер ягында балалар бакчасы иде, аны да яптылар. Бүген яшьләрнең һәркайсында машина бар, балаларын үзләре белән күрше авылларга йөртәләр. Район өчен дә шулай яхшырак: экономия бит.

Галия апа безгә Иске Муны күрсәтеп чыкты: ике ел элек авылның өч урамына да асфальт юл кергән. Моңа кадәр юлсызлыктан интеккән халык рәхәткә чыккан.

– Асфальт юл булды, болай булгач, безнең авыл бетмәячәк! – дигән сүзне Иске Муда бик күп кешедән ишетергә туры килде.

Минем исә тизрәк «гайре табигый көчкә ия» кеше белән танышасым килде. Кем ул? Нәрсә эшләргә сәләтле?

«ӘРВАХЛАР КАЙТКАН!»

Ул да түгел каршыбызга буш чиләкләрен тотып бер ир-ат килеп чыкты: нишләптер авыз үзеннән-үзе ерылды. Бу абзыйны берәр режиссер күреп алып, аның белән фильм төшерсә, һичшиксез, дан казаныр иде. Койган да куйган Леонид Гайдай геройларының берсе. Баш киемен кыңгыр салган, беркатлы итеп, елмаеп торып кычкыра-кычкыра сөйләшә... Алай гына да түгел, урам уртасына басып, туган авылы турында үзе язган шигырьләрен укып китте. Гаҗәп кеше! Чынлап, якын итеп әйтүем... Таныштык: Хәкимов Бакый абый икән, гомере буе Иске Муда яши.

– Су юкмы әллә сездә? – дим, абзыйның буш чиләкләренә ымлап.

– Су кертеп булмый әле. Хөкүмәттән ярдәм көтәм. Зыян юк үзе, физзарядка гына ул. Шәһәр кешеләре акча түләп спортзалларда шөгыльләнә, минем бушка ул. – Һәм рәхәт итеп көлеп җибәрә.

Бакый абый, үзе әйтмешли, туган авылының «смотрящие». Атна саен яшьләр белән хоккей уйный, төрле чаралар оештыралар. Илле ике яшенә җитүенә карамастан өйләнмәгән, әнисе белән яши икән.

– Болай урамда тормыйлар, өйгә кереп сөйләшик, – дип, ул безне йортына чакырды. Туксан яшен тутырган Җөфәрбикә апа Хәкимова да улы кебек җор телле булып чыкты:

– Әллә кәләш алып кайттымы, дип торам. Әйдә, узыгыз, уз, – дип түргә чакырды. – Мин, балалар, авылның иң өлкән әбие булам инде. Тагын миннән ике яшькә зуррак бер апа бар, тик ул килен генә. Иске Муда туып-үстем, яшәдем. Без үскәндә башлангыч мәктәптә 80 бала укыдык. Бер безнең класста гына да 24 укучы иде. Сугыштан соң, кеше кимеде. Бөек Ватан сугышына безнең авылдан 85 кеше китте, шуның 40 гы гына әйләнеп кайтты. Барысы да узды баштан, черек бәрәңгесен дә ашадык... 1943 елдан 1952 елга кадәр колхозда бригадир булып эшләдем. Никадәр җирне корчаңгылы атлар белән эшкәртеп чыгып, чәчү чәчтек. Трактор дүрт-биш авылга бер генә иде. Уракка карт әбиләр дә чыкты. Түздә халык, түзде, тату яшәдек. Хәзер тормышлар матур, Аллага шөкер...

Җөфәрбикә апа тормыш иптәше Гыйлемхан абый белән 7 бала: биш ул белән ике кыз үстергән, бер улы вафат булган. Тормыш иптәше дә мәрхүм инде. Балалары читтә, бер Бакый абый гына туган нигезендә калган.

– Өйләнмәде бит, бер тапкыр да, – диде әби, көрсенеп. – Яшьләр белән йөреп кенә булмый, картлык көнендә ялгыз каласың, – дим дә бит.

– Өйләнәм әле, әни, борчылма. Пенсиягә тагын сигез елым бар бит, – дип кеткелдәп куйды Бакый абый.

– Баштa йорт салгач, диден, хәзер пенсия, ди. Үзе генә кала инде, – дип борчылып куйды карт ана.

Туксан яшен тутырса да, Җөфәрбикә апаның хәтере бик яхшы. Әллә кайчан булган вакыйгаларны да төгәл итеп сөйли. Бүген авылда ничә кеше яшәгәнен дә санаган, әнә.

– 87 кеше яши, 33 йортта көн саен ут яна, сеңлем. Җәй көне тагын бер ун йортка кайтып яшиләр. Андыйларны ирем: «Әнә, әрвахлар кайткан», – дип әйтә иде. Хәзер мин дә шулай дим. Әрвахлар түгел инде, үзебезнең авыл кешеләре ул, төп нигез, дип, ата-ана йортларын бетермиләр. Яңарталар да кайтып яшиләр.

«1943 елдан 1952 елга кадәр колхозда бригадир булып эшләдем», – ди Җөфәрбикә апа Хәкимова.

– Безнең авыл бик тату, – дип сүзгә кушылды Бакый абый. – Эшләгән кешегә эш тә бар. Мин үзем фермада нәселле таналар карыйм. Өйдә хәзер мал тотмыйбыз инде, әни дә картайды. Читкә китәргә әллә ничә тапкыр әйткәннәр иде, юк, Иске Муымны ташлый алмыйм. Бик күңелле яшибез. Үзебезнең хоккей командабыз бар, район турларында җиңүләр яулыйбыз. Авыл уртасында боз ясадык. Егетләр хәтта уенчыларның фамилияләре язылган формаларга кадәр алып кайтты. Җәен волейбол уйныйбыз.

Шуннан Бакый абый янә туган авылына багышлап язылган шигырьләрен укырга кереште.

PRESSA.RU

«Умартачылык эшенә каенатам өйрәтеп калдырды», – ди Фәридә апа Гарифуллина.

«НУР ИҢДЕ...»

Авылның үзенчәлекле кешесе әллә шушы абзыймы икән дисәм, юк икән, Галия апа Хисаметдинова безне икенче йортка – Гарифуллиннарга алып китте. «Серле» гаиләнең башлыгы Раниф абый гомере буе колхозда эшләгән, механизатор булган. Ә Фәридә апа – башлангыч мәктәпнең атаклы укытучысы. Заманында Иске Муда мәктәп төзүне башлап йөргән кеше ул. Бүген икесе дә лаеклы ялда инде.

– Бу авылга килен булып төшкәч, берничә ел Курсабашта рус теле укыттым, – дип сөйләде Фәридә апа. – Ул чакта балалар җәяү йөри, шул исәптән башлангыч сыйныфлар да. Язын, көзен юл юк, бик авыр иде. Район мәгариф бүлегенә баргач, башлангыч мәктәп булса да ачуларын сорадым. Шуннан ата-аналардан имзалар җыеп, район администрациясенә илттем. 1984 елда башлангыч сыйныфларны Иске Муда укытырга рөхсәт бирделәр. Шулай итеп, иске бер өйдә нәниләр белән дәрес өйрәнә башладык. 1987 елда яңа мәктәп бинасы төзелде. Авыл өчен бик зур вакыйга булды, чөнки ул елларда йорт саен диярлек өчәр бала иде. Чын мәгънәсендә авылның чәчәк аткан чоры дип әйтә алам.

Фәридә апаның мөгаллимлек стажы 37 ел. Лаеклы ялга чыккач, үзе өчен икенче дөнья ачкан ул – ислам динен өйрәнгән. Биш ел мәдрәсәдә укыган, гарәп телен үзләштергән. Бүген биш вакыт намазын калдырмый. «Гайре бер көч» дигәне менә нәрсә икән:

– Бу хәл мин пенсиягә чыккач булды, – дип сөйләде Фәридә апа. – Йоклап ятам, күзне нур чагылдыра. Кояш нурларына карагач, күз йомыла бит, нәкъ шулай. Уянып киттем, өндәге кебек: хәтта күзләр камашкан иде. «Нәрсә булды икән бу?» – дип озак уйладым. Авылыбызның өлкән яшьтәге абыстаена бу хакта сөйләдем: «Сиңа дин юлына басарга кирәк, нур иңгән бит сиңа. Бу хакта кешегә сөйләмә», – диде. Шуннан догалар өйрәнә башладым, мәдрәсәгә укырга кердем. Гаҗәп: әмма гарәп телен шулкадәр тиз өйрәндем ки, укытучыларым да аптырады. Миннән алдарак өйрәнә башлаган кешеләр гарәпчә Коръәнне укый белми, ә мин беләм. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә кушканча яши башладым.

Фәридә апа Гарифуллина Иске Муның иң хөрмәтле кешеләреннән берсе: мәетләрне юа, ашларда Коръән укый. Тавышы моңлы, әһәңле аның.

– Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булгандыр дим, – ди Фәридә апа. – Бу эшләрне башкарырмын дип кем уйлаган?! Авылның өлкән яшьтәге остабикәсе үлеп киткәч, аның эшен бер апа алып барды. Ике ел элек яшьтәшем вафат булды, авылда мәет юарга кеше юк. Теге апа чирләп киткән. «Әйдә, син эшлә, булдырасың», – диделәр. Уйлап торырга вакыт юк иде, алындым. Шуннан бирле бу эшләр минем өстә инде...

Фәридә апа белән күбрәк аралашкан саен гаҗәпләнүем арта гына барды. 65 яшен тутырып килүче бу мөләем ханым авылның атаклы умартачысы да икән: 45 оя корты бар. Дөрес, аңа бу эштә Раниф абый да булыша, бал аерткан чорда балалар да кайта икән.

– Умартачылык эшенә каенатам өйрәтеп калдырды, – ди Фәридә апа. – «Килен, өйрән, тормышыгыз баллы булыр», – дия иде. Җәйләрен Раниф гел эштә булгач, каенатама корт карашырга үзем булыша идем. Гомер буе бергә яшәдек без.

– Әти үлгәч, кортлар да үлеп бетте, – дип сүзгә кушылды Раниф абый. – Бер өйрәнгәч, корт асрауның әллә ни авырлыгы юк, шул бал аерткан да гына йөгереп йөрергә кирәк. Аннан малай күрше авылдан ике оя корт алып кайтты, менә шулар үрчеп китте. Әле менә март башында кортларны кышлаудан чыгардык. Арт бакчада яшиләр хәзер. Кояш җылысына чыга да башладылар инде.

Фәридә апа кортлар янына алып чыкты. Чынлап та, оялары тирәсендә кортлар тыз-быз очып йөри, май уртасы диярсең! Хәтта якын барырга да курыктык. Ә Фәридә апабыз уйлап та бирми, сөйләшә-сөйләшә, оялар янына китте.

– Сез безнең авылга җәй килегез, бик матур монда. Бакча артында инеш ага, таулар, ике чакрым ераклыкта урман башлана. Урам тулы каз-бәбкә, чеби була. Без үзебез дә утызлап каз алабыз. Инде менә беренче партия чебиләр алып кайтырга заказ бирдем. Килегез, күрерсез.

МӘЧЕТ ЮК, МУЛЛА БАР

Иске Муның киләчәге белән кызыксынабыз: «Авылда яшьләр каламы?»

– Бар, минем улым да безнең белән яши, югары белем алгач, «Ак барс» агрохолдингында бухгалтер булып эшли башлады, – ди Галия апа. –

«Аллаһы Тәгалә исәнлекне биреп, тагын да күбрәк гыйлем тупларга язсын», – ди Ольга һәм Илгизәр Сәмигуллиннар.

Тагын берничә яшь кеше бар. Миңа калса, авыл бетмәячәк әле. Арчага егерме чакрым, йөреп эшләргә дә була. Асфальт юл бар, тыныч, рәхәт монда.

Клубтан кала, бер социаль объект та юк дип, авыл халкы зарланыр дигән идем, бер зар да ишетмәдем. Хәтта мулла, авылның мәчете булмауны да проблемага санамый.

– Гаетләрне мәктәп бинасында уздырабыз, – диде Илгизәр абый Сәмигуллин. – Ә җомга намазына җыелмыйбыз. Бездә элек мәчет булган, совет власте чорында бетерелгән. Дөресен генә әйткәндә, аның бит мәчеткә йөрердәй кешеләре дә юк: картлар бик аз, авырыйлар, яшьләрнең вакыты юк. Алар күбрәк спортка бирелгән. Минем үземнең дә ике улым бар. Гаиләләре бар инде. Авылга кайтсалар, хоккей, волейболга дип чыгып китәләр. Ярар, анысы да начар түгел, иң мөһиме: тәртипсез юлда йөрмәсеннәр. Килерләр әле дингә дә.

Илгизәр абыйга 62 яшь, тормыш иптәше Ольга апа белән ике ул, бер кыз үстергән. (Иске Муда бөтен гаиләдә өч бала бит, Сәмигуллиннар да традицияне бозмаган – **авт.**) Ир белән хатын лаеклы ялда булсалар да, өч сыер, үгез-бозаулар асрыйлар, атлары да бар.

– Саву аппараты бар безнең, – ди Ольга апа Сәмигуллина. – Башта үзебез дә алган идек, аннан өч сыер асраучыларга район да аппарат бүләк итте, бик җайлы. Без эшләргә өйрәнгән инде. Хәзер ялкау булмаган кешегә печән җыярга була, сатып та алабыз. Сөтне әлегә кадәр литрына 22 сумнан алдылар. Сыер малы үз-үзен аклый. Элек үгезләр күпләп тота идек, хәзер итнең бәясе төште, файдалы түгел. Ә болай авыл җирендә яшәргә була, сәламәтлегең булып, иренмичә эшләргә генә кирәк.

– Иске Муның сыерлары ничек мөгери? Авыл исемендәгечәме? – дим.

– Әйе, «му» диләр инде. Халыкта авыл тарихы белән бәйле бер мәзәк тә йөри: имеш, борынгы бабаларыбыз, нинди исем кушарга аптырашып торганда, каралтыдан бер сыер башын тыгып «му» дигән. Авыл агайлары: «Ярар, сыердан узып булмый, аныңча булсын», – дигәннәр. Шуннан Му исеме калган, имеш.

Ольга апа Сәмигуллина керәшен татары икән. Кияүгә чыкканнан соң, ислам диненә күчкән. Үзләре әйткәнчә, «дингә кереп барулары».

– Күңелдә иман гомергә булды, – дип сөйләде Илгизәр абый. – Читтән торып Арча мәчетенең мәдрәсәсендә укыдым, гарәпчә өйрәндем. Мәчет булмагач, минем төп эш – зиратны карап тору, җеназа укып, мәетләрне җирләү, ашлар уздыру. Аллаһы Тәгалә исәнлекне биреп, тагын да күбрәк гыйлем тупларга язсын...

Иске Му үзенә бер утрау кебек тоелды миңа. Бердәм булып, зарланмыйча, үзләренчә, һәр туган көнгә сөенеп яшиләр. ■

Сәмигуллиннар ихатасы.

PRESSA.RU

НИЧЕК БОРГАЛАСАҢ ДА...
«ТАТАРСТАН»НЫ ТАТАР
ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ УКЫГЫЗ!
Реклама 16+
ТАТАРСТАН
КАМСКИЙ
СУДАК
ТАТАРСТАН

М А Х С У С   П Р О Е К Т

— 20нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

Марат Насыйбуллин, «Кара Алтын предприятиесе» ЯАЖ генераль директоры, май аенда үзенең 65 яшьлеген билгеләп үтә.

Нефтьче – тумыштан килгән сәләт

Фәнис Вәлиев, «Нефтеконсорциум» ЯАЖ генераль директоры

Хөрмәтле Марат Галимуллович, Сезне 65 яшьлек юбилеегыз белән котлый алуыма мин ихлас күңелемнән шат!

Безнең танышлыгыбыз күп еллар элек башланды. Әлеге еллар дәвамында Сезнең максатчан, тәвәккәл, намуслы булуыгыз, алгы сафта атларга, яңа, катлаулы бурычларны хәл иткәндә бөтен тәҗрибәгезне кулланырга тырышуыгыз – гомумән, Сезне сирәк профессионал һәм бик яхшы кеше итә торган барлык сыйфатларыгыз – үзгәрешсез калды.

Нефть тармагында Сез инде күптәннән хезмәт куясыз. Егерме елдан артык Татарстандагы иң яхшы кече нефть компанияләренең берсенә җитәкчелек итәсез. Аларның сафка басу чоры республиканың нефть тармагында иң катлаулы, әмма зарури үсеш этапларыннан булды. Ул чакта, 1990 нчы еллар ахырында, зур җитәкчелек тәҗрибәсенә ия зат буларак, Сез яңарак кына оештырылган «Кара Алтын» компаниясенең кыска вакыт эчендә аякка басуына һәм нефтьне табу, туплау, әзерләү, төяп-озатуны үз эченә алган инфраструктура булдыруга ирешә алдыгыз.

Бүгенге көндә нефть табу күләме буенча «Кара Алтын» республиканың иң уңышлы кече нефть компанияләре исәбенә керә. Һәр КНК*неке кебек үк, аның да төп бурычлары – ярлыланган нефть чыганакларына һәм аз рентабельле скважиналарга икенче гомер бирүдән, елдан-ел нефть табу күләмнәрен арттырудан, төрле дәрәҗәдәге бюджетларны тулыландырудан, төбәк экологиясен яхшыртуга зур өлеш кертүдән гыйбарәт. Татарстанның нефть тармагы каршындагы югары максатлар технологияләрне даими камилләштерүне, инновацион якын килү һәм белемнәрне куллануны таләп итә. Сез җитәкчелек иткән компания елдан-ел югары нәтиҗәләр күрсәтә һәм әлеге яңа юнәлешләрдә дә нәтиҗәле эшли.

Сезнең профессиональ биографиягездә горурланырлык сәбәпләр җитәрлек. Төрле дәүләт грамоталары һәм бүләкләр дә шул турыда сөйләп тора. Мин ышанам: тәҗрибәгез, һөнәри осталыгыгыз киләчәктә дә авыр чыгарыла торган запасларга ия нефть чыганакларын үзләштерү белән бәйле бик күп проектларда таләп ителер. Һәм юбилеегыз алдыннан Сезгә чын йөрәктән бер генә планны да шуннан башка тормышка ашырып булмый торган нәрсәләрне – ныклы сәламәтлек, дуслар һәм фикердәшләр таянычын, якыннарыгызның мәхәббәтен һәм кайгыртуын, гаилә учагы җылысын телим!

Реклама

* КНК – кече нефть компаниясе.

Хәмзә Баһманов, «Татэнерго» АҖнең генераль директор урынбасары, май аенда үзенең 60 яшьлеген билгеләп үтә.

Валерий Абрамов,
«ТК – Инженер үзәге» ҖЧҖ
генераль директоры

Принципларга тугры калып

Хөрмәтле Хәмзә Әзәлович! Үткәннәргә, шул исәптән бергә үткәргән озын хезмәт елларына борылып караган саен, мин Сезнең тормыш юлыгыздагы гаҗәеп күп казанышларның бер кеше язмышына ничек сыя алуына ышанып җитә алмый торам.

Төзелеш, нефть эшкәртү, энергетика – Сез эшли башлаган һәрбер өлкә Сезне бер карусыз кабул итә, чөнки Сез ия булган принципиаль профессиональлек, зирәк акыл, феноменаль хезмәт сөючәнлек һәм психологияне нечкә тоемлау кебек сыйфатларны һәр адымда табу мөмкин түгел.

Сезнең күпсанлы шәкертләрегездән булган профессионаллар, шул исәптән югары звено җитәкчеләре бүгенге көндә, кайчандыр үз остазларыннан алган принципларына тугры калып, республикада һәм аннан читтә дә, ягъни илебезнең төрле почмакларында хезмәт итәләр.

Нык һәм тату гаиләгез Сезгә танылу китерәчәк кыю максатларыгызны тормышка ашыру өчен төпле җирлек булдырды. Аның һәр әгъзасы өчен үз һәм кадерле Сез – ышанычлы һәм зирәк тормыш иптәше буларак та, сөекле әти һәм бабай буларак та.

Кадерле дустым! Без иңгә-иң торып, бер-беребезгә ышанычны саклап, уңышлы һәм катлаулы еллар аша үттек. Шуңа да бүгенге юбилееңкөнендә алга таба да тормыш юлыннан шундый ук ышанычлы адымнар белән, безнең барыбызда да җуелмас эз калдырган принципларга тугры калып, атлавыңны телим.

Рифгать Вәлиев,
«ТКМУ «Термостепс» ААҖнең
генераль директоры

Үз эшенең патриоты

Хөрмәтле Хәмзә Әзәлович, Сезне үзебезнең идарә коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз – 60 яшьлегегез белән котларга рөхсәт итегез!

Сезне һәрвакыт дөрес максатны сайлап ала һәм аңа ышанычлы рәвештә һәм максималь бирелгәнлек белән бару аерып торды. Шуңа да Сезне, һич шикләнмичә, үз эшегезнең патриоты дип атарга була. Нинди генә вазыйфаны башкарсагыз һәм нәрсә белән генә шөгыльләнсәгез дә, Сездәге сирәк очрый торган профессиональ һәм шәхси сыйфатларның бер-берсенә тәңгәллеге барлык башлангычларыгызда югары нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә.

Без Сезнең белән үз вакытында уңышлы партнёрлык мөнәсәбәтләрендә торуыбыз белән горурланабыз. Бу хезмәттәшлек безгә шуны төшендерде: профессионал буларак, Сезнең өчен бердәнбер төп принцип бар – үзегез дә намуслы рәвештә максималь бирелгәнлек белән эшлисез, хезмәткәрләрегездән дә шуны таләп итәсез. Зирәк акыл, тиз һәм дөрес карар кабул итү, командада эшли белү, стратег һәм идарәче таланты – болар Сезгә бүген дә республика халкына хезмәт итәргә мөмкинлек бирүче төп сыйфатларның кайберләре генә. Бу хакта Сезгә бирелгән күпсанлы бүләкләр һәм мактаулы исемнәр дә сөйләп тора: ТР һәм РФнең атказанган төзүчесе, «Татнефть»нең Почётлы нефтьчесе, Минин һәм Пожарский исемендәге «Лаеклы гражданинга – рәхмәтле Россия» милли премиясе лауреаты, «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләр өчен» ордены, бизнестагы тел тидермәслек абруй өчен «Сократ исемендәге халыкара бүләк» һәм башкалар.

PRESSA.RU

Үз-үзен хөрмәт иткән һәр авылда сезгә нинди дә булса бабай сөйләп бирерлек бер яисә ике риваять була. «Татарстан» мондый риваятьләр белән төрле вакыйгаларга искиткеч бай авылны тапты. Моннан соң инде аны без генә түгел, ә бөтен Татарстан да беләчәк.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: «БЕРМУД ӨЧПОЧМАГЫ», ҮПКӘЛӘГӘН КҮЛ ҺӘМ ПЫЧРАК МУНЧА

Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылында... тылсымлы юл чаты бар. Төнлә белән анда барып чыккан иң-иң аек кеше дә барасы юнәлешен таба алмый иза чигә. Әйтик, кеше Олы Солтан авылының үзәгенә эләгергә тели, ә үзе күрше Зюзино авылына барып чыга. Югыйсә төн дә айлы, аяз, авыл да уч төбендәгедәй күренеп тора, һәм юл да шул якка бара кебек – тик, әллә нишләсәң дә – барасы җиреңә эләкмисең. Кисәтүләргә дә карамастан, үз башына бәла эзләп, шунда барып чыккан кешеләр аңа «Бермуд өчпочмагы» дигән исем биргән.

Ә «Бермуд өчпочмагын» әйләнеп үткән кешеләр Олы Солтан һәм Черемыш авыллары арасындагы күл тирәсендә дә шундый ук хикмәтләр булуы турында сөйли. Черемышлар аны – Солтанныкы, ә Солтанныкылар Черемышныкы дип йөртә. Бәлки бөтен бәлаләр шуның аркасында килеп чыгадыр? Бер заман ул күл кипкән булган һәм аның җирен Черемыш җитәкчелеге – үз авылы кешеләренә, ә Солтанныкылар үз авылы кешеләренә бүлеп биргән. Күрәсең, күл мондый буталчыкка үпкәләгән, һәм яңа игенчеләргә теге юл чатындагыдан да хәтәррәк хәлләр күрсәтә башлаган: болар йә үз биләмәләрен таба алмыйча, тапсалар – өйләренә кайта алмыйча аптырыйлар икән...

Тик моның белән генә бетми әле! Олы Солтандагы иң гадәти мунчалар да чынлыкта гадәти түгел. Элеккеге участковый Харис абый авылдашларына еш кына бер мунча турындагы риваятьне сөйли торган булган. Бервакыт ул, яшь һәм күптән түгел өйләнгән ир-егетләр кичләрен сөйләшеп утырырга, дәртле яшь хатыннарыннан беразга ял итәргә дип җыела торган авыл советы бинасыннан кайтып бара икән. Менә бер мунча яныннан уза, кесәсендә, билгеле инде, табель коралы да бар. Кинәт мунча өйалдында бала елаган тавыш ишетә. Харис абый балага ярдәмгә ташлана, мунча өйалдына кереп, як-ягына карана, ул арада бала тавышы инде мунчаның эченнән үк ишетелә башлый. Анда барып керә, хәзер инде елау тавышы алгы якка күчкән. Шунда Харис абый бу мунчаның чиста түгеллеге турында йөргән сүзләрне исенә төшерә дә куркып китә. Һәм шунда ук чыгып йөгерә. Хәзер бу урында ул мунча юк инде, Харис абый да исән түгел. Әмма аның сөйләгәннәрен авылдашлары онытмый, бу урынны һәрвакыт читләтеп уза.

ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКОЕ ИЗДАНИЕ

ТАТАРСТАН

Реклама 16+

В нашем инстаграме – душа «Татарстана»!

PRESSA.RU

НОМЕР КӘЕФЕ:

ТОРМЫШКА КАЙТАРУ

Казан буенча искегә, ташландык урыннарга, аутентика белән психоделикага мода йөри. Уңайсызлыкларны сагынган халык әле, кысан булса да, шуның ямен табып, «мунча артындагы гаражда» «Свияжск музей-тыюлыгы» директоры Артем Силкин башкаруында ул үзе үк иҗат иткән Свияжск әкиятләрен тыңларга җыела. Әле, үз фотосәяхәтләрен челтәргә урнаштырып, соклануды лайклар җыя-җыя, элеккеге «Тасма»ның ташландык цехларына экспедицияләр оештыра. Әле, җитен комбинаты буларак мәгълүм Алафузов фабрикасының яшәргә яраксыз, әмма искелек яратучыларда көчле тәэсирләр уята торган хәрабәләрен үзләштерергә керешә.

XIX гасырда Казанда иң уңышлылардан саналган җитештерү йөзьеллыкның депрессив һәм җимерек хәрабәсенә әверелде. Әмма бүген, булдыклы кулларга эләгеп, җитен комбинаты яңа кыяфәт ала. Яныннан үтеп йөрүче һәркемне борынгы капкалары өстендә калкып утыручы биниһая зур бинасы белән шаккатыра ул. Кая керәбез?









Ната Смирнова фотолары

Кая элэгэчэкбез? Нэрсэ күрэчэкбез? Югарыда телгэ алынган булдыклылар тудырган төс-кыяфэткэ бага-бага, «лофт-пространство»га элэгэбез. Һэм менэ ни күрэбез: гаҗэеп зур гипс битлеклэр, пелэш манекеннар, ватык көзгедэн җыелган сигезаяк һэм элеге тарихи мэйданга нигез салучы – беренче гильдия сэүдэгэр, Казанның «мануфактур-киңэшчесе» һэм нэселле гражданины Иван Алафузовның йөзе: ул вакыт таушалдырып бетергэн кирпеч диварга граффити ысулы белэн ясап куелган. Менэ шушы формалар һэм күлэмнэр төрлелеге стандарт булмаган матурлыкны яратучыларны үзенэ тарта да инде. Индустриаль мэйдан Казан кешелэрен һэм аның кунакларын перформанслар, кинолар, концертлар, заманча базарлар, хэрабэлэрдэ яшеренгэн тагын эллэ нилэр белэн кызыктырып, үзенэ чакырып тора. Сэер атмосфера: эллэ Чернобыль, эллэ экияти Каф тавы артлары... Җимерек мануфактуралар арасында йөргэндэ, көндезлэрен дэ үзеңне арт-хаус киносында, яки Советлар Союзының элеккеге кайтавазлары һэм көмеш гасыр сэламнэре өермэсендэ тоеп була. Төннэрен исэ, җирле ди-джейлар белэн бергэ, җанланып, бирегэ Европа рейвлары очып килэ. Киловаттлы тавышлар, тонналаган энергия һэм акылдан яздырырлык ритмнар. XIX гасырның икенче яртысыннан Адмиралтия бистэсенең чын хуҗасына эверелгэн Иван Иванович Алафузов үзенең җитен фабрикасының хэрби кием-салым, постау, җитен тукымалар, ат җигү кирэк-ярагы һэм күн эйберлэр чыгару белэн генэ чиклэнмэячэген белсэ икэн! Хэер, белсэ дэ, кэефе төшмэс иде, чөнки бер генэ эшмэкэрлек төре дэ аңа ят булмаган. Эшчелэр театры (Гладилов урамы, 49 йорт) һэм XIX гасыр ахырында төзелгэн Александр II исемендэге Мэгариф йорты да – аның идеясе бит. Бию кичэлэре, эдэби укулар, «томанлы сурэтлэр» күрсэтү, спектакллэр һэм эшчелэрнең айлык хезмэт хакларының дүрттэн өч өлешенэ кадэр бэягэ кредитка эйберлэр сатып алырлык кулланучылар кибете... Формалары төрле, максаты бер. Ревитализация, уйлап карасаң. Сүзен сүзгэ тэрҗемэ итсэк – «тормышка кайтару», ягъни мэсэлэн.

ХОЧЕШЬ ЗАРАБАТЫВАТЬ С НАДЕЖНЫМ И СИЛЬНЫМ ПАРТНЕРОМ?

ГКЗ | ГЛАЗОВСКИЙ комбикормовый завод

Входит в группу компаний КОМОС ГРУПП

СТАНЬ ДИЛЕРОМ

ГЛАЗОВСКОГО КОМБИКОРМОВОГО ЗАВОДА
В ЛЮБОМ РЕГИОНЕ РОССИИ!

Реклама

ДИЛЕРАМ МЫ ОБЕСПЕЧИВАЕМ:

- бесплатные образцы комбикормов
- рекламный баннер на торговую точку
- инструкции по кормлению и каталоги продукции
- % скидки*

Позвони и уточни условия сотрудничества

+7 (912) 010-53-51, ljapushinds@kombi-korm.ru, www.kombi-korm.ru

* Подробности по телефону +7 (912) 010-53-51. Срок действия скидок до 31 декабря 2017 г.